Боерык

<u>05.05.2014</u> <u>№163-осн</u>

Казан ш.

**Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 2 өлеше, 2008 елның 22 маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлешендәге 1 пункты нигезендә,
**боерык бирәм:**

1. Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын расларга.
2. Мәгълүмати технологияләрне үстерү секторы җитәкчесенә (М.В. Киселев) әлеге боерыкны теркәү һәм бастырып чыгаруны техник яктан тәэмин итәргә.
3. Юридик бүлек башлыгына (М.В. Зайцева) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми төстә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
4. Финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлеге бүлеге башлыгына (А.К. Ганиева) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итүгә бәйле булган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр в.б. Х.Г. Мусин

Татарстан Республикасы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

# Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламенты

Казан, 2014 ел

| | ЭЧТӘЛЕК | Бит № |
|---|---|---|
| | Кереш | 5 |
| | Россия Федерациясенең Закон чыгару актлары | 6 |
| | Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база | 14 |
| **1 бүлек** | **ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР** | 16 |
| 1 | Урманчылыкка кыскача сыйфатлама | 16 |
| 2 | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | 23 |
| **2 бүлек** | **Урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү нормативлары** | 32 |
| 2.1 | Үзагач әзерләгәндә урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары (диләнке хисабы), параметрлары һәм вакытлары | 32 |
| 2.2 | Урманнардан чәер зерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 78 |
| 2.3 | Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 79 |
| 2.4 | Урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 83 |
| 2.5 | Урманнардан аучылык хуҗалыгын алып бару һәм аучылык белән шөгыльләнү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 97 |
| 2.6 | Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 101 |
| 2.7 | Урманнардан фәнни-тикшерену һәм мәгариф эшчәнлеге башкару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 122 |
| 2.8 | Урманнардан рекреация эшчәнлеге башкару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 122 |
| 2.9 | Урманнардан урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 217 |
| 2.10 | Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 128 |
| 2.11 | Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 129 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12 | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләр башкару максатларында рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 131 |
| 2.13 | Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 134 |
| 2.14 | Урманнардан электртапшыру линияләре, элемтә линияләре, юллар, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 137 |
| 2.15 | Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 145 |
| 2.16 | Урманнардан дини эшчәнлек башкару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары | 145 |
| 2.17 | Урманнарны саклау, яклау, яңадан үстерүгә карата таләпләр һәм нормативлар | 147 |
| 2.18 | Урманнардан урман үсү зоналары һәм урманлы районнарга ярашлы файдалану нормативлары | 234 |
| **3 бүлек** | **Урманнардан файдаланудагы чикләүләр** | |
| 3.1 | Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләүләр | 235 |
| 3.2 | Махсус сакланучы урман кишәрлекләре буенча кисү төрләрен чикләү | 237 |
| 3.3 | Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр | 241 |
| | Татарстан Республикасы Лубян урманчылыгы урманнарының максатчан билгеләнеше буенча кварталларының мәйданнарын бүлгәләүнең квартал саен исемлеге | |

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты - Лубян урманчылыгы урманнарын файдалануны, саклауны, яклауны һәм яңадан җитештерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексының (алга таба – РФ УК) 87 статьясының 7 өлеше нигезендә, 2012 елның 4 апрелендәге "Урман хуҗалыгы регламентлары составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында" 126 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган программа буенча эшләнде.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылыкның территориясенә, урман үстерү шартларына карата кулланылучы урманнарны комплекслы үзләштерүнең нормативлары һәм параметрлары җыелмасын үз эченә ала һәм урман кишәрлекләренең хокукый тәртибен билгели.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылык чикләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан торгызуны гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле (РФ УК 87 ст., 6 ө.).

Урман хуҗалыгы регламентында урманчылык чикләрендә урнашкан урманнарга карата, РФ УК 87 статьясының 5 өлеше нигезендә, түбәндәгеләр аныклана:

– РФ УК 25 статьясы нигезендә билгеләнүче урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән төрләре;

– агач кисентеләренең яше, диләнке хисабы, урманнардан файдалану вакытлары һәм алардан рөхсәтле файдалануның башка параметрлары;

– РФ УК 27 статьясы нигезендә урманнардан файдалануны чикләү;

– урманнарны саклау, яклау, яңадан торгызуга карата таләпләр;

Урманнардан файдалануның төрләре буенча ел саен мөмкин булган файдалану күләмнәре урман хуҗалыгы регламентының гамәлдәге вакыты өчен билгеләнгән һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

– урманның кеше сәламәтлеге өчен әйләнә-тирәлекне булдыручы, су саклаучы, яклаучы, санитар-гигиена һәм башка файдалы үзлекләрен саклау һәм көчәйтү;

– җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча урманнардан күпмаксатлы, рациональ, өзлексез, бетермичә файдалану;

– урманнарның токым составын һәм сыйфатын яңадан үстерү, яхшырту, аларның продуктлылыгын, сакланышын һәм якланылуын арттыру;

– урман фонды җирләреннән рациональ файдалану;

– бердәм техник сәясәт нигезендә урман хуҗалыгын алып баруның нәтиҗәлелеген арттыру, фән, техника һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын куллану;

– биологик төрлелеген, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектларын саклау.

Түбәндәрәк аларга нигезләнеп урман хуҗалыгы регламенты булдырылган норматив-хокукый, норматив-техник, методик закон документларының исемлеге китерелә:

## Россия Федерациясенең Закон чыгару актлары

2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ УК).

2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ СК).

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК).

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба – РФ ГК).

1992 елның 21 февралендәге "Җир асты байлыклары турында" 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – "Җир асты байлыклары турында" РФ Законы).

1994 елның 21 декабрендәге "Янгын куркынычсызлыгы турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – "Янгын куркынычсызлыгы турында" ФЗ).

1995 елның 14 мартындагы "Махсус саклanучы табигый территорияләр турында" 33-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 24 апрелендәге "Хайваннар дөньясы турында" 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 26 декабрендәге "Геодезия һәм картография турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 19 июлендәге "Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында" 109-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 26 сентябрендәге "Намус иреге һәм дини берләшмәләр турында" 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы Федераль закон).

2007 елның 24 июлендәге "Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында" 221-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон).

1999 елның 31 мартындагы "Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон).

2001 елның 18 июнендәге "Җир төзелмәсе турында" 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы Федераль закон).

2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 26 мартындагы "Электр энергиясе турында" 35-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 07 июлендәге "Элемтә турында" 126-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы Федераль закон).

2006 елның 04 декабрендәге "Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында" 201-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 17 декабрендәге "Орлыкчылык турында" 149-ФЗ номерлы Федераль закон (149-ФЗ номерлы Федераль закон).

2009 елның 24 июлендәге "Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

## Аларны җайга салу Россия Федерациясе Урман кодексы һәм аларны җайга салучы норматив-хокукый актлар белән каралган хокукый мөнәсәбәтләр (01.01.2013 елга карата).

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 59 ст. | Сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган урман үсемлекләрен саклау | "Россия Федерациясенең Кызыл китабы турында" 19.02.1996 ел, № 158 РФ Хөкүмәте карары |
| 91 ст. 7 ө. | Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе | "Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе турында" 03.03.2007 ел, № 138 РФ Хөкүмәте карары |
| 100 ст. 2 ө., 81 ст. 38 п. | Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләп чыгару таксалары һәм методикалары | "Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару турында" 08.05.2007 ел, № 273 РФ Хөкүмәте карары |
| 96 ст. 6 ө. 81 ст. 36 п. | Дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген башкару тәртибе | "Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау турында" 22.06.2007 ел, № 394 РФ Хөкүмәте карары |
| 50 ст. 3 ө. | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләме | "Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләмен билгеләү турында" 22.06.2007 ел, № 395 РФ Хөкүмәте карары |
| 73 ст. 4 ө. 81 ст. 27 п. | Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары | ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел, № 310 РФ Хөкүмәте Карары |
| 44 ст. | Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе | "Су объектын файдалануга тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында" 30.12.2006 ел, № 844 РФ Хөкүмәте карары. |
| 45 ст. | Урманнарны линияле объектлар төзүдә файдалану | "Россия Федерациясенең элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында" 09.06.1995 ел, № 578 РФ Хөкүмәте карары |
| 76 ст. 3 ө.<br>81 ст. 30 п. | Федераль милектәге җирләрдә әзерләнүче диләнкеләр күләменең берәмлеге өчен түләү ставкалары (урман утыртмаларын сату–алу килешүе өчен) | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел, № 310 РФ Хөкүмәте Карары |
| 55 ст. 3 ө.; 81 ст. 17 п. | Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен раслау турында" 29.06.2007 ел, № 414 РФ Хөкүмәте Карары |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында" 30.06.2007 ел, № 417 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарны янгынга каршы кору турында" 16.04.2011 ел, № 281 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча көчләрне һәм янгын сагы бүлекчәләре чараларын җәлеп итү кагыйдәләрен раслау турында" 05.05.2011 ел, № 344 РФ Хөкүмәте Карары<br>"Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында" 17.05.2011 ел, № 376 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урман янгыннарын сүндерү планын һәм аның формасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында" 17.05.2011 ел, № 377 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында" 18.08.2011 ел, № 687 РФ Хөкүмәте Карары |
| 22 ст. 3 ө. | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау тәртибе | "Урманнарны үзләштерү өлкәсендәге өстенлекле инвестиция проектлары турында" 30.06.2007 ел, № 419 РФ Хөкүмәте Карары |
| 6 ст. | Урманнар урнашкан җирләрнең категорияләре | "Урман фонды җирләрен башка төр (бүтән) категория җирләренә күчерү турында документлар составы һәм аларны әзерләү тәртибе турында" 28.01.2006 ел, № 48 РФ Хөкүмәте Карары |
| 105 ст. 7 ө. | Урман–парк зоналарының, яшел зоналарның функция зоналарын билгеләү | "Урман-парк зоналарының функция зоналарын, урман-парк зоналарының, яшел зоналарның мәйданын һәм чикләрен билгеләү турында нигезләмә раслау турында" 14.12.2009 ел, №1007 РФ Хөкүмәте Карары |
| 13 ст. | Урман инфраструктурасы | "Саклык урманнары, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында" 2012 елның 17 июнендәге №1283-р РФ Хөкүмәте Әмернамәсе |
| **Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгы актлары (РФ ТРМ)** | | |
| 62 ст. 3 ө.<br>81 ст. 21 п. | Урман торгызу кагыйдәләре | "Урман торгызу кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №183 боерык |
| 64 ст. 3 ө.<br>81 ст. 23 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарны карап тору кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №185 боерык |
| 103 ст. 6 ө.<br>81 ст. 40 п. | Махсус саклanучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу үзенчәлекләре | "Махсус саклanучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №181 боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (Рослесхоз) боерыклары** | | |
| 88 ст. 2 ө. | Урманнарны үзләштерү проектының составы һәм аны эшләү тәртибе | "Урманнарны үзләштерү проектының составын һәм аны эшләү тәртибен раслау турында" 29.02.2012 ел, №69 боерык |
| 104 ст. 2 ө.<br>107 ст. 4 ө. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләре | объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |
| 15 ст. 3 ө. | Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар | "Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, №61 боерык |
| 86 ст. 5 ө. | РФ субъектының урман планы составы һәм планны әзерләү тәртибе | "Россия Федерациясе урман планының типлаштырылган формасын һәм составын, аны әзерләү тәртибен раслау турында" 5.10.2011 ел, №423 боерык |
| 87 ст. 7 ө.<br>81 ст. 34 п. | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдәге вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | "Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында" 04.04.2012 ел, №126 боерык |
| 81 ст. | Урманнарны саклык категорияләре буенча аеру | "Урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатацияләнүче урманнарга, резервтагы урманнарга кертү буенча вакытлы күрсәтмәләрне раслау турында" 26.08.2008 ел, №237 боерык |
| 15 ст. 4 ө. | Кисентеләрнең яше | "Кисентеләрнең яшен билгеләү турында" 19.02.2008 ел, №37 боерык |
| 29 ст. 5 ө.<br>81 ст. 1 п. | Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе | "Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе турында" 27.05.2011 ел, №191 боерык |
| 29 ст. 9 ө.<br>81 ст. 4 п. | Үзагач әзерләү кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Үзагач әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 01.08.2011 ел, №337 боерык |
| 39.1 ст. | Урман үсемлекләренең утырту материалларын үстерү | "Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкеннәрне) үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 19.07.2011 ел, №308 боерык |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен | "Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | файдалану | 10.06.2011 ел, №223 боерык |
| 43 ст. | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану | "Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 27.12.2010 ел, №515 боерык |
| 31 ст. | Чәер әзерләү | "Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 24.01.2012 ел, №23 боерык |
| 91 ст. 9 ө.; 81 ст. 35 п. | Дәүләти урман реестрын алып бару тәртибе | "Дәүләти урман реестрын алып бару турында" 30.05.2011 ел, № 194 боерык; "Дәүләти урман реестрын алып бару рәвешләрен раслау турында" 15.02.2012 ел, №194 боерык |
| 32 ст. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | "Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында" 05.12.2011 ел, №512 боерык |
| 39 ст. | Җимешле, җиләкле декоратив урман үсемлекләрен үстерү | "Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, № 510 боерык |
| 34 ст. | Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үсемлекләрен әзерләү | "Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №511 боерык |
| 40 ст. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча урманнардан файдалану | "Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 23.12.2011 ел, №548 боерык |
| 41 ст. | Рекреация эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану | "Урманнардан рекреация эшчәнлеген башкару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 21.02.2012 ел, №62 боерык |
| 104 ст.<br>105 ст. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |
| 49 ст. 3 ө.<br>81 ст. 14 п. | Урманнардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 60 ст. 2 ө. 81 ст. 20 п. | Урманнарны саклау һәм алардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 63 ст. 2 ө. 81 ст. 22 п. | Урман үрчетү кагыйдәләре | "Урман үрчетү кагыйдәләрен раслау турында" 10.01.2012 ел, №1 боерык |
| 66 ст. 2 ө. 81 ст. 25 п. | Урманнарны яңадан үстерү һәм урман үрчетү турында хисап рәвеше, аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 89 ст. 1 ө. | Урманнарны үзләштерү проектының дәүләт һәм муниципаль экспертизасы тәртибе | "Урманнарны үзләштерү проектының дәүләт һәм муниципаль экспертизасы тәртибен раслау турында" 22.12.2011 ел, №545 боерык |
| 26 ст. 3 ө. 81 ст. 3 п. | Урман декларациясенең рәвеше, аны тутыру һәм тапшыру тәртибе | "Урман декларациясе турында" 17.01.2012 ел, №18 боерык |
| 77 ст. 5 ө. 81 ст. 31 п. | Дәүләт яки муниципаль милектәге урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти һәм муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм Урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 318 боерык |
| 74 ст. 5 ө. 29 һәм 28 п. 81 ст. | Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 319 боерык |
| 38 ст. | Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану | "Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №509 боерык |
| 26 ст. 6 ө. 81 ст. 2 п. | Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеге | "Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында" 05.12.2011 ел, №513 боерык |
| 46 ст. 3 ө. 81 ст. 13 п. | Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләре | "Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 12.12.2011 ел, № 517 боерык |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын һәм санитар иминлек | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгын яисә санитар иминлекне тәэмин итү |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | кагыйдәләре | максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чараларының үтеп керүен, урманнарда билгеле бер эш төрләрен үткәрүне чикләү тәртибен раслау турында" 03.11.2011 ел, №471 боерык "Урманнарны янгынга каршы кору турында турында" 27.04.2012 ел, №174 боерык "Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, урманнардагы һава торышына карап, табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында" 05.07.2011 ел, № 287 боерык |
| 67 ст.<br>68 ст. | Урман коруны үткәрү кагыйдәләре | "Урман кору күрсәтмәсен раслау турында" 12.12.2011 ел, №516 боерык. |
| | Санитар-тернәкләндерү чараларын үткәрү буенча күрсәтмә, Зарарлы организмнар чыккан урыннарны юк итү һәм бетерү буенча күрсәтмә, Урманнарны патологик яктан мониторинглауны проектлау, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә һәм Урманнарны патологик тикшеренүләрне планлаштыру, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә | "Методик документларны раслау турында" 29.12.2007 ел, №523 боерык. |
| **Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары** | | |
| 82, 83 ст. | | 2008 елның 22 маендагы "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 22-ТРЗ номерлы ТР Законы; 2009 елның 16 мартындагы "Татарстан Республикасының Урман планын раслау турында" ПУ-146 номерлы ТР Президенты Указы "2011-2014 елларда Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгын үстерү" озак вакытлы максатчан программасын раслау турында" 29.04.2011 ел, № 355 ТР МК Карары |

## Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә түбәндәгеләрдән файдаланылды:

– законнар, методик һәм норматив документлар нигезендә яшь класслары ысулы белән башкарылган 2012 елның урманкору материаллары;

– җир корылышы материаллары;

– Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсе органнарының исемлек һәм статистика хисаплылыгы;

– РФ Юстиция министрлыгында теркәлгән норматив-хокукый актлар.

Россия ТРМ урман хуҗалыгы регламентларына үзгәрешләр кертү тәртибе ачыкланды. Үзгәрешләрне кертү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

– урман торышы һәм структурасы буенча урман корылышын яисә махсус тикшеренүләрне уздырганда ачыкланган үзгәрешләр;

– урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге гамәлдә булган норматив-хокукый актлардагы үзгәрешләр;

– Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән очракларда.

Аларны Урман кодексына ярашлы торышка китерү өчен түбәндәге гамәлләр башкарылды:

– 01.01.2013 елга карата дәүләти урман реестры күрсәткечләре нигезендә урманчылыкның мәйданы билгеләнде.

– урманчылык кишәрлекләре буенча урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре билгеләнде;

– әзерләнгәннең күләме (диләнке хисабы), өлгергән һәм картайган утыртмаларны сайланма һәм тоташ кисүләрдә урманнарны рөхсәтле файдалануның параметрлары һәм вакытлары хисапланды;

– урманнарны карап тотканда, санитар-савыктыру чараларын үткәргәндә урта яшьле, өлгереп килүче утыртмаларны кискәндә әзерләнүче үзагач күләмнәре хисапланды;

– урманнардан чәер әзерләү буенча рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде,

– агач булмаган урман ресурсларын әзерләү буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– аучылык хуҗалыгын алып бару һәм аучылык белән шөгыльләнү, авыл хуҗалыгын алып бару буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу нормативлары билгеләнде;

– урманнардан максатчан билгеләнеш төрләре, махсус якланучы кишәрлек төрләре буенча файдаланудагы чикләүләрнең нормативлары, куллану төрләре буенча чикләүләр билгеләнде;

– урманнарның максатчан билгеләнеше буенча бүлгәләнешенә карап, картографик материалларга үзгәрешләр кертелде.

**Эшләп чыгару өчен нигезләр**

Урман хуҗалыгы регламенты 2013 елның 28 ноябрендәге, ТР Урман хуҗалыгы министлыгы белән төзелгән 092/71Д номерлы килешү нигезендә төзелде. Килешүдә Урман хуҗалыгы министрлыгы составында яңа урманчылык барлыкка килү сәбәпле, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын әзерләү буенча хезмәтләр күрсәтүне күздә тота.

**Эшләп чыгаручы оешма турында мәгълүматлар**

Урман хуҗалыгы регламенты ФГУП "Рослесинфорг" Казан филиалы тарафыннан эшләнде, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а, тел. (8-843) 272-31-83, 272-17-81, 272-33-92. ИНН/КПП ИНН/КПП 7705028865/52602001.

Лицензияләр:

Геодезия һәм картография эшләрен башкаруга 06.09.2012 ел, №77-00309Ф.

ФГУП "Рослесинфорг" Казан филиалы директоры - Йосыпов Айрат Якуб улы, тел.: (8843) 272 – 31 – 83.

Җаваплы башкаручы – ФГУП "Рослесинфорг" Казан филиалының 1 категорияле инженер-таксаторы – Пеньковцев Алексей Анатольевич, тел.: (8843) 272 – 31 – 83.

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1. Урманчылыкның исеме һәм урнашуы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Лубян урманчылыгы Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгыш өлешендә Кукмара административ районы территориясендә урнашкан. Кукмара ш.т.п. административ үзәге.

Урманчылыкның конторасы Лубян авылында урнашкан, ул республика башкаласы Казаннан – 214 км, иң якын Наратлык т/ю станциясеннән 30 км ераклыкта.

Урманчылыкның юридик һәм почта адресы: 422108, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Лубян ав., Техникум ур., 10 йорт.

Телефоннар: 2-32-60 код 8-855-57, факс: 2-31-66

E-mail:llt05@mail.ru

Урманчылыкның төньяктан көньякка кадәр озынлыгы – 14 км, көнчыгыштан көнбатышка кадәр – 36 км.

Татарстан Республикасы урманчылыкларының Лубян урманчылыгы территориясе аерып күрсәтелгән схематик картасы №1 карта-схемада күрсәтелгән.

### 1.2 Урманчылыкның гомуми мәйданы

01.01.2014 елга карата район урманчылыгының урман фонды җирләренең гомуми мәйданы – 12966 га тәшкил итә.

### 1.3 Урманчылык территориясен муниципаль берәмлекләр буенча бүлгәләү

Урманчылыкның структурасы

1 таблица

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Лубян | Кукмара | 12966 |
| **Урманчылык буенча барлыгы** | | | 12966 |

Урманчылыкның урман фонды җыйнак бүлгәләнгән урман массивыннан гыйбарәт.

Кварталлар күләме – 126 данә, кварталның уртача мәйданы - 103 га.

### 1.4. Урманчылыкның урнашуы

Урманчылыкның урман фонды урман массивыннан һәм урман кишәрлекләреннән торучы утраучыклардан гыйбарәт. Урманчылык территориясе буйлап Нократ елгасы һәм күпләгән санда кече елгалар, елгачыклар ага.

1.5. Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү РФ УК 15 ст. һәм "Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, №61 Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы боерыгы нигезендә башкарылды, ул 2 табл. күрсәтелгән.

2 таблица

**Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү**

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Урман үсү зонасы | Урманлы район | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Лубян | Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | Россия Федерациясе Европа өлеше ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | 1-126 | 12966 |
| **Урманчылык буенча барлыгы** | | | | **126** | **12966** |

3 таблица

## 1.6 Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы. га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Барлыгы урманнар | Лубян | 1 - 126. | 12966 | РФ Урман Кодексының 10 һәм 102 ст., Урман корылышы инструкциясе ("Урман корылышы инструкциясен раслау турында"12.12.2011 ел, № 516 Рослесхоз боерыгы) |
| Саклык урманнары, барлыгы | Лубян | 3373 | 3373 | |
| Шул исәптән: | | | | |
| махсус саклanучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнар | Лубян | 15, 30, 40, 46, 58-64 квартал өлешләре | 120 | |
| 1) су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Лубян | 3,7,15-17,22,24,25,27-32,39-41,45,46,48,55-59,63,64,72-74,81-84,90,91,95,96,102-104,106-111,114,115,123-126 квартал өлешләре | 821 | |
| 2) табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар, барлыгы | Лубян | | 316 | |
| әчәр су һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү буенча санитар сак зоналарының 1 һәм 2 поясларында урнашкан урманнар | Лубян | - | - | |
| | | | | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы. га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары | Лубян | шушы квартал өлешләре: 31,48-50, 67,68,85,86,96,97,104,105 | 316 | РФ Урман Кодексының 10 һәм 102 ст., Урман корылышы инструкциясе (12.12.2011 елдан № 516 "Урман корылышы инструкциясен раслау турында" Рослесхоз боерыгы) |
| Яшел зоналар | Лубян | - | - | |
| урман-парк зоналары | Лубян | - | - | |
| шәһәр урманнары | Лубян | - | - | |
| дәвалау-савыктыру җирлекләренең һәм курортларның (таулы-санитар) санитар сак округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урманнар | Лубян | - | - | |
| Кыйммәтле урманнар, барлыгы | Лубян | | 2236 | |
| шул исәптән: | | | | |
| дәүләт саклык урман полосалары | Лубян | - | - | |
| эрозиягә каршы көрәш урманнары | Лубян | - | - | |
| кеше аз йөри торган ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар | Лубян | 117-122 кварталлар<br>124 квартал | **720** | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы. га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | РФ Урман Кодексының 10 һәм 102 ст., Урман корылышы инструкциясе (12.12.2011 ел, №516 "Урман корылышы инструкциясен раслау турында" Рослесхоз боерыгы) |
| фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар | Лубян | - | **-** | |
| чикләвекле-кәсепчелек зоналары | Лубян | - | **-** | |
| җимешле урман утыртмалары | Лубян | - | **-** | |
| тасмалы наратлыклар | Лубян | - | **-** | |
| су объектлары буенда урнашкан тыюлы урман полосалары | Лубян | 66, 112 , 113 квартал Шушы квартал өлешләре: 31,48,49,67, 84,85,95-97,104-106,123,124,126 | **1072** | |
| уылдык саклаучы урман полосалары | Лубян | 116 квартал Шушы квартал өлешләре: 83,95,103,104,111,123,125 | **324** | |
| Эксплуатация урманнары | Лубян | Шушы кварталлар: 1,2,4-6,8-14,18-21, 23,26,33-38,42-44,51-54,65, 69-71,75-80,87-89,92-94,98-101 3,7,15-17,22,24,25,27-30,32,39,40,41,45-47,49,50,55-64,68,72-74,81,82,86,90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре | 9593 | |
| Резерв урманнар | Лубян | - | **-** | РФ Урман Кодексының 10 һәм 102 ст., Урман корылышы инструкциясе (12.12.2011 ел, №516 "Урман корылышы инструкциясен раслау турында" Рослесхоз боерыгы) |

**Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре**

– 04.12.2006 ел, Россия Федерациясе Урман кодексының 102 ст.;
– РФ Су кодексы;
– Урман корылышы инструкциясе ("Урман корылышы инструкциясен раслау турында" 12.12.2011 ел, №516 Рослесхоз боерыгы)
– "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, № 232 Рослесхоз Боерыгы.

***Су саклау зоналарында урнашкан урманнар*** РФ УК 102 статьясы, "Урманнарны саклык, эксплуатация һәм резерв урманнарына кертү турында" 20.03.08 ел, №84 РФ Табигый ресурслар министрлыгы боерыгы күрсәтмәләре нигезендә аерып чыгарылды.

***Далалы, ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, чүлләрдә, тауларда урнашкан урманнар*** *(элегрәк – категория – "бүтән саклык урманнары")* 11.08.1950 ел, №12221-р СССР МС Әмернамәсе нигезендә аерып чыгарылды.

***Автомобиль юллары буендагы саклык полосалары*** 14.07.1944 ел, №14537 СССР ХКС Әмернамәсе һәм 31.12.2003 ел, №702 ТР МК Карары белән расланган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеге нигезендә аерып чыгарылды.

***Яшел зоналарның урман хуҗалыгы өлешләре*** 04.05.1949 ел, №6136-р СССР МС Әмернамәсе, 22.06.93 ел, №168 Россиянең Федераль урман хуҗалыгы хезмәте боерыгы белән аерып чыгарылды. 20.03.08 ел, №84 Рослесхоз боерыгы нигезендә "авыл җирлекләренең һәм хуҗалык итүче объектларның яшел зоналары урманнарны" (урман хуҗалыгы һәм урман-парк өлешләре) "яшел зоналар, урман-парклар" категориясенә кертелде.

***Кыйммәтле кәсепчелек балыкларының уылдык чәчү урыннарын саклаучы тыюлыклы урман полосалары*** 26.10.1975 ел, №554 РСФСР МС Карары, 07.08.1978 ел, №388 РСФСР МС Карары белән аерып чыгарылды. "Урманнарны саклык, эксплуатация һәр резерв урманнарына кертү турында" 20.03.2008 ел, №84 Табигый ресурслар министрлыгы боерыгы нигезендә "кыйммәтле кәсепчелек балыкларының уылдык чәчү урыннарын саклаучы тыюлыклы урман полосалары" категориясе", категория өлешләренә бүлгәләп, "дәүләт саклык урман полосалары" категориясенә кертелде.

***Табигать һәйкәлләре*** – 23.07.1991 ел, №313 ТАССР Министрлар Кабинеты Карары белән 20.03.08 ел, №84 РФ ТРМ боерыгы нигезендә "табигать һәйкәлләре" категориясе дип (әгәр дә махсус сакланучы табигый

территорияләрдә урнашкан булсалар) "фәнни яки тарихи әһәмияткә ия урманнар" категориясе санала.

***II төркем эксплуатация урманнары*** 23.04.1943 ел, №430 СССР ХКС Карары белән аерып чыгарылган, 20.03.08 ел, №84 РФ ТРМ Боерыгы белән 2 төркемдәге барлык урманнар эксплуатация урманнарына кертелә.

**Урманнарның өстенлекле юнәлеше** – су саклау һәм саклык функцияләре, тотрыклы, максималь рәвештә нәтиҗәле итеп югары сыйфатлы үзагач һәм башка урман ресурсларын, аларны эшкәртү продуктларын алу максатларында урманнарның файдалы функцияләрен саклауны тәэмин итү.

4 таблица

## 1.7 Урманчылык территориясендәге урманлы һәм урмансыз урман фонды җирләренә сыйфатлама

| Җирләрнең категорияләре | Урманчылык буенча барлыгы | |
|---|---|---|
| | мәйданы,га | % |
| 1 | 2 | 3 |
| Җирләрнең гомуми мәйданы | 12966 | 100 |
| Урманлы җирләр - барлыгы | 12330 | 95 |
| Урман үсемлекләре белән капланган җирләр - барлыгы | 12048 | 93 |
| Урман үсемлекләре белән капланган җирләр - барлыгы | 282 | 2 |
| шул исәптән: | | |
| кисү | 100 | 1 |
| көекләр | - | - |
| аралыклар | - | - |
| аланнар | - | - |
| башкалар | - | - |
| Урмансыз җирләр - барлыгы | - | - |
| шул исәптән: | - | - |
| урман ызаннары | 86 | |
| юллар | 119 | 1 |
| сазлар | 119 | 1 |
| башкалар | 12 | |

## 1.8 Махсус саклanучы табигый территорияләр исемлеге

Лубян урманчылы территориясендәге 15, 30, 40, 46, 58-64 кв. махсус саклanучы табигый территория бар: региональ әһәмияттәге "Лубянка елгасы"

табигать һәйкәле, 120 га мәйданда. Аерып чыгарылган кишәрлек урманчылыкның Лубянка елгасы буенча сузылган түбәнге өлешен биләп тора. МСТТ 24.04.89 ел, №167 ТАССР МС Карары һәм 29.12.2005 ел, №644 ТР МК Карары нигезендә аерып чыгарылган.

## 1.9 Урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектлары сыйфатламасы (РФ УК 13, 14 ст.)

### 1.9.1 Урман инфраструктурасы объектлары

Урман инфраструктурасы объектларына урман юллары, урман саклыкханәләре һәм урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү өчен кулланылучы башка объектлар, асылда квартал урман юллары, чик линияләре, квартал һәм күрсәтмә баганалар, урман хуҗалыгы билгеләре керә.

Булган урман инфраструктурасы объектларыннан агач кисеп салынган 107 км квартал юллары кисүне һәм чистартуны таләп итә.

### 1.9.2 Урман эшкәртү инфраструктурасы

Урман эшкәртү инфраструктурасы табылган урман ресурсларын саклау һәм эшкәртү өчен билгеләнә, аларны саклык урманнарында булдыру тыела. Лубян урманчылыгы территориясендә урман эшкәртү инфраструктурасы юк.

## 1.2.Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре

Урманнардан файдалану урман мөнәсәбәтләрендә катнашучы булып саналган гражданнар, юридик затлар тарафыннан башкарыла (РФ УК 4 ст.). Шул ук вакытта, аның нигезендә урманнарны файдалану, саклау, яклау һәм яңадан үстерү экологик система кебек яисә табигый ресурс кебек урман төшенчәсеннән гамәлгә ашырылучы РФ УК 5 ст. чыгып; урман динамик рәвештә кире торгызылучы һәм трансформациягә бирелүче табигый ресурс буларак карала. Алга таба китереләчәк 5 таблицада урманнарны рөхсәтле файдалануның мөмкин булган төрләре һәм күләмнәре карала.

РФ УК, РФ УК 24, 25 ст. нигезендә алга таба Лубян урманчылыгында мөмкин булган урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре карала.

5 таблица

## Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре

мәйданы, га

| Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның һәм аларның өлешләренең исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Үзагач әзерләү | Лубян | <u>Карап тоту кисүләре, санитар кисүләр һәм бүтән кисүләр формасында</u><br>1. Су саклау зоналарында урнашкан урманнар - 3, 7, 15-17, 22, 24, 25, 27-32, 39-41, 45, 46, 48, 55-59, 63,64, 72-74, 81-84, 90, 91, 95, 96, 102-104, 106-111, 114, 115, 123-126 квартал өлешләре<br>2. Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары - 31,48-50,67,68,85,86,96,97,104,105 квартал өлешләре<br>3. Су объектлары буйларында урнашкан саклык урман полосалары - 66, 112, 113 квартал; 31,48,49,67,84,85,95-97,104-106,123,124,126 квартал өлешләре<br>4. Уылдык саклаучы урман полосалары - 116 квартал; 83,95, 103, 104,111, 123,125 квартал өлешләре<br>5. Фәнни яки тарихи әһәмияткә ия урманнар - 46, 60-64 квартал өлешләре<br><u>Сайланма кисүләр, карап тоту кисүләре, санитар кисүләр һәм бүтән кисүләр формасында</u><br>1. Далалы, ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, чүлләрдә, тауларда урнашкан урманнар - 117-122 кварталлар; 124 квартал өлешләре<br><u>Тоташ, сайланма кисүләр, карап тоту кисүләре, санитар кисүләр һәм бүтән кисүләр формасында:</u><br>1. Эксплуатация урманнары - 1, 2, 4-6,8-14,18-21,23,26,33-38, 42-44,51-54,65,69-71, 75-80, 87-89,92-94,98-101 кварталлар; 3,7,15-17,22,24,25,27-30,32,39, 40,41,45-47,49, 50,55-64,68,72-74,81,82,86,90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре | 12386 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Чәер әзерләү | Лубян | Эксплуатация урманнары - 1,2,4-6,8-14,18-21,23,26,33-38,42-44,51-54, 65,69-71, 75-80, 87-89,92-94,98-101 кварталлар; 3,7,15-17,22,24,25,27-30,32,39,40,41, 45-47, 49,50,55-64,68,72-74,81,82,86,90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре Далалы, ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, чүлләрдә, тауларда урнашкан урманнар - 117-122 кварталлар; 124 квартал өлешләре | 12386 |
| Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу | Лубян | 1 - 126 кварталларның урманлы җирләре | 12169 |
| Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару | Лубян | 1-45,47-59,65-126 кварталлар; 40, 60-64 квартал өлешләре Урманлы зонада, МСТТ һәм махсус саклanучы кишәрлекләрендә тыела | 12846 |
| Авыл хуҗалыгын алып бару. | Лубян | 3,7,15-17,22,24,25,27-32,39-41,45,46,48,55-64,72-74,81-84,90,91,95,96,102-104,106-111,114,115,123-126 квартал өлешләре; 1,2,4-6,8-14,18-21,23, 26,33-38,42-44,47,49-54,65-71,75-80,85-89,92-94,97-101,105,112-113,116-122 кварталлар. Яшел зонада, фәнни-тарихи әһәмияткә ия булган урманнарда (умартачылыктан гайре) һәм су саксалу зонасыныың яр буйларындагы саклык полосаларында тыела | 12025 |
| Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген башкару. | Лубян | 1 - 126 кварталлар | 12966 |
| Рекреация эшчәнлеген башкару | Лубян | 1 - 126 кварталлар | 12966 |
| Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | Лубян | Эксплуатация урманнары - 1,2,4-6,8-14,18-21,23,26,33-38,42-44,51-54, 65,69-71, 75-80, 87-89,92-94,98-101 кварталлар; 3,7,15-17,22,24,25,27-30,32,39,40,41, 45-47, 49,50,55-64,68,72-74,81,82,86,90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре Урмансыз һәм урман үсемл. белән капланмаган җирләрдә | 633 |
| Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үсемлекләрен үстерү. | Лубян | Эксплуатация урманнары - 1, 2, 4-6 ,8-14, 18-21, 23, 26, 33-38, 42-44, 51-54, 65, 69-71,75-80, 87-89, 92-94, 98-101 кварталлар; 3,7,15-17, 22, 24, 25, 27-30, 32, 39, 40, 41, 45-47, 49, 50, 55-64, 68, 72-74, 81, 82, 86, 90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре | 9593 |
| Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкечләрне) үстерү | Лубян | Эксплуатация урманнары - 114 квартал | 7 |
| Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләрне башкару | Лубян | 1-45,47-59,65-126 кварталлар; 40, 60-64 квартал өлешләре Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләрне башкару барча мәйданда рөхсәт ителә, яшел зонадан һәм фәнни-тарихи әһәмияттәге урманнардан кала | 12846 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү | Лубян | 1 - 126 кварталлар | 12966 |
| Электртапшыру, элемтә линияләрен, юлларны, торбаүткәргечләрне һәм башка линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү | Лубян | 1 - 126 кварталлар | 12966 |
| Үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү | Лубян | Эксплуатация урманнары - 1,2,4-6,8-14,18-21,23,26,33-38,42-44,51-54, 65,69-71, 75-80, 87-89,92-94,98-101 кварталлар; 3,7,15-17,22,24,25,27-30,32,39,40,41, 45-47, 49,50,55-64,68,72-74,81,82,86,90,91,102,107-110,114,115 квартал өлешләре | 9593 |
| Дини эшчәнлек башкару | Лубян | 1 - 126 кварталлар | 12966 |
| Бүтән төрләре | | | |

# 2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ВАКЫТЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ, ЯКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮСТЕРҮ НОРМАТИВЛАРЫ

## 2.1. Үзагач әзерләгәндә урманнарны рөхсәтле файдалану нормативлары (диләнке хисабы), параметрлары һәм вакытлары

### 2.1.1. Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кискәндә үзагач әзерләү өчен диләнке хисабы

РФ УК 29 ст. нигезендә, 27.05.2011 ел, №191 "Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибен раслау турында" Россия Рослесхоз боерыгы нигезендә, 19.02.2008 ел, №37 Рослесхоз боерыгы белән расланган урман утыртмаларын кисүләрнең яше нигезендә (10 табл.) кирәкле хисаплар башкарылды (6 табл.).

6 таблица

**Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдәге вакытына өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын сайланма кисү буенча диләнке хисабы**

| Күрсәткечләр | Барлыгы | | Шул исәптән тулылыклар буенча | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Га | Мең. м3 | 1.0 | | 0.9 | | 0.8 | | 0.7 | | 0.6 | | 0.3 – 0.5 | |
| | | | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Саклык урманнары**<br>**Урманнарның максатчан билгеләнеше: саклык урманнары**<br>Саклык урманнары категориясе – РФ субъекты милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары | | | | | | | | | | | | | | |
| **Хуҗалык секциясе: Наратлы** | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисапка барлыгы кертелде | 13 | 3,8 | | | | | | | | | 10 | 3,1 | 3 | 0,7 |
| Гомуми запастан уртача сайлап алу проценты | 12 | | | | | | | | | | | | | |
| Бер тапкырда кисеп ташлана торган запас | 10 | 0,5 | | | | | | | | | 10 | 0,5 | | |
| Уртача кабатланучанлык чоры | 10 | | | | | | | | | | | | | |
| Ел саен ясалучы диләнке хисабы: | 1 | | | | | | | | | | | | | |
| - тамыр | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| - ликвид | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| - эшлекле | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| - тамыр | | | | | | | | | | | | | | |
| - ликвид | | | | | | | | | | | | | | |
| - эшлекле | | | | | | | | | | | | | | |

| Күрсәткечләр | Барлыгы | | Шул исәптән тулылыклар буенча | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Га | Мең. м3 | 1.0 | | 0.9 | | 0.8 | | 0.7 | | 0.6 | | 0.3 – 0.5 | |
| | | | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Хуҗалык секциясе: Чыршылы** | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисапка барлыгы кертелде | 26 | 7,0 | | | | | | | | | 18 | 5,2 | 8 | 1,8 |
| Гомуми запастан уртача сайлап алу | 11 | | | | | | | | | | | 15 | | |

| Күрсәткечләр | Барлыгы | | Шул исәптән тулылыклар буенча | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Га | Мең. м3 | 1.0 | | 0.9 | | 0.8 | | 0.7 | | 0.6 | | 0.3 – 0.5 | |
| | | | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 | Га | Мең. м3 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| проценты | | | | | | | | | | | | | | |
| Бер тапкырда кисеп ташлана торган запас | 18 | 0,8 | | | | | | | | | 18 | 0,8 | | |
| Уртача кабатланучанлык чоры | 10 | | | | | | | | | | | | | |
| Ел саен ясалучы диләнке хисабы: | 2 | | | | | | | | | | | | | |
| - тамыр | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| - ликвид | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| - эшлекле | | 0,1 | | | | | | | | | | | | |
| **Хуҗалык секциясе: Товарлык юкә** | | | | | | | | | | | | | | |
| Хисапка барлыгы кертелде | 43 | 11,2 | | | | | 8 | 1,6 | | | 21 | 6,6 | 14 | 3,0 |
| Гомуми запастан уртача сайлап алу проценты | 13 | | | | | | | 30 | | | | 15 | | |
| Бер тапкырда кисеп ташлана торган запас | 29 | 1,5 | | | | | 8 | 0,5 | | | 21 | 1,0 | | |
| Уртача кабатланучанлык чоры | 10 | | | | | | | | | | | | | |
1 гектардагы техник яшеллек запасын билгеләү өчен әлеге утыртманың 1 гектарга карата агачларының уртача санын һәм аларның юанлык баскычлары буенча урнашуын белергә кирәк. Әгәр дә андый белешмәләр булмаса, 0,5 гектар күләмендә кулланып карау мәйданнарын ясарга кирәк һәм, агачларны санап, 1 гектар буенча һәр юанлык баскычындагы агачларның уртача санын ачыкларга. Килеп чыккан санга бер агачтан чыккан техник яшеллекне тапкырлап, 1 гектар буенча запасны ачыклыйлар, ә аннан соң чимал базасының барлык мәйданы буенча ресурсларын да. Хисап эшләрен алып барганда шулай ук 1 м3 карата билгеле агач токымының кәүсә массасыннан чыгучы уртача техник яшеллекне дә исәпкә алырга мөмкин.

Кабык, ылыслар, үзагачлар, органик булмаган һәм органик агач яшеллеге кушылмалары ГОСТ 21769-84 таләпләренә туры килергә тиеш.

Азык максатларында агач яшеллеген әзерләгәндә эт шомыртын, бүре җиләген, аю баланын, еламсар таллыкны, кабар агачын, имәнне куллану тыела.

***Агач булмаган ресурсларны саклау һәм кабат җитештерү***

Комплекслы система түбәндәге чаралар төркемен үз эченә ала:

– тикшеренүләр – чимал запасларын исәпкә алу һәм дару үләннәренең төп әрәмәлекләрен һәм әһәмиятле төрләре массивларын карталау;

– оештыру – иң беренче чиратта чикләнгән күләмдә таралучы һәм зур булмаган чимал запаслы төрләр өчен әзерләү күләмнәрен һәм районнарын планлаштыру;

– административ – тыюлыклар оештыру һәм сирәк дару үсемлек чималлары төрләрен җыеп алуны чикләү;

– тәрбияви – дару үләннәренең әһәмияте, дару ресурсларын саклау кирәклеге турында аңлату эшләре;

– культивацияле – әһәмиятле булган чималларны культивацияләү;

- техник – әзерлекләрне рациональ алып бару, чимал җыюның билгеләнгән ысулларын һәм вакытларын үтәү, яшь үрнәкләрнең җимшәнен һәм җир өстендәге өлешләрен калдыру һ.б.

## 2.4 Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу буенча рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу мондый урман ресурсларын алу, саклау һәм урманнан чыгаруга бәйле эшмәкәрлек эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Азык-төлек урман ресурсларына кыргый үсүче җимешләр, җиләкләр, чикләвекләр, гөмбәләр, орлыклар, каен суты һәм башка урман ресурслары керә.

Гражданнар һәм юридик затлар азык-төлек урман ресурсларын әзерләүне һәм дару үләннәрен җыеп алуны урман кишәрлеге арендасы килешүе нигезендә гамәлгә ашыра.

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу урманчылыкның яки урман-паркның урман хуҗалыгы регламенты нигезендә башкарыла.

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү кагыйдәләре РФ УК 34 ст. һәм 05.12.2011 ел, № 511 РФ Рослесхоз боерыгы белән расланган "Азык-төлек урман ресурсларын, урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре"  белән билгеләнә.

## 2.4.1 Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәрен җыеп алганда урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары

13 таблица

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үсемлекләрен җыеп алганда урманнардан файдалану параметрлары

| № п/п | Азык-төлек урман ресурслары, дару үләннәре төре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган әзерлек күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **Азык-төлек ресурслары** | | | |
| 1. | Чикләвекләр | Кг/га | 100 |
| 2. | Җиләкләр: кура җиләге | т | - |
| | җир җиләге | т | - |
| | миләш, шомырт | т | - |
| | **Җәмгысе** | т | **100** |
| 3. | Гөмбәләр: | т | 10 |
| | **Җәмгысе** | т | **10** |
| 4. | Агач сутлары: каен | т | - |
| 5. | һ.б.ш. | | - |
| **Дару чималы** | | | |
| 4. | Сары мәтрүшкә, ике өйле кычыткан, ландыш, аю табаны, дару ромашкасы, акбаш, эт тигәнәге, канлы үлән, песи үләне, сәдәп гөле, лапчатка, үги ана яфрагы, кыр наратбашы һ.б. | кг | 500 (коры көе) |

Җиләкләрнең, гөмбәләрнең һәм дару чималларының 60 % уңышы җирле халык тарафыннан үзләштерелә.

***Агач булмаган продукцияне куллану***

Соңгы 20-30 елда туфракның тыгызлануына, җимешләрне дөрес җыймауга һәм ахыр чиктә биологик тотрыклылыкны бозуга китергән янгыннар, урман җирләрен сусаклагыч сулары басу, урманнарга халыкның массакүләм йөрүе нәтиҗәсендә кыргый үсүче җиләкләрнең, җимешләрнең һәм гөмбәләрнең күләме 2-3 тапкырга кимеде.

Агач булмаган продукциянең бар булган запаслары аларны максатчан файдаланганда, әлеге ресурсларны дөрес һәм рациональ эксплуатацияләгәндә әзерлек күләмнәрен сизелерлек арттырырга мөмкинлек бирә.

***Җиләкле урманнарны инвентарьлаштыру***

Кара җиләк, нарат җиләге, күк җиләк һәм мүк җиләге әрәмәлекләре һөнәрчелеккә карый. Җиләкле үсемлекләре булган бүлемтекләрне һөнәрчелеккә кертүнең гомуми таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: мәйданы (редукцияләнгән) кимендә 0,5 га, куаклыгының куелыгы түбән һәм гектарына 2 мең данә күләмендә үсентеләре бар.

Һөнәрчелек критерийларына туры килми торган җиләклек куаклары резервлы санала һәм аерым исәпкә алына. Фитоценозларның табигый динамикасы процессында яки махсус чараларны үткәрү нәтиҗәсендә әлеге җирләр һөнәрчелек мәгънәсен алырга мөмкин.

Кара җиләкнең һәм нарат җиләгенең кайбер резерв куаклыклары югары фитомасса күрсәткечләренә ия, шуңа күрә үрентеләрне һәм яфракларны (дару чималы сыйфатында) әзерләү буенча төп база буларак хезмәт итә алалар.

Лубян урманчылыгы территориясендә һөнәрчелек әзерлеген оештыру өчен моңа охшаш җиләклекләр юк.

Җиләкле урманнар өч җиләк үсемлекләре белән каплану күрсәткечләре буенча төркемләнә: чагыштырмача түбән – 10-40%, уртача – 50-70%, югары – 80-100%.

Бу җиләк һәм дару чималларын әзерләгәндә, җыючыларны иң беренче чиратта әзерләнүче продукциянең иң зур концентрацияле урыннарына юнәлдереп, хезмәт һәм матди ресурсларны нәтиҗәле кулланырга ярдәм итә.

Объектта җиләк запасларын хисаплау еллык уртача уңышы таблицасы нормативлары ярдәмендә башкарыла (Икенчел дәрәҗәдәге урман ресурсларын һәм урманнан файдалануның өстәмә продуктларын исәпкә алу һәм бәяләү буенча кулланма, 2003 ел).

13.1 таблица

Урта Идел буендагы төрле урман җимешләренең һәм җиләкләренең чама белән уртача уңышы (уңышлы елларда)

| Үсемлекнең төре | Уңышлылык, кг/га | Уңышның кабатланучанлыгы | Үсемлекнең төре | Ундырыш, кг/га | Уңышның кабатланучанлыгы |
|---|---|---|---|---|---|

| Үсемлекнең төре | Уңышлылык, кг/га | Уңышның кабатланучанлыгы | Үсемлекнең төре | Уңдырыш, кг/га | Уңышның кабатланучанлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Кура җиләге | 250 | 1 – 2 | Җир җиләге | 50 | 1 – 2 |
| Карлыган | 300 | 1 – 2 | Миләш, 2500 куак/га | 1500 | 1 – 2 |
| Гөлҗимеш | 1000 | 2 – 3 | Артыш | 50 | 1 – 2 |

13.2 таблица

**Татарстан Республикасының төрле типлы урманнарында җиләкле, җимешле үсемлекләрнең һәм ашарга яраклы гөмбәләрнең уңдырышы**

| Урман типлары | Урман курасы | | Миләш | | Гөмбәләр | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | урманның гомуми мәйданыннан җиләк бирүче мәйдан %ы | Уртача уңдырыш, кг/га | урманның гомуми мәйданыннан җиләк бирүче мәйдан %ы | Уртача уңдырыш, кг/га | урманның гомуми мәйданыннан гөмбәле мәйдан %ы | Уртача уңдырыш, кг/га |
| **Наратлыклар** | | | | | | |
| Юкәлекле | | | | | 10 | 120 |
| Үләнле | | | | | яшь утыртмалардан 50 картларыннан - 10 | 30 |
| Лишайниклы | | | | | 10 | 100 |
| Нарат җиләкле | | | | | 10 | 50 |
| Кара җиләкле | | | | | 5 | 20 |
| Озын мүкле | | | | | | |
| Мамыкбашлы-сфагнумлы | | | | | | |
| Сфагнумлы | | | | | | |
| **Чыршылыклар** | | | | | | |
| Юкәлекле | | | | | 10 | 50 |
| Үләнле | | | | | 10 | 30 |
| Кара җиләкле | | | | | | |
| Озын мүкле | | | | | | |
| **Каенлыклар** | | | | | | |
| Юкәлекле | | | | | 10 | 200 |
| Үләнле | | | | | 50 | 200 |
| Нарат җиләкле | | | | | 5 | 100 |
| Кара җиләкле | | | | | 1 | 50 |
| **Усаклыклар** | | | | | | |
| Юкәлекле | | | | | 10 | 150 |
| Үләнле | | | | | 10 | 150 |
| Нарат җиләкле | | | | | 10 | 50 |
| Кара җиләкле | | | | | 1 | 20 |
| **Имәнлекләр** | | | | | | |
| 3-5 еллык киселгән урыннар | 20 | 300 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Үсемлекләр белән капланучы киселгән урыннар | | | 60 | 76 | | |

## 2.4.2 Һөнәрчелек запасын бәяләү һәм кыргый үсүче җиләкләрне әзерләү күләмнәрен проектлау, җиләкләрне һәм гөмбәләрне әзерләү вакытлары

Һөнәрчелек бәяләвенең беренче этабында җиләклекләрнең исәпкә алынган мәйданнарыннан түбәндәгеләр алып ташланырга тиеш:

– техноген пычрану зоналарында урнашкан җиләклекләр; техноген пычрану зоналарына юлның ике ягы буйлап 100 метр киңлектәге республика һәм район әһәмиятендәге автоюллар буйларында урнашкан урман полосаларын кертергә кирәк.

Техноген пычрануның башка зоналары һәр кишәрлек өчен аерым ачыклана.

Саклanучы территорияләрдә җиләкләр җыю рөхсәт ителми.

Һөнәрчелек бәяләвенең чираттагы этаплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– исәпкә алынган мәйданнарны һөнәрчелек (гектарына 100 кг артык булган уңдырышлы) һәм резерв (тотрыксыз һәм начар җимеш бирүче) төрләренә бүлү;

– җиләкләрнең эксплуатация (хуҗалык) запасын билгеләү, ул күзаллanучы хисаплар өчен биологик төреннән 50% тигез итеп кабул ителә (күрсәткеч аз өйрәнелгән);

– запасның транспорт шартлары буенча мөмкин булуын хисаплау.

Җиләкләрне сәнәгатьле әзерләгәндә җыючының җәяү үткәндәге юлының транспорт юлларыннан 5 км ераклыгы чик ара булып санала, зуррак булганда ул уңышлы булудан туктый.

Димәк, әгәр дә юл буйларының 5 чакрымлык зонасында җиләклек куаклыкларына үтеп керү мөмкин булса, ул вакытта 1 мең гектарга 2 км һәм аннан күбрәк юллар булу территориянең тулаем мөмкин булуы турында сөйли. Юлларның озынлыгы кимрәк булган очракта мөмкинлекнең тиешле коэффициенты кертелә һәм мөмкин булган запаслар әлеге зурлыкка кадәр киметелә.

Территориянең халкы һәм үтеп китүчеләрнең саны исәпкә алына. Әдәби күрсәткечләр буенча, шәхси кирәк-яракларга әзерләү өчен бер шәһәрдә яшәүчегә – 1 кг, авылда яшәүчегә 2 кг җыелган җиләк туры килә. Җиләк әзерләнмәләрендә икътисади мөмкинлекләрне билгеләү һәм аларның күләмнәрен проектлау өчен. Хисапка түбәндәге күрсәткечләр алына: җыючыларның саны, җиләкләрне җыйгандагы эшләнеш һәм әзерләү чорының озынлыгы.

***Гөмбәләрне җыюның нормативлары һәм вакытлары***

Әзерләүгә рөхсәт ителгән ашарга яраклы гөмбәләрнең исемлеген тармак стандартлары билгели. Азык-төлек һәм товар кыйммәте буенча ашарга яраклы гөмбәләрне дүрт категориягә бүләләр:

I – ак, гөреҗдә (чын һәм сары), нарат гөмбәсе;

II – усак гөмбәсе, каен гөмбәсе, майлы гөмбә, чын һәм эт гөреҗдәләре, подгруздкалар, имән гөмбәләре, гади шампиньоннар;

III – маховиклар, әтәч гөмбәләре, кара гөреҗдәләр, баллы гөмбәләр, кәҗә гөмбәләре, поляк гөмбәләре, ак йөнтәс гөмбәләр, валуй гөмбәләре, йөнтәс гөмбәләр, кыр шампионьоннары, ал гөмбәләр, җөйле гөмбәләр, җыерчалы гөмбәләр;

IV – шыгырдавык гөмбәләр, ачы гөмбәләр, бөгелгән сөтчелләр, яшел гөмбәләр, рядовкалар, шомачыклар, борыч гөреҗдәләре, кызыл гөмбәләр, юан гөмбәләр, урман шампиньоннары.

13.3 таблица

**Гөмбәләрнең иң киң таралган төрләре, җыеп алу вакыты һәм урыннары**

| Гөмбәләрнең атамалары | Җыеп алу вакыты | Җыеп алу урыны | Җирле атамасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Кәҗә гөмбәләре | Апрель - май | Нарат урманнарында урман киселгән, янгын булган, комлы туфраклы урыннарда | |
| Кәҗә гөмбәләре | Апрель - май | Нарат һәм карагай урманнарында, куаклыкларда | |
| Ак гөмбә | Июнь - сентябрь | Нарат, чыршы, каен һәм имән урманнарында | Нарат гөмбәсе, ак гөмбә, чыршылык ак гөмбәсе |
| Сары гөмбә | Август - сентябрь | Сирәк шытып чыккан нарат һәм чыршы урманнарында | Еловик, рядка |
| Ал гөмбә | Июнь – октябрь | Барлык урманнарда да, әмма иң күп очракта карагай урманнарында | Соры гөмбә, шайтан таягы, горянка |
| Каен гөмбәсе | Июнь – октябрь | Каен булган бөтен җирдә үсә | Кара шөлди, колосовик, обабок |
| Кызыл гөмбә | Июль - сентябрь | Яшь усаклыкларда һәм усак катнашмалы катнаш урманнарда | Кызыл башлы гөмбә, красюк |
| Майлы гөмбә | Июнь – октябрь | Наратлыкларда һәм вак яшь наратлыкларда (культураларда) | Майлы гөмбә, челыш, сары майлы гөмбә |
| Моховик | Июнь - сентябрь | Нарат урманнарында нечкә торфлы-комлы туфракларда | Чуар гөмбә |
| Баллы гөмбә | Август – октябрь | Нарат һәм карагай токымлы, бигрәк тә зирек агачлары төпләрендә | Көзге гөмбә |
| Әтәч гөмбәсе | Июнь - сентябрь | Каен, ылыслы һәм катнаш урманнардагы дымлы урыннар | Силосень, әтәч гөмбәсе |
| Валуй | Июль – октябрь | Барлык урманнарда да | Йодрыкчык, кульбик, ташбаш, забалуй |
| Гөреҗдә | Июль – октябрь | Яфраклы һәм юкә һәм чикләвек куаклары булган катнаш урманнарда | Грузель, сухарь |
| Дуңгыз гөмбә | Июнь – октябрь | Ылыслы һәм яфраклы урманнарда кырпуларда, юл буйларында, паркларда | Дунька, дуңгыз колагы |
| Йөнтәс гөмбә | Июль – октябрь | Катнаш һәм каен урманнарында | Кызылча, волжанка |

| Гөмбәләрнең атамалары | Җыеп алу вакыты | Җыеп алу урыны | Җирле атамасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ачы гөмбә | Май – октябрь | Нарат урманнарында дымлы урыннарда | Ачы гөмбә, терлек сары гөмбәсе |
| Шампиньон | Июль - сентябрь | Яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында, паркларда, болыннарда, көтүлекләрдә, чүплекләрдә | Гади шампиньон |
| Кәҗә гөмбәсе | Июль - сентябрь | Нарат урманнарында һәм дымлы урыннардагы катнаш урманнарда | |
| Поляк гөмбәсе | Июль - сентябрь | Нарат һәм чыршы урманнарында | Чикләвек гөмбәсе, саз гөмбәсе, нарат гөмбәсе |

Гөмбәләрнең массакүләм чыгу чорлары вакыты буенча сузылган, шуңа күрә гөмбәле мәйданнарның натур исәбе урман фондының натур инвентаризациясе буенча объектив була алмый.

Гөмбәләрнең уңдырышы һәм запаслары яшь класслары буенча таблицаларның – "Урман җирләрен урман типлары төркемнәре буенча бүлү" таблицасы һәм норматив таблица нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

0,8 тулылыклы утыртмалар, 10 яшькә кадәрге яфраклы яшь агачлар һәм 20 яшьлек чорга кадәрге чыршылыклар (аз продуктлы гөмбә урманнары буларак) хисапка кертелми; төп кисү яшендәге, аларда гөмбә җыю тыелган саклык территорияләрендәге утыртмаларны шулай ук хисаптан алып ташлыйлар.

Гөмбә ресурсларын тулы итеп файдалану өчен гомуми билгеле булган ашарга яраклы гөмбәләр генә түгел, ә халык тарафыннан аз җыела торган, азык кыйммәте һәм югары уңдырышы булган гөмбәләр дә натуралата исәпкә алына һәм исәпкә кертелә: сөтлегән (шома гөмбә), соры гөмбә, кара гөреҗдә, чын әтәч гөмбәсе, маховиклар, рядовкалар һ.б.

13.4 таблица

**Урман үсемчелеге шартлары типларының төп төркемнәрендә гөмбәләрнең биологик уңдырышы шкаласы**

| Урман тибы | Өстенлек итүче токым | Сезонлы уңдырыш, кг/га | | | Уртача еллык уңдырыш, кг/га |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Начар | Уртача | Яхшы | |
| Лишайниклы һәм тирәкле | С | 10 | 25 | 50 | 25 |
| Нарат җиләкле-яшел мүкле | С | 12 | 30 | 60 | 30 |
| Кара җиләкле | С | 16 | 40 | 80 | 40 |
| Чәчбайлы-кара җиләкле һәм өянкеле | С | 18 | 45 | 90 | 45 |
| Сәрдәле-сырмавыклы | С | 20 | 50 | 100 | 50 |
| Нарат җиләкле-яшел мүкле | Б | 24 | 60 | 120 | 60 |
| Кара җиләкле, майниклы-кара җиләкле | Б | 40 | 100 | 200 | 100 |
| Сәрдәле-сырмавыклы | Б | 34 | 85 | 170 | 85 |
| Нарат җиләкле-яшел мүкле | Ос. | 20 | 50 | 100 | 50 |
| Кара җиләкле, майниклы-кара җиләкле | Ос. | 30 | 75 | 150 | 75 |
| Сәрдәле-сырмавыклы | Ос. | 20 | 40 | 80 | 40 |

Әлеге таблицада гөмбәләрнең уңдырыш зурлыгы турындагы белешмәләр утыртмаларның гөмбәле мәйданнарына гадиләштерелгән. Гөмбәләрнең гомуми биологик запасларын барча ашарга яраклы гөмбәләрнең тулаем (суммар) уңдырышы буенча билгелиләр.

Таблица һәм натур таксация ярдәмендә түбән, уртача һәм югары уңдырышларда азык-төлек ягыннан иң кыйммәтле булган еллык запасларның хисабын эшлиләр, бу ревизияара чорларның һәр елында, аларның уңыш бирүенә карап, гөмбәләрнең чын запаслары турында фикер йөртү мөмкинлеген бирә. Гөмбәләрнең чама белән уңдырышын билгеләү критерийлары булып (ретроспектив анализ очракларын исәпкә алып) өч категория буенча Козьяков тәкъдимнәре (1981) хезмәт итә ала:

– түбән: вегетация чоры дәвамында гөмбәләр берән-сәрән генә очрый, әзерлек пунктлары гөмбәләрне кабул итми, җирле халык шәхси кирәк-яраклары өчен гөмбәләрне зур булмаган күләмдә әзерли;

– уртача: аерым төр гөмбәләре зур күләмдә очрыйлар, әзерлек һәм гөмбә кайнату пунктлары эшли, җирле халык шәхси кирәк-яраклы, базарларда сату һәм әзерлек пунктларына тапшыру өчен гөмбәләрне әзерли;

– югары: җәйге-көзге чорда гөмбәләр бөтен җирдә һәм күпләп очрый.

Эксплуатация запасларын хисаплаганда биологик уңдырышның "кортлау" буенча югалуларын исәпкә алалар. Барлык төрдәге гөмбәләр өчен "кортлау" процентын шартлыча 50% тигез итеп карау кабул ителгән.

Җыеп була торган һәм әзерләү өчен мөмкин булган гөмбә запаслары җиләк запасларына аналогик рәвештә билгеләнә (җиләкләрне әзерләү запасын һөнәрчелек бәяләве һәм күләмнәрен проектлауны кар.)

## Дару үләннәре

Безнең илдәге фәнни медицинада файдалануга рөхсәт ителгән 190 төрле дару үсемлекләренең якынча 60%ын кыргый үсүчеләр тәшкил итә, аларның күп өлеше урманнарда үсә. Моннан тыш, урман үсемлекләренең йөзләрчә төре халык (традицион) медицинада кулланыла.

13.5 таблица

**Яңа җыеп алынган дару чималыннан чама белән чыга торган җиңел-коры чимал проценты**

| № п/п | Үсемлекнең атамасы | Чималның төре | Җиңел-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Тәҗрибә күрсәткечләре | Әзерлекләр буенча белешмә, 1985 ел | Башка әдәби белешмәләр | Дару сәнәгате берлеге белән килештерелгән чыгыш күләме |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | Гади кылыч үлән | Тамыры | 38 ± 1 | 30 | 25 | 30 |
| 2 | Дарулык мәче борчагы | Тамырлары | - | 22 | 2 - | - |
| 3 | Тау арникасы | Чәчәкләре | - | 20-22 | - | - |
| 4 | Сазанак | Үләне | - | 32-26 | - | - |
| 5 | Кара тилебәрән | Яфраклары | - | 16-18 | 20 | - |
| 6 | Ботаклары асылынып төшкән каен (ак каен) | Бөреләре | - | 40 | 30.3 | - |
| 7 | Ком меңьяфрагы | Чәчәкләре | 46 ± 2 | 25-30 | 23-25 | 33 |
| 8 | Дүләнә | Чәчәкләре | - | 18-20 | - | - |
| 9 | -*- | Җимешләре | - | 25 | - | - |
| 10 | Нарат җиләге | Яфраклары | 56 ± 1 | 45 | - | 45 |
| 11 | Кара аю баланы | Чәчәкләре | - | 18-20 | 12.5 | - |
| 12 | Дару үләне булган песи үләне | Тамырлары | 35 ± 3 | 25 | 22 – 36 | 25 |
| 13 | Зәңгәр күкчәчәк | Кызыл чәчәкләре | - | 20 | - | - |
| 13 | Кондыз үләне (трифоль) | Яфраклары | - | - | - | - |
| 14 | Кабызлык (елан тамыры) | Тамыр сабаклары | - | 25 | 33.7 | - |
| 15 | Су борычы (су борычы) | Үләне | - | 20-22 | 25 | - |
| 16 | Бүсер үләне | Үләне | - | 20-22 | - | - |
| 17 | Биек сары чәчәк | Тамырлары белән тамыр сабаклары | 36 ± 2 | 30 | - | 30 |
| 18 | Гади имән | Кайры | - | 40 | - | - |
| 19 | Гади миңгерәткеч | Яфраклары | - | 12 – 14 | - | - |
| 20 | Гади мәтрүшкә | Үләне | - | 25 | - | - |
| 21 | Кошкунмас агач | Җимешләре | - | 17 | - | - |
| 22 | Тишек яфраклы сары мәтрүшкә | Яфраклары | - | 20 | - | - |
| 23 | Урман җир җиләге | Яфраклары | - | 20 | - | - |
| 24 | -*- | Җимешләре | - | 14-16 | - | - |
| 25 | Кече кызыл чатыр | Үләне | 35 ± 2 | 25 | 25 – 26 | 25 |
| 26 | Гади балан | Кайры | - | 40 | - | - |
| 27 | Икеөйле кычыткан | Яфраклары | 30 ± 2 | 22 | 20-25 | 22 |
| 28 | Әвернә уты | Тамыры һәм тамыр сабаклары | 32 ± 1 | - | - | - |
| 29 | Дарулык кан үләне | Тамырлары | - | 25 | - | - |

| № п/п | Үсемлекнең атамасы | Чималның төре | Җиңел-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Тәҗрибә күрсәткечләре | Әзерлекләр буенча белешмә, 1985 ел | Башка әдәби белешмәләр | Дару сәнәгате берлеге белән килештерелгән чыгыш күләме |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 30 | Мурт эт шомырты | Кайры | - | 40 | 37 | - |
| 31 | Сары чүлмәк | Тамыры | 14 – 1 | 8 – 10 | - | 11 |
| 32 | Кукуруз | Җимешлек авызчыклары белән сабаклары | - | 25 | - | - |
| 33 | Май ландышы | Яфраклары | 23 ± 1 | 20 | 20 – 23 | 20 |
| 34 | -*- | Үләне | 21 ± 0.5 | 20 | 20-23 | 20 |
| 35 | -*- | Чәчәкләре | 19 ± 1 | 14 | - | 14 |
| 36 | Калган | Тамыры | - | 28-32 | - | - |
| 37 | Кытай лимоннигы | Җимешләре | 25 + 15 | - | - | 20 |
| 38 | Йөрәксыман юкә | Чәчәкләре | 31 + 1 | 25 | 30 – 25 | 25 |
| 39 | Гади кура | Җимешләре | - | 16 – 18 | 20 | - |
| 40 | Үги ана яфрагы | Яфраклары | 18 – 1 | 15 | 19-20 | 15 |
| 41 | Гади артыш | Күркә-җиләкләре | - | 30 | - | |
| 42 | Дару тузганагы | Тамырлары | - | 33-35 | - | - |
| 43 | Соры зирек (һәм җилемле зирек) | Җимешләре (күркәләре) | - | 38 – 40 | - | - |
| 44 | Көтүче сумкасы | Үләне | - | 26-28 | - | - |
| 45 | Гади гөлбадран | Чәчәкләре | - | 25 | - | - |
| 46 | Плаун (төрле төрләре) | Споралары | - | 6-7 | - | - |
| 47 | Зур көтүче яфрагы | Яфраклары | 20 ± 1 | - | 22-23 | 15 |
| 48 | Ачы әрем | Үләне | - | 22 | - | - |
| 49 | -*- | Яфраклары | - | 24 – 25 | - | - |
| 50 | Йөрәкяфраклы арыслан койрыгы | Үләне | - | 25 | - | - |
| 51 | Дару ромашкасы | Чәчәкләре | 27 ± 1 | 20 | 20 – 27 | 20 |
| 52 | Хуш исле ромашка | Чәчәкләре | - | - | 20 | - |
| 53 | Зәңгәр күкчәчәк | Тамырлары | - | 30-32 | - | - |
| 54 | Скополия | Тамыры | 27 ± 2 | 30-32 | 30-32 | - |
| 55 | Кара карлыган | Җимешләре | - | 18-20 | - | - |
| 56 | Гади нарат | Бөреләре | - | 40 | - | - |
| 57 | Кыр каешкыраны | Тамырлары | 47 ± 1 | 30 ± 32 | 30 ± 32 | - |
| 58 | Шуышма чабыр үләне (чамбыр) | | - | 25-30 | - | - |
| 59 | Саз кипкәре | Үләне | | 23-25 | - | - |
| 60 | Гади турак уты | Яфраклары | 60 ± 3 | 50 | - | 50 |
| 61 | Гади меңьяфрак | Үләне | 0 | 22 | - | - |
| 62 | Өч чәчәкле миләүшә | Үләне | 27 ± 2 | 20 | 20-22 | 20 |
| 63 | Кыр наратбашы | Үләне | - | 25 | - | - |
| 64 | Лобель аксыргагы | Тамырлары | - | 25 | - | - |
| 65 | Өч өлешле эт тигәнәге | Үләне | 19 ± 1 | 15 | 25 | 15 |
| 66 | Гади шомырт | Җимешләре | - | 42 – 45 | - | - |
| 67 | Гади кара җиләк | Җимешләре | 16 ± 1 | 13 | 15 – 18.3 | 13 |
| 68 | Зур канлы үлән | Үләне | - | 23 – 25 | - | - |
| 69 | Май гөлҗимеше (һ.б. күп витаминлы төрләре) | Җимешләре | 46 ± 2 | 32 – 35 | 32 – 35 | 32 |

| № п/п | Үсемлекнең атамасы | Чималның төре | Җиңел-коры чимал чыгышы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Тәҗрибә күрсәткечләре | Әзерлекләр буенча белешмә, 1985 ел | Башка әдәби белешмәләр | Дару сәнәгате берлеге белән килештерелгән чыгыш күләме |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 70 | Эт гөлҗимеше (һ.б. аз витаминлы төрләре) | Җимешләре | 58 ± 3 | 32 – 35 | - | 23 |
| 71 | Кашыклы абага | Тамыры | - | 30 | - | - |
| 72 | Күлсыман эвкалипт | Яфраклары | 50 ± 3 | - | - | 43 |
| 73 | Шарсыман эвкалипт | Яфраклары | 50 ± 3 | - | - | 43 |
| 74 | Түшәлүче якорьчыклар | Үләне (тамырлары белән) | - | - | 3 - | - |

13.6 таблица

## Өстенлек итүче токым кысаларында урман типлары буенча дару үләне чималының коры запасы (коры көе кг/га)

| Дару чималының исеме | Нарат | Зирек | | Каен | | | Усак | Юкә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С яс.сн. | Зир. кр. | Д. кр. | Д ос. | С. крт. | Д пм. | С мтр. | С. крт. |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Европа таштоягы (барлык үсемлекләр) | 3.0 | - | 3.0 | - | 3.0 | - | 3.0 | 3.0 |
| Урман җир җиләге (яфраклары) | 0.2 | - | 0.2 | - | 0.2 | - | 0.2 | 0.2 |
| Дарулык песи үләне (тамыры) | - | - | - | - | - | 0.2 | - | - |
| Кашыклык абага (тамырлары) | 7 | - | 13.7 | - | 13.7 | - | 13.7 | 13.7 |
| Ике өйле кычыткан (яфраклары) | - | 3.4 | - | - | - | 13.9 | - | - |
| Кашыклык абага (тамырлары) | - | 5.2 | - | - | - | - | - | - |
| Лобель чамбыры (тамыры) | - | - | - | - | - | 3.6 | - | - |
| Мүк җиләге | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Нарат җиләге | - | - | - | 3.4 | - | - | - | - |
| Кыр наратбашы (үлән) | 0.3 | - | 0.3 | - | 0.3 | 10.5 | 0.3 | 0.3 |
| Кызыл бөрлегән (барлык үсемлекләр) | 0.4 | - | 0.4 | - | 0.4 | - | 0.4 | 0.4 |
| Гади золотарник (үләне) | 0.2 | - | 0.2 | - | 0.2 | - | 0.2 | 0.2 |
| Язгы торна борчагы (барлык үсемлекләр) | 0.9 | - | 0.9 | - | 0.9 | - | 0.9 | 0. |
| Ике яфраклы майник (барлык үсемлекләр) | 0.1 | - | 0.1 | - | 0.1 | - | 0.1 | 0.1 |
| Үпкә үләне (үләне) | 0.9 | - | 0.9 | - | 0.8 | - | 0.9 | 0.9 |
| Саз төнбоегы (үлән) | - | - | - | 8.7 | - | - | - | - |
| Карама яфраклы тубылгы (тамыры) | - | - | - | 40.2 | - | 28.9 | - | - |
| Саескан җиләге (барлык үсемлекләр) | - | - | - | 0.7 | - | - | - | - |
| Карга җиләге (үләне) | - | 0.6 | - | - | - | - | - | - |

## 2.4.3 Агач сутларын җыю

### *Каен суты*

Кайбер агач үсемлекләренең сутлары зур азык-төлек кыйммәтенә ия. Россия территориясендә каен суты киң кулланыла.

Каен суты кулланылышы буенча бик киң спектрга ия. Бу составында глюкоза һәм фруктоза, берничә минераль тоз булган күңелгә ятышлы, сафландыручы эчемлек кенә түгел, ә шулай ук азотлы катнашмалар да. Ул фитоницид үзенчәлекләренә дә ия. Сутны азык-төлек максатларында табигый һәм консервланган халәттә чөмерке һәм башка алкогольсез эчемлекләр, сироп әзерләү, десерт һәм коры шәраблар эшләү, этил спиртын алу өчен кулланалар. Каен суты шулай ук парфюмерия сәнәгатендә һәм авыл хуҗалыгында кулланыла (терлекчелектә һәм умартачылыкта). Урман химиясе сәнәгатендә каен сутын нарат чәерен тапканда сагыз чыгаручы стимуляторы, шул ук вакытта чәер чыгаручы буларак кулланалар.

Каен суты дәвалау үзлекләренә ия һәм элек-электән халык медицинасында матдәләр алмашын яхшырту өчен, зәңгеләгә каршы, сидек кудыргыч һәм гомуми ныгытучы чара буларак кулланыла. Ул организмның бүлеп чыгару функцияләрен активлаштыра, кузгалак кислотасы утыруны кисәтә.

Каен суты - каен урманнарыннан исән вакытта файдалануның югары табышлы төре. Сут алу эшләрен планлаштырганда һәм үткәргәндә сут чыгуның башлану һәм бетү вакытларын, сокның әчешү үзенчәлекләрен белергә кирәк.

Каен сутының бүленә башлавы һәм бетүе буенча теге яки бу тотрыклы вакытлары юк, алар күп факторларга бәйле, шуңа күрә сут чыга башлау фазасын агач кайрысын 1-1,5 см без белән тишеп билгелиләр. Тишелгән урыннарда сут барлыкка килгән көн сут бүленеп чыгу фазасын башлап җибәрә. Әлеге фазага 10% ким булмаган данәләр кергәндә, массакүләм сут әйләнеше 50 % булганда сут бүленә башлаган көн булып санала.

Сут әйләнеше тәмамланган көн булып агачларның якынча 50% ында сут бүленеп чыгу тәмамланган чор санала. Әчелеш башлану билгеләре – сут тоныклана, каналларда һәм сутны җыеп алу җайланмаларында ак элпә барлыкка килә. Сут йөрүнең биологик дәвамлылыгы 27 көннән 35 көнгә кадәр дәвам итә, сутны хуҗалык максатларында файдалану буенча сагыз алу чоры - сут бүленеп чыкканнан башлап әчелеш башланганчыга кадәр – уртача 15-20 көн.

Сут алуга чыгаруга сөялле, бөдрә каеннар һәм очлы яфраклы өрәңге утыртмалары җәлеп ителә ала. Яфраклы токымнарның сутын алу буенча чимал базасы I-III бонитетлы, тулылыгы 0,4 тән дә ким булмаган ревизия чорында киселергә җибәрелә торган өлгергән каен һәм өрәңге утыртмаларыннан гыйбарәт. Күкрәк биеклегендә килеш агачның диаметры кимендә 20 см булган агачлар сут алуга юнәлдерелә.

Чимал базасына түбәндәгеләр керми:

– дымлы һәм юеш урман типларында үсүче урманнар;

– зәгыйфьләнгән утыртмалар;

– төп файдалану хисабыннан чыгарылган утыртмалар;

– яшел зоналы урманнардагы утыртмалар һәм кыр саклагыч утыртмалар;

– корткычларга карата химик чаралар белән көрәш алып барылганнан соң 2 елдан азрак вакыт узган утыртмалар.

Сут алуга түбәндәгеләр җәлеп ителми:

– IV һәм V яшь классы һәм Крафт буенча үсеш агачлары;

– зәгыйфьләнгән һәм механик яктан зарарланган агачлар;

– махсус сортиментлар әзерләү өчен сайлап алынган агачлар;

– полюс утыртмалары.

Каен сутын алу вакыты – 10 елдан, өрәңгенекен 5 елдан артмаска тиеш. Алга таба II бонитет класслы чиста каен агачлыкларыннан чыга торган каен сутын хисаплау өчен норматив таблица китерелә т/га (Украина авыл хуҗалыгы академиясе).

13.7 таблица

**Каен суты чыгышы**
**(I һәм II бонитет классындагы чиста каен утыртмаларында т/га)**

| Сут алына башлаган урынның иң кечкенә уртача диаметры | Тулылыклар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1.0 | 0.9 | 0.8 | 0.7 | 0.6 | 0.5 | 0.4 |
| 20 | 45/372 | 41/335 | 37/298 | 34/261 | 31/224 | 29/187 | 27/150 |
| 22 | 35/289 | 32/260 | 29/231 | 27/202 | 25/173 | 23/144 | 22/115 |
| 24 | 25/220 | 23/193 | 22/176 | 20/154 | 18/110 | 17/88 | 17/60 |

Искәрмә: Күрсәткечләрдә бер гектарда сут алуга тиешле кәүсәләрнең минималь саны күрсәтелгән.

Каен суты запасларын билгеләүне региональ норматив-белешмә таблицаларын кулланып башкаралар. Санап чыгу таксациясе белешмәләре булган очракта каен сутының хисап чыгышын агачларның тулылык баскычлары санын бер агачтан тәүлегенә чыккан каен сутына тапкырлау юлы белән билгелиләр (Давидов, 1979).

13.8 таблица

**Бер агачтан тулылык баскычлары буенча каен суты чыгышы**
**(1 тәүлектә)**

| Тулылык баскычлары, см | 8 | 12 | 16 | 20 | 26 | 28 | 32 | 36 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Сут күләме, л | 0.60 | 1.81 | 3.25 | 4.39 | 5.90 | 6.95 | 8.55 | 9.55 |

Сут алу вакыты – 15-20 көн, язның ничек килүенә карап. Кисәргә 5-10 ел калгач сут алынмый башлый. Сут алудагы агачларның уртача күләме – 1 гектарга 200 данә. Кәүсәләр гектарына 150 данәдән кимрәк булганда каен сутын алу табышлы түгел (Каен сутын алу техникасы һәм технологиясе буенча кагыйдәләр).

## 2.5 Урманнардан аучылык хуҗалыгы алып бару һәм аучылык белән шөгыльләнү өчен рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

РФ УК 25, 36 ст. таләпләреннән чыгып билгеләнә. Аучылык хуҗалыгы урманнарны кыргый хайваннарның популяцияләре белән идарә итү һәм ел саен, шул исәптән агачлыкларның яше үзагач товарын әзерләү мөмкинлеген бирмәгән мәйданнардан продукция алу рәвешендә комплекслы файдалануга үз өлешен кертә.

### Урманнарны гражданнар тарафыннан һәвәскәр аучылык һәм спорт аучылыгы буенча РФ УК 36 ст. нигезендә файдалану

Урманнарны аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләре буларак файдалану РФ Урман кодексының 36 статьясы белән бәйле. Урман кишәрлекләре юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен башкару өчен ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турындагы федераль закон нигезендә төзелгән аучылык хуҗалыгы килешүләре һәм урман кишәрлеге арендасы шартнамәләре нигезендә бирелә.

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен башкару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турындагы федераль закон нигезендә аучылык инфраструктурасы объектларын кору рөхсәт ителә.

Гражданнар тарафыннан гомуми мөмкин булган аучылык урыннарында урманнарны файдалану урман кишәрлеген бирмичә генә башкарыла.

Аучылык "Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 24.07.2009 ел, №209-ФЗ Федераль закон нигезендә башкарыла һәм 22.05.2008 ел, № 22-ТРЗ "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" Татарстан Республикасы Законы белән урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен башкару өчен файдалану кагыйдәләре, һәм шулай ук урманнардан аучылык хуҗалыгын алып бару өчен файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары билгеләнгән. Аучылык урманнары чикләренә аларның хокукый режимы белән аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен башкаруга рөхсәт ителгән җирләр кертелә. Аучылык урманнары түбәндәгеләргә бүленә:

– 24.07.2009 ел, №209-ФЗ Федераль закон белән каралган нигезләрдә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланылучы аучылык урманнары (алга таба – беркетелгән аучылык урманнары);

– физик затлар аучылык максатларында ирекле йөрү хокукына ия булган аучылык урманнары (алга таба – гомуми мөмкин булган аучылык урманнары).

Гомуми мөмкин булган аучылык урманнары Россия Федерациясе субъектындагы (яки муниципаль берәмлектәге) аучылык урманнарының гомуми мәйданыннан кимендә егерме процентын тәшкил итәргә тиеш.

Озак вакытлы һәм гамәлдәге вакыты әле чыкмаган лицензияләре булган һәм аукционда катнашырга теләмәгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен РФ Хөкүмәте үзенең "Аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзү хокукына карата аукцион үткәрмичә генә аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзегәндә аучылык урманнары мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында"гы 30.06.2010 ел, №490 Карары белән шундый мөмкинлек тудырды.

Хайваннар дөньясындагы аучылык объектларына караучы объектларны табу вакытлары "Ау кагыйдәләрен раслау турында" 16.11.2010 ел, №512 "Ау кагыйдәләрен раслау турында" Россия ТРМ боерыгы белән билгеләнгән.

Хайваннар дөньясындагы аучылык объектларына караучы объектларны табу вакытларын Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы төзәтә ала. Язгы чорда канатлы киекләрне ату билгеләнгән ату вакыты башланганнан алып 16 көн дәвамында башкарыла.

Һәр аучылык урманын оештыру һәм үстерү буенча чараларны җентекле эшләү һәм нигезләү Аучылык урманнарыннан файдалану һәм саклау схемасын эшләү барышында башкарылырга тиеш. Аучылыктан файдаланучы хисабына әлеге эшләрне мәҗбүри үтәү "Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 24.07.2009 ел, №209-ФЗ Федераль законда каралган.

Лубян урманчылыгы шартларында аучылык һәвәскәр яки спорт холкында булырга мөмкин.

13.9 таблица

**Аучылык хуҗалыгын алып барганда һәм аучылык белән шөгыльләнгәндә урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары**

| № п/п | Чараларның төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган күләм, |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Тозлыклар урнаштыру | | |
| | - ПОШИ | данә | 12 |
| | - КУЯН | данә | 127 |
| 2 | Ашату чорында тозланган печән әзерләү | | |
| | - ПОШИ | тонна | 2 |
| | - АК КУЯН | тонна | 2 |
| 3 | Ашату мәйданнарын кору | | |
| | - КУЯН | данә | 127 |
| 4 | Җимлекләр урнаштыру | | |
| | - ПОШИ | данә | 12 |
| | - КАБАН ДУҢГЫЗЫ | данә | 4 |
| 5 | Чуер ташлык кору | данә | 39 |
| 6 | Ашату кырлары булдыру | | |
| | - КАБАН ДУҢГЫЗЫ | га | - |
| 7 | Ашату өчен усак кисү | данә | 138 |

Урманчы 13.9 таблицада күрсәтелгән чараларны үтәү өчен башкаручыларны билгели.

13.10 таблица

**Ау хайваннарын ату нормалары**

| № п/п | Аучылык ресурслары төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган ау табышы |
|---|---|---|---|
| 1 | Поши | данә | күзге хисап санынннан 10-15% |
| 2 | Кабан дуңгызы | -*- | көзге хисап санынннан 10-20% |
| 3 | Аю | -*- | Гомуми санынннан 10 % кадәр |
| 4 | Кондыз | -*- | Гомуми санынннан 10 % кадәр |
| 5 | Төлке | -*- | көзге хисап санынннан 30-40% |
| 6 | Ак куян | -*- | көзге хисап санынннан 30-50% |
| 7 | Чәшке | -*- | көзге хисап санынннан 20-25% |
| 8 | Сусар | -*- | көзге хисап санынннан 20-25% |
| 9 | Суер | -*- | язын сайраучы ата кошлардан 15 -20% |
| 10 | Көртлек | -*- | язын сайраучы ата кошлардан 20% |
| 11 | Божыр | -*- | көзге баш исәбеннән 15% |
| 12 | Саз киекләре | -*- | җәйге-көзге хисап санынннан 30-50% |
| 13 | Суда йөзүче киекләр | -*- | җәйге-көзге хисап санынннан 30-50% |
| 14 | Кырдагы канатлы киекләр | -*- | Җирле үрдәкләр җәйге-көзге санынннан 40% кадәр |

Хуҗалыкта ау хайваннарын ату нормаларын проектлаганда урманчы мәҗбүри тәртиптә аларның саны һәр елның ау хайваннарының үрчем (үсү) интенсивлыгын билгеләүче шартларына бәйле булуын һәм хуҗалыкның киекләрнең санын арттыруга, саклауга яки киметүгә корылган булуын исәпкә алырга тиеш.

Лубян урманчылыгы территориясендә аучылык урманнарының 6 тибы бар:

Ылыслы урман. Урманнарның әлеге тибына төрле яшьтәге ылыслы утыртмалар кертелә. Ылыслы урман аучылык фаунасына бай түгел. Биредә поши, төлке, тиен, сусар, сирәгрәк кабан очрый. Кырларга тоташучы яшь нарат агачлыкларында гадәттә куян йөри.

Яфраклы урман. Әлеге урман тибына чиста яфраклы утыртмалар кертелә. Яфраклы урманнарда поши, кабан, төлке, куян өчен шартлар уңайлы.

Катнаш урман. Монда төрле яшьтәге ылыслы-яфраклы утыртмалар кертелгән. Әлеге тип күпчелек хайваннар өчен иң яхшы туклану, саклау үзлекләренә ия.

Сөрүлекләр Әлеге типка чәчү һәм авыл хуҗалыгы культураларын утырту өчен кулланыла торган кишәрлекләр кертелә. Биредә гадәттә куян яши.

Болын. Бу төп үсемлекләре табигый һәм чәчелгән үләннәрдән торучы урыннар. Бирегә шулай ук агачсыз урыннар, агач киселгән урыннар һәм тапталмаган урман культуралары карый. Болыннарның аучылык фаунасы аларның сазлы булу-булмавына бәйле. Коры далаларда ул ак куян, сазланган җирләрдә – тартар, чуллык, урман үрдәге һәм башка шөлдиләр белән гыйбарәт.

Биредә еш кына үрдәкләр оя кора. Агачсыз урыннарда һәм агач киселгән җирләрдә еш кына пошилар очрый.

Саз. Монда үтеп була торган һәм түбән урыннардагы сазлар, елгалар кертелә. Әлеге урыннарның үсемчелеге гадәттә шикәр камышы, төрле кыяклылар, моннан тыш күпчелек сазлар өчен тал куаклары һ.б. белән характерлы.

Аерым бер аучылык урманында, егерь әйләнеп уза торган урыннардагы, табигый ызаннардагы тиреәлек итү шартларының гомуми сыйфат бәяләмәсен бонитировка дип атыйлар.

Бонитет хайваннарның теләсә кайсы бер төренең тереклек итү шартларына суммар бәя бирә. Бонитет классы табигый һәм икътисади шартлар комплексының аучылык урманнары алдында куелган бурычларга нинди күләмдә җавап бирүе турында сөйли. Аның күрсәткече булып урманнардагы җитештерүчәнлек, ягъни 1000 гектарлы мәйданда хайваннар һәм кошлар күләме тора.

Урманнарның оптималь яки хуҗалык-мөмкин булган сыешлыгы һәм хайваннарның оптималь тыгызлы билгеләнгән.

13.11 таблица

**Аучылык җирләрен бонитетлар буенча бүлү**

| № п/п | Аучылык фаунасы төрләре | Уртачалан дырылган бонитет | Урманнарның мәйданы, га | Факттагы баш саны, данә | Оптималь сыешлык (1000 гектарга баш саны), данә | 1000 гектарга оптималь баш тыгызлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Поши | III | 27.0 | 74 | 81 | 3 |
| 2 | Кабан дуңгызы | III | 27.0 | 9 | 54 | 2 |
| 3 | Кыр кәҗәсе | III | 27.0 | | 135 | |
| 4 | Төлке | III | 27.0 | 148 | 135 | 5 |
| 5 | Ак куян | III | 27.0 | 545 | 2160 | 80 |
| 6 | Сусар | III | 27.0 | 45 | 540 | 20 |
| 7 | Тиен | III | 27.0 | 35 | 540 | 20 |
| 8 | Божыр | III | 27.0 | 100 | 540 | 20 |
| 9 | Үрдәкләр | III | 0.1 | 1280 | 20 | 20 |

***Үткәрүчәнлек үзенчәлеге***

Лубян урманчылыгы территориясендә ау вакытлары һәм кагыйдәләре "Татарстан Республикасы территориясендә ау кагыйдәләре" белән билгеләнгән.

Аучылык фаунасын эксплуатацияләү методлары буенча төзүгә түбәндәгеләр нигез булып хезмәт итә: аучылык урманнарының җитештерүчәнлеге, ау хайваннарының саны, популяцияләрнең үсү темплары, төрләр буенча сезонлы һәм еллык ату нормалары, ау сезоннарының дәвамлылыгы.

Аучылык хуҗалыгының үткәрүчәнлек үзенчәлеге территориаль һәм фактикка бүленә.

Хуҗалык территориясендә урманнардан рациональ файдалану принципларын һәм ау буенча иминлек кагыйдәләрен бозмыйча ау белән шөгыльләнә ала торган аучыларның санын билгеләү өчен территориаль үткәрүчәнлек мөмкинлеге (ТҮМ) исәпләнгән, ягъни ул киекләрнең санына карамыйча ТҮМ хуҗалыгын кабул итәргә мөмкин булган аучыларның максималь санын күрсәтә һәм ул саны арттырылу хисабына югарырак була алмый. Төрле ау төрләрен бер тапкыр үткәргәндә аларның үткәрүчәнлек мөмкинлеген максималь мөмкин булганны үтеп китмәслек итеп суммаларга кирәк. Моннан тыш, яраклы урманнарның барча территориясендә бер тапкыр ауга чыгу киекнең тереклек итү шартларына начар йогынты ясый, ул хуҗалык чикләренә качып китәргә мөмкин.

## 2.6 Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану алар урнашкан җирләрнең билгеләнешенә бәйле рәвештә, урман фонды җирләрендә ул урман хуҗалыгы мәнфәгатьләре туры килгәндә генә рөхсәт ителә һәм РФ УК 38 статьясы белән регламентлана, шул ук вакытта, авыл хуҗалыгы җитештерүе дип авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлек үстерү генә түгел, аны җитештерү, эшкәртү буенча икътисади эшчәнлек төрләре җыелмасы да санала. (29.12.2006 ел, №264-ФЗ “Авыл хуҗалыгын үстерү турында” ФЗ, 4 ст.).

Авыл хуҗалыгы җитештерүенә гадәттә авыл хуҗалыгы чималын беренчел эшкәртү генә кертелә. Сәнәгать эшкәртүе авыл хуҗалыгы җитештерүе дип саналмый.

Шул максатта РФ УК 38 статьясындагы 2 өлеше белән авыл хуҗалыгы алып бару өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә бары тик вакытлы корылмалар (умарталыклар, киртәләр, әвеслекләр һ.б.ш.) төзү генә рөхсәт ителә.

Әлеге норма авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен сәнәгать эшкәртүен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми, еш кына хәтта беренчел эшкәртергә дә.

Капиталь төзелеш объектларын төзергә кирәк булганда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә урманнардан авыл хуҗалыгы максатлары өчен файдалану гына түгел, урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану да таләп ителә (РФ УК 46 ст.).

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдаланганда алынган продукция бер үк вакытта урман ресурсы булып та саналырга мөмкин.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану Лубян урманчылыгында түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

– гражданнар, шул исәптән әйдәүче крестьян (фермер) хуҗалыклары, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче шәхси ярдәмче хуҗалыклар;

– хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, җитештерү кооперативлары, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, бүтән коммерция оешмалары;

– коммерцияле булмаган оешмалар, шул исәптән кулланучылар кооперативлары, дини оешмалар.

Билгеләнгән тәртиптә авыл хуҗалыгын алып бару өчен урман кишәрлекләре даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, арендага яки түләүсез билгеле бер вакытка бирелә торган файдалануга тапшырылырга мөмкин. Мондый урман кишәрлекләренә сервитутлар йөкләнергә мөмкин.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре “Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 05.12.2011 ел, №509 Россиянең Рослесхоз боерыгы белән билгеләнә.

Әлеге Кагыйдәләрдә авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануның теләсә кайсы төренә кагыла торган гомуми нигезләмәләр һәм урманнарда алып барыла торган авыл хуҗалыгы эшчәнлегенең аерым төрләрен билгеләүче махсус таләпләр бар.

### 2.6.1 Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары

Яшел зоналарда авыл хуҗалыгын алып бару тыела. РФ Урман кодексының 11 статьясының 1 өлеше нигезендә авыл хуҗалыгын алып бару гражданнарның урманнарда ирекле һәм бушлай йөрү хокукын чикләргә тиеш түгел.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан рөхсәтле файдалануның төп параметрлары 14 таблицада китерелә.

14 таблица

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары

| № п/п | Файдалану төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен мөмкин булган күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | Сөрүлекләрне файдалану | га | - |
| 2 | Печән чабу | га/тонна | 199/160 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү | | |
| | а) урманда | га/ баш | 1200/50 |
| | б) утлавыкларда, көтүлекләрдә | га/ баш | 72/100 |
| 4 | Умартачылык | | |
| | а) бал бирүчеләр: | | - |
| | -юкә | га | 530 |
| | -үләннәр | га | 77 |
| | б) бал продуктлылыгы: | | - |
| | -юкә | кг/га | 50 |
| | -үләннәр | кг/га | 25 |
| | в) умарта оялары күләмен тәэмин итү мөмкинлеге | умарта гаиләләренең күләме | 220 |
| 5 | Себер боланчылыгы | га/ баш | - |
| 6 | Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү | га | - |
| 7. | Бүтән авыл хуҗалыгы эшчәнлеге | | - |

## 2.6.2 Авыл хуҗалыгы, печән чабу, авыл хуҗалыгы терлеген көтү, умартачылык мөмкин булган авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданнары турында белешмәләр

***Печән чабу***

Печәнлекләрне классификацияләгәндә түбәндәгеләр билгеләнә: печәнлекләрнең тибы (су баса торган, коры җирдәге, сазланган), табигыймы ул яисә яхшыртылганмы, агач-куаклар басып китү дәрәҗәсе, печән әзерләүне кыенлаштыра торган факторлар, үләннең төп төрләре, аның каплап кителеш дәрәҗәсе, куелыгы, уңышы, сыйфаты. Печәнлекләр мәйданының 20%ын агач-куаклар басып алган булса, ул агач-куак басып киткән дип санала, 20%тан артыгын түмгәкләр каплаган булса – түмгәкле дип, яхшыртылган печәнлекләр дип – табигый һәм чәчелгән үләннәр каплап алган булса, анда механика кертеп була.

Печән уңышын бәяләү: 10 ц/га һәм аннан да күбрәк – яхшы, 6-9 ц/га – уртача, 1-5 ц/га – начар.

***Печән чабу җирләрен бәяләү***

Печәнлекләр өчен түбәндәгеләр кулланыла:

– урман утыртылмаган диләнкеләр, ачыклыклар һәм урман җире капламаган һәм урман культуралары утыртып, урманнарны торгызу мөмкин булмаган җирләр;

– яхшыртуга мохтаҗ, печән чабу өчен яраклы җирләр;

– реконструкция өчен билгеләнмәгән кыйммәте аз булган урман үсентеләре кишәрлекләре.

14.1 таблица

**Печән чабу җирләренең сыйфатламасы**

| Печән чабу тибы | Урнашкан урыны | Үлән капламы | Печән чабу тибының сыйфаты |
|---|---|---|---|
| Вакытлыча дымы артып киткән коры җирләр | Сизелер-сизелмәс субүлү урыннары | Карчыга үләне, тубылгы, гравилат, тузгак кылган, башаклы үлән, түмәрлек, эт үләне, бөтнек | Уртача |
| Коры үзәнле. үзәнлекле - ерганаклы | Кече елга үзәннәре, үлән баскан тар яр сөзәкләре һәм төбе тигез булмаган уйсулыклар | Тимофеевка, солыча, кылчыклы үлән, төлке койрыгы, бөтнек | Яхшы |
| Түбән уртача-артык дымланган | Киң үзән булдыручы түбәнлекләр | Бөртекләләр, башаклы үлән, кузаклылар | Уртача |
| Сазланган иңкүлекләр | Грунт сулары якын булган сазланган түбәнлекләр | Дым яратучы бөртекләләр, эре башаклы үлән | Начар |

## Урманнарны авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү өчен файдалану

***Терлек көтү җирләрен исәпкә алу***

Су саклау зоналарында, табигый һәм бүтән объектларны саклау функциясен башкаручы, кыйммәтле урманнардан һәм МСК кала,

урманчылыкның барлык урманнарында көтү көтәргә ярый. Урманнарда кәҗәләрне көтү тыела.

Терлек көтү түбәндәге урыннарда рөхсәт ителми:

– очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м) урман культуралары кишәрлекләрендә;

– урман орлыкларын үстерү, чыршы, тал, тирәк һәм чикләвек плантацияләрендә;

– табигый торгызуга ярдәм итү чаралары уздырыла торган кишәрлекләрдә;

– очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м.) яшь урман утыртмаларында;

– ылыслы һәм каты яфраклы токымнарны торгызу өчен билгеләнгән, урман утыртмалары белән капланмаган җирләрдә;

– су һәм җир эрозиясе белән зарарлаган җирләрдә.

***Көтүлекләрнең категорияләре һәм аларның азык продуктлылыгы***

Көтүлекләрне төрләргә бүлгәндә проект капланышын, үләннең төп төрләрен, аның куелыгын, асылда нинди үләннәрдән торуын, аларның сыйфатын региональ шкалалар кулланып күрсәтәләр. Алар булмаганда түбәндәгеләрне кулланырга мөмкин:

– яхшы җирләр – яхшыртылган һәм су баса торган, кузаклы-бөртеклеләр өстенлек итә торган (60% һәм аннан да күбрәк) кишәрлекләр; үләннең проект капламы – 60% һәм аннан да күбрәк);

– начар җирләр – табигый һәм каты үләннәр басып алган (60% аннан да күбрәк) (эре башаклы үлән, камышлык, ситник); башка үләннәрнең проект капламы 50%ка кадәр.

14.2 таблица

**1 баш терлеккә якынча сезонлы көтү нормалары, га**

| | |
|---|---|
| 0.5 – 0.6 тулылыктагы каен өстенлек итә торган яфраклы урманнар | 2 |
| 0.5 тулылыктагы саф каенлыклар | 1.5 |
| Көтүлек өчен яраклы башка урман үсентеләре (1 башмөгезле эре терлеккә яисә 7 сарыкка) | 4 – 5 |
| Куаклардан һәм шытып чыккан урман үсентеләре булмаган киселгән урыннарда | 0.75 |

14.3 таблица

**Көтү өчен кулланылучы төп урман типларының терлек азыгы продуктлылыгы**

| Урман типлары төркемнәре | Уңдырыш, ц/га | | Утлавыкта ашала торган терлек азыгы күләме, ц/га | Терлек азыгы берәмлеге запасы | 1 шартлы баш мөгезле эре терлекне гектарда көтү нормасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Коры авырлыкта | Яшел массада | | | |
| Сәрдәле коры | 6 – 12 | 15 – 31 | 8 – 16 | 150 – 300 | 6.9 – 3.4 |
| Сәрдәле яңа | 9 – 19 | 30 – 66 | 15 – 33 | 280 – 620 | 3.7 – 1.7 |
| Кымызлыклы | 7 – 9 | 23 – 30 | 12 – 15 | 230 – 280 | 4.6 – 3.7 |
| Яшел мүкле | 7 – 10 | 23 – 33 | 12 – 17 | 230 – 320 | 4.6 – 3.2 |

***Умартачылык***

Бал бирүче үсемлекләр

1000 артык төре булган күпсанлы чәчәк үсемлекләреннән бал кортлары чәчәк нектары һәм серкәсе җыя. Шуларның берсе – беренче дәрәҗәдә бал бирүчеләр, башкалары – икенче дәрәҗәдә бал бирүчеләр. Алга таба аеруча киң таралган бал бирүче үсемлекләр тасвирламасы китерелә.

14.4 таблица

**Бал бирүче үсемлекләрнең бал продуктлылыгы**

| Бал бирүчеләр | Чәчәк атуның уртача вакытлары | | Бал продуктлылыгы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | Башы (дата) | Продуктлылыгы (көн) | |
| Үги ана яфрагы | 12.04 | 30-60 | П* |
| Чикләвек куагы | 20.04 | 6-9 | П* |
| Йолдыз чәчәк | 20.04 | 30 | П* |
| Кызыл тал | 22.04 | 5-30 | 150 |
| Баллыкый (даруханә) | 23.04 | 30 | П* |
| Кәҗә талы | 28.04 | 10 | 150 |
| Бүре җиләге | 30.04 | 15 | П* |
| Үрмәләк үлән | апрель | 90 | П* |
| Үткен яфраклы чаган | 08.05 | 7-10 | 200 |
| Мурт тал | 10.05 | 5-10 | 150 |
| Ак тал | 11.05 | 15-20 | 150 |
| Карлыган | 20.05 | 10-20 | 50-140 |
| Шомырт | 21.05 | 12 | П* |
| Сукыр кычыткан | 24.05 | 45 | 100 |
| Чия | 23.05 | 10-12 | 30-40 |
| Сары акация | 25.05 | 10-14 | 350 |
| Алмагач | 26.05 | 10-12 | 20-30 |
| Дүләнә | май | 15 | П* |
| Нарат җиләге | -"- | 30 | " |
| Татар өрәңгесе | май | 7-10 | 100 |
| Миләш | -"- | 10 | 30-40 |
| Күгән | -"- | 15 | 25 |
| Зелпе | май-июнь | 20 | П* |
| Гади чамбыр | -"- | 34 | 140 |
| Кара җиләк | -"- | 30 | 30 |
| Кыр шалфейе | май | 30-60 | 110 |
| Мурт эт шомырты | 06.06 | 14 | 35 |
| Балан | 11.06 | 30-45 | П* |
| Урман курасы | 15.06 | 25-40 | 60-100 |
| Кырлыган | 22.06 | 45-60 | 350-400 |
| Киңяфраклы юкә | 23.06 | 14 | 500-600 |
| Ак ике еллык кандала үләне | 25.06 | 30 | 200-300 |
| Җир җиләге | июнь | 20 | 10 |
| Тычкан борчагы | июнь-июль | 30-40 | 180-370 |
| Дарулык шалфей | -"- | 47 | 117-133 |
| Сары кандала үләне | -"- | 30-40 | 150-200 |
| Болын тукранбашы | -"- | -"- | 80 |
| Кызыл тукранбаш | -"- | 30 | 200 |
| Ак акация | 03.07 | 10 | 400 |
| Арчан | 24.07 | 30-40 | 200 |

Искәрмә: П* - табышны тотып торучы тип билгеләнгән.

14.5 таблица

**Юкә чәчәк атканда саф юкәлекләрдә җыеп алырга мөмкин булган бал, кг/га ( гомуми бал продуктлылыгыннан 30%)**

| Яше, ел | I – II бонитет | | III бонитет | | IV – V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тулылыгы | | | | | |
| | 0.3 – 0.5 | 0.6 – 1.0 | 0.3 – 0.5 | 0.6 – 1.0 | 0.3 – 0.5 | 0.6 – 1.0 |
| 20 | 29 | 32 | 22 | 25 | 11 | 14 |
| 30 | 115 | 137 | 86 | 104 | 65 | 76 |
| 40 | 155 | 187 | 133 | 162 | 104 | 126 |
| 50 | 190 | 223 | 169 | 198 | 137 | 162 |
| 60 | 216 | 248 | 198 | 227 | 166 | 191 |
| 70 | 227 | 270 | 205 | 245 | 184 | 216 |
| 80 | 227 | 270 | 216 | 259 | 194 | 230 |
| 90 | 205 | 248 | 209 | 252 | 187 | 223 |
| 100 | 198 | 230 | 198 | 230 | 173 | 198 |
| 110 | 176 | 209 | 173 | 205 | 137 | 166 |
| 120 | 162 | 190 | 155 | 184 | 115 | 137 |
| 130 | 140 | 165 | 133 | 155 | 97 | 115 |
| 140 | 126 | 148 | 112 | 133 | 83 | 97 |
| 150 | 108 | 130 | 94 | 115 | 68 | 83 |

**Башка токым утыртмаларындагы юкәлекләрнең һәм юкәнең бал продуктлылыгы**

14.6 таблица

Нормаль юкәлекләрнең продуктлылыгы (Мурахтанов буенча)

| Яше | Утыртмаларның тулылыгы | | |
|---|---|---|---|
| | 1.0 – 0.8 | 0.7 – 0.6 | 0.5 – 0.3 |
| 20 | 6.45 | 6.24 | 5.04 |
| 30 | 28.12 | 27.73 | 22.87 |
| 40 | 43.35 | 42.49 | 35.32 |
| 50 | 53.09 | 52.04 | 42.98 |
| 60 | 61.52 | 60.25 | 49.93 |
| 70 | 66.44 | 65.14 | 54.03 |
| 80 | 67.65 | 67.25 | 56.05 |
| 90 | 67.29 | 65.96 | 54.50 |
| 100 | 62.11 | 60.65 | 50.57 |
| 110 | 55.49 | 54.24 | 45.13 |
| 120 | 48.72 | 47.71 | 39.57 |
| 130 | 41.30 | 40.43 | 33.67 |
| 140 | 35.18 | 34.47 | 28.63 |
| 150 | 30.08 | 29.34 | 24.46 |

Төрле утыртмалар составындагы юкәнең бал продуктлылыгын хисаплау буенча түбәндәге формула тәкъдим ителә:

$M = N \times 0.1K \times C \times S$, биредә

M – кишәрлектә юкәнең бал продуктлылыгы;

N – 1 гектарга карата бал продуктлылыгы (табл.);

К – утыртма составындагы юкә коэффициенты;

С – юкәнең чәчәк ату озынлыгы, көннәр (14 көнгә тигез кабул ителә);

S – бүлемтек мәйданы.

Гомуми мөмкин булган нектар запасын билгеләгәндә бал кортлары нектарның 30%ын гына җыйганнарын исәпкә алырга кирәк.

Тагын шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, районнардагы умарталыкларда нектар пробаларын алудан һәм үсемлекләрнең һәм умартачылык җирләренең бал продуктлылыгын билгеләүдән гыйбарәт булган бал продуктлылыгын исәпләүләр – бик күп хезмәт таләп итә һәм бары тик фәнни хезмәткәрләр яисә шушы максатлар өчен әзерләнгән эзләнү экспедицияләре белгечләре тарафыннан гына башкарылырга тиеш.

## Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен урманныкы булмаган җирләр, шулай ук урман утыртылмаган диләнкеләр, ачыклыклар һәм урмансыз һәм аларда урманнарны торгызганчы билгеләнгән җирләр кулланыла.

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен кулланыла торган урман кишәрлекләрендә химик һәм биологик препаратлар “Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында” 19.07.1997 ел, №109-ФЗ Федераль закон нигезендә кулланыла.

Әлеге өлештә авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануның инде булган хокукый җайга салынышына авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затларга түбәндәге бурычлар йөкләнү турындагы нормалар өстәлә:

– гражданнарның сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зарар китерүгә юл куймаска;

– урманнардан файдаланганда туфрак эрозиясен булдырмаска, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, һәм шулай ук су объектларына һәм башка табигый объектларга тискәре йогынтыны булдырмаска яисә чикләргә;

## 2.7 Урманнардан фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге башкару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Лубян урманчылыгы урманнары фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары тарафыннан фәнни-тикшеренү, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча файдаланылырга мөмкин.

Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, башка фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына – арендага бирелә (Урман кодексы, 40 ст., 2007 ел).

## 2.8 Урманнардан рекреация эшчәнлеге башкару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

***Рекреация эшчәнлеге***

Рекреация эшчәнлеген РФ УК белән кешеләрнең ялын, туризмны, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыруга кагылышлы эшчәнлек буларак карала.

Урманнардан мондый файдалану (РФ УК 41 ст.) урман кишәрлекләре бирүне таләп итә, әмма урман ресурсларын җыймауны күз алдында тота торган эшчәнлек төренә кертелә, бирелгән урман кишәрлекләрендә кирәкле урман инфраструктурасы, шул исәптән вакытлы корылмалар булдырыла, территория төзекләндерелә (РФ УК 41, 13 ст.).

Шулай ук физик культура-савыктыру, спорт һәм спорт-техник корылмаларны төзү рөхсәт ителә, әгәр дә анысы Татарстан Республикасының урман планында каралган булса.

Рекреация эшчәнлеген оештыру үзенчәлекләре 21.02.2012 ел, №62 Рослесхоз боерыгы белән расланган Рекреация эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрендә бәян ителә.

### 2.8.1 Урманнарны рекреация эшчәнлеген башкару өчен куллану нормативлары

РФ УК 11 статьясы гражданнарның урманнарда ирекле һәм бушлай йөрү хокукын гарантияли.

РФ УК 41 ст. 3 өлеше табигый ландшафтларны, хайваннар дөньясы объектларын, су объектларын саклауны таләп итә, шуңа күрә актив ял зоналарын бүлеп чыгарганда һәм саклаганда рекреация басымнарын белү таләп ителә. Әлеге максатларда рекреация дигрессиясе стадияләре һәм кишәрлекнең рекреация билгесе шкаласы кулланыла.

14.7 таблица

**Урман тирәлеге дигрессиясе шкаласы ("Леспроект" ВО күрсәткечләре буенча)**

| Кишәрлекнең сыйфатламасы | Дигрессия классы |
|---|---|
| Урман тирәлеге бозылу билгеләре юк, агачлар һәм куаклар нормаль үсештә, механик зарарлаулар күзәтелми, яшь агач һәм куаклар тереклек итүгә сәләтле, мүк һәм үлән капламы әлеге урман тибы өчен характерлы, түшәмәсе пружиналы һәм бозылмаган. Рекреацияне җайга салу таләп ителми. | I |
| Урман тирәлеге сизелер-сизелмәс үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше начарайган, аларда берән-сәрән механик бозылулар бар; шытып чыкканнары һәм куаклары (төрле яшьтәге) яшәрлек, уртача куелыкта, 20%ка кадәр зарарланган һәм кипкән нөсхәләр бар. Мүк белән капланышы мәйданының 20%ына кадәр, үлән капламы – 50% кадәр, аяк асты урман япмасы бераз бозылган, туфрак һәм аяк асты урман япмасы тыгызланган, агачларның аерым тамырлары шәрәләнгән, туфракның 5%ка кадәр мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреацияне зур булмаган күләмдә көйләү таләп ителә. | II |
| Урман тирәлеге шактый үзгәргән һәм агачлар һәм куакларүсеше зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 10 % ка кадәр механикзарарланган; шытымнар һәм куаклар зәгыйфьләнгән, уртача куелыкта яисә сирәк ( зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр – 21-50 %). Аяк асты түшәмәсе һәм туфрак сизелерлек тыгызланган, шәрәләнгән агачлар бик күп. Туфракның минераль өлешенә кадәр мәйданының 40 % ы тапталган. Рекреацияне зур күләмдә көйләү таләп ителә. | III |
| Урман тирәлеге нык бозылган, агачлыкары куртиналы типта, агачлары сизелерлек зәгыйфьләнгән. Кәүсәләрнең 11-20%ы механик зарарланган, яшь агачлары һәм куаклары тереклек итүгә яраклы (нигездә куртиналарда сакланган), сирәк яки юк, нөсхәләрнең 50%ыннан артыгы зарарланган һәм кипкән. Мүкләр юк. Үләннең проект капламы 40-60%. Шәрәләнгән агач төпләре күп. Ачык урыннарда аяк асты урман япмасы бөтенләй юк, туфракның 40-60 % мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреациянең катгый режимы таләп ителә. | IV |
| Урман тирәлеге деградацияләнгән, агачлыклары сирәкләнгән, куртиналы типта, агачлары нык зәгыйфьләнгән яки кибеп бара, 20%ыннан артыгы механик зарарланган. Яшь агачлар, куаклар, мүкләр, түшәмәләр юк. Күп кенә агачларның тамырлары шәрә һәм зарарланган, туфракның 60%ыннан артык мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация рөхсәт ителми. | V |

**Кишәрлекнең рекреация билгесе шкаласы ("Леспроект" БО күрсәткечләре буенча)**

| Кишәрлекнең сыйфатламасы | Балл |
|---|---|
| Агач-куак үсемчелеге, туфрак өстендәге капламының һәм башка элементларының торышы буенча кишәрлек иң яхшы күрсәткечләргә ия. Барлык юнәлешләрдә дә хәрәкәт итү уңайлы. Территорияләрне тышкы төзекләндерүләрсез генә ял итү өчен файдаланырга мөмкин. | I |
| Агач-куак үсемчелеге, туфрак өстендәге капламының торышы буенча кишәрлек иң яхшы күрсәткечләргә ия. Кайбер юнәлешләрдә хәрәкәт итү чикле. Территорияләрне азрак күләмдә тышкы төзекләндерүләрдән соң ял итү өчен файдаланырга мөмкин. | II |
| Агач-куак үсемчелеге, туфрак өстендәге капламының һәм башка элементларының торышы буенча кишәрлек начар күрсәткечләргә күбрәк ия. Барлык юнәлешләрдә дә хәрәкәт итү авырлаштырылган. Ялны оештыру өчен территорияләрне тышкы төзекләндерү буенча зур чыгымнар таләп ителүче чараларны үткәрергә кирәк. | III |

Таксация барышында шулай ук ландшафт типлары, эстетик бәя, биологик тотрыклылык һәм кишәрлекнең үткәрүчәнлеге билгеләнә.

Мөмкин булган рекреация басымнарын системалы контрольдә тоту мөһим һәм, алар арткан һәм аларны киметү мөмкин булмаган очракларда, ял

итүчеләрне тарату өчен "игътибарны читкә юнәлтә торган объектлар" (җирле истәлекле урыннар, яңа сулыклар, күренекле нокталар, дендрология бакчалары һ.б.) булдыру таләп ителә. Массакүләм ял итүне оештыру өчен урыннарны рекреация басымнарына нык тотрыклы булган утыртмалардан сайлап алырга, ә аз тотрыклы булганнарны кешеләр күпләп килүдән, аларны йөреп керү юллары һәм туристлык маршрутлары буенча трассировкалаганда урап узып, аларның чикләренә керү юлын шлагбаум һәм кисәтүле аншлаглар яки куе тере читәннәр белән ябып, локальләштерергә кирәк. Җиңел комлы туфраклар буйлап салынган йөреп керә торган юллар һәм сукмаклар каты каплам яки агач түшәмәләре белән капланырга тиеш. Массакүләм ял итү урыннарын урнаштыру пунктларын ачыклап, 5-7 елдан соң аларның күрсәтелгән вакыт дәвамында элегрәк урнашкан урыннарын урман табигый комплексын торгызу өчен территориаль яктан үзгәртү мөмкинлеген күздә тотарга кирәк.

Рекреация урманнарында түбәндәге туфрак-мелиоратив чаралар проектлана: ашлама кертү, известьлау, мульчалау, көпшәкләндерү, киртәләү; Моннан тыш, алда бәян ителгәннәр белән берлектә, 30.05.88 ел, РСФСР Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган "РСФСРның Европа өлешендәге шәһәрләр һәм башка торак пунктлар тирәләрендәге яшел зоналарның урман-парк өлешләрендә хуҗалык алып бару буенча күрсәтмәләр"гә, һәм шулай ук РФ Югары Советы тарафыннан кабул ителгән "Әйләнә-тирә табигый тирәлекне саклау турында" 19.12.1991 ел, №2060-1 РСФСР Законына һәм 2001 елдагы "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" Федераль законга таянырга кирәк.

14.8 таблица

**Яшел зона урманнарындагы территорияләрне тышкы төзекләндерү нормалары**
**(гомуми мәйданның 100 гектарында)**

| п/п | Тышкы төзекләндерү элементлары исеме | Яшел зона | | Алар чикләрендә туристлык маршрутлары (1 км маршрутка), |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ялныкы | Йөреп керә торган | |
| 1 | Гравийлы килү юллары хәрәкәт итү өлеше 4,5 м (км) киңлектә булган | 0,15 | 0,02 | - |
| 2 | Массивлар эчендәге гравийлы юллар тасма киңлеге 3 м (км) булган | 1,8 | 0,5 | - |
| 3 | 15 машинага исәпләнгән автотукталышлар гравий һәм вак ташлы (данә) | 0,25 | 0,03 | - |
| 4 | Йөреп керү сукмаклары (км) | - | 0,04 | - |
| 5 | 4 урынлы утыргычлар (данә) | 18 | 3 | 1 |

| п/п | Тышкы төзекләндерү элементлары исеме | Яшел зона | | Алар чикләрендә туристлык маршрутлары (1 км маршрутка), |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ялныкы | Йөреп керә торган | |
| 6 | 6 урынлы ашап алу өстәлләре (данә) | 7 | 0,6 | - |
| 7 | Яңгырдан ышыклану урыннары (данә) | 1,5 | 0,2 | 0,2 |
| 8 | Азык әзерләү учаклары (данә) | 3,5 | 0,5 | 0,6 |
| 9 | Чүп савытлары (данә) | 30 | - | - |
| 10 | Чүп җыйгычлар (данә) | 3,5 | - | - |
| 11 | Бәдрәфләр (данә) | 0,18 | - | - |
| 12 | Спорт һәм уен мәйданчыклары, м3. | 37 | - | 5 |
| 13 | Елгалардагы һәм сулыклардагы кызыну урыннары, м2 | 90 | 15 | - |
| 14 | Кызыну урыннарындагы кабиналар (данә) | 0,18 | 0,02 | - |
| 15 | Беседкалар (данә) | 0,17 | - | - |
| 16 | Күрсәткечләр (данә) | 1,5 | 0,2 | 0,4 |
| 17 | Күренекле нокталар (данә) | 0,7 | 0,1 | 0,3 |
| 18 | Коелар һәм чишмәләр (данә) | 0,02 | 0,01 | 0,1 |
| 19 | Туристларга палатка кору өчен мәйданнар, м2 | 50 | - | 20 |

14.9 таблица

## Яшел зона урманнарындада урманнардан файдалануның төп хуҗалык чаралары һәм төрләре

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ялныкы | Йөреп керә торган | Фауна тынычлыгыныкы |
| ***1. Урман хуҗалыгы чаралары*** | | | | |

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ялныкы | Йөреп керә торган | Фауна тынычлыгыныкы |
| 1 | Урманнарны карап тотканда түбәндәге максатларда кисү: | | | |
| - | Ландшафтларны формалаштыру | + | + | - |
| - | Аз кыйммәтле үсемлекләрне алып ташлау | + | + | + |
| - | Табигый торгызылуга ярдәм итү | + | + | + |
| - | Үрентене карап тоту | + | + | + |
| - | Бар булган һәм булдырылган урман ландшафтларын карап тоту | + | + | + |
| - | Утыртмаларны үзгәртеп кору һәм яңарту | + | + | - |
| 2 | Реконструкция кисүләре | + | + | - |
| 3 | Башка кисүләр түбәндәге максатларда: | | | |
| - | Ачык ландшафтлар булдыру, ерактан күренешләрне чистарту | + | - | - |
| - | Күренекле нокталарда рекреация карамагыннан кимчелекле үсемлекләрне алып ату | + | - | - |
| - | Ял һәм тышкы төзекләндерү объектлары буенча төзелеш мәйданчыкларын чистарту | + | + | - |
| - | Ачык ландшафтларны һәм күренекле урыннарны карап тоту | + | + | - |
| 4 | Агачларны һәм куакларны түбәндәге максатларда утырту: | | | |
| - | Ландшафтларны формалаштыру | + | + | - |
| - | Урманның санитар-гигиенасын һәм утыртмаларның тотрыклылыгын арттыру | + | + | - |
| - | Урманны торгызулар | - | + | + |
| - | Ремизалар булдыру | - | - | + |
| - | Утыртмаларны реконструкцияләү | + | + | - |
| 5 | Болынлы газоннар булдыру | + | - | - |
| 6 | Ачык урыннардагы үлән катламнарын карап тоту | + | + | - |
| 7 | Табигатьне саклау чаралары | + | + | + |
| 8 | Санитар-саклык чаралары, ш.и. санкисүләр | + | + | + |
| 9 | Янгынга каршы чаралар | + | + | + |
| 10 | Урман бозуларны һәм ял итүчеләр тарафыннан урманга зыян салуларны кисәтү | + | + | + |
| ***II. Биотехник чаралар һәм фаунаны саклау*** | | | | |
| 1 | Хайваннар дөньясындагы шартларны яхшырту | - | - | + |
| 2 | Ашату мәйданнарын кору һәм җанварларны ашату | - | + | + |
| 3 | Кош ояларын кору һәм элеп чыгу | + | + | + |
| 4 | Урман хуҗалыгы эшләрен регтаментлау һәм чикләү | - | - | + |
| ***III. Территорияләрне тышкы төзекләндерү*** | | | | |
| 1 | Юл-сукмак челтәрләрен, автотукталышларны, ясалма корылмаларны булдыру | + | + | - |
| 2 | Рекреация маршрутларын булдыру | + | + | - |
| 3 | Күренекле урыннарны һәм карау мәйданнарын булдыру | + | + | - |
| 4 | Ял мәйданнарын булдыру һәм җиһазлау | + | + | - |
| 5 | Архитектураның вак формаларын һәм урман-парк җайланмаларын төзү һәм урнаштыру | + | + | - |
| 6 | Визуаль мәгълүмат | + | + | + |
| 7 | Ачык агитация | + | + | - |
| 8 | Төн кунулы җәйге ял буенча стационар урыннарны кору һәм җиһазлау | + | - | - |
| 9 | Тышкы төзекләндерү объектларын карап тоту, аларны төзекләндерү | + | + | + |
| ***IV. Урманнан файдалану*** | | | | |

| № п/п | Чараларның исеме | Функция зоналары | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ялныкы | Йөреп керә торган | Фауна тынычлыгыныкы |
| 1. | Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү | - | - | - |
| 2. | Урман торгызу буенча кисүләр | - | - | - |
| 3. | Печән чабу | + | + | - |
| 4. | Көтү көтү | - | - | - |
| 5. | Җиләкләрне, гөмбәләрне, чикләвекләрне һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 6. | Дару чималын һәвәскәр җыю | + | + | - |
| 7. | Умартачылык | - | - | - |

"+" тамгасы – файдалану рөхсәт ителә; "–" тамгасы – файдалану рөхсәт ителми.

### 2.8.2 Рекреация эшчәнлеге зонасының кварталлары исемлеге

Рекреация эшчәнлеге зонасы кварталларының кишәрлек урманчылыклары буенча исемлеге әлеге регламентның 3 таблицасында китерелә (урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү).

### 2.8.3 Рекреация эшчәнлеге зонасын функция территорияләренә бүлгәләү

Функциональ бүлгәләнеше буенча рекреация зоналары түбәндәгеләргә бүленә:

1. Интенсив кулланылышлы
2. Чамалап кулланылышлы;
3. Оешкан төстә ял итү;
4. Резерватлы
5. Тыюлык
6. Катгый режимлы
7. Хуҗалык итүле

Рекреация эшчәнлеге буенча Лубян урманчылыгы урманнары уртача файдаланудагы зонага карый.

### 2.9 Урманнардан урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер максатчан токым урман үсентеләрен үстерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Билгеле бер (максатчан) токым урман утыртмаларына, куелган сыйфатламалары булган үзагач алуны тәэмин итә торган ясалма чыгышлы урман утыртмалары кертелә. Урман плантацияләре урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә (урман утыртмалары каплап алмаган җирләрдә һәм урманныкы булмаган җирләрдә)

булдырылырга мөмкин. Урман плантацияләрендә урман утыртмаларын кисү һәм урман утыртмаларына кирт салу чикләүләрсез рөхсәт ителә (РФ УК 42 ст.).

## 2. 10 Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү буенча рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман җимешләрен, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү (РФ УК 39 ст.) җимешләр, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре һәм башка шундый урман ресурслары алуга бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт. Аларны үстерү өчен файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар урнаштыру рөхсәт ителә.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, һәм шулай ук урман булмаган диләнкеләр, аланнарны һәм аларга урман культураларын утыртканчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман утыртмалары белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һ.б.) җирләр файдаланыла.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен реконструкцияләүгә билгеләнмәгән азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланырга мөмкин;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектларының кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен куллану РФ УК 59 статьясы нигезендә тыела.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен һәм дару үләннәрен үстерү өчен саклык урманнарыннан һәм урманнардагы махсус саклanучы кишәрлекләрдән файдалану тыела.

### *Азык-төлек урман продукциясен плантациядә үстерү перспективалары*

Кыргый үсүче азык-төлек һәм дару үләннәре өлкәсендә шактый гына табигый запаслар булуга карамастан, соңгы 20-30 елда кайбер төр җиләкләрне, җимеш бирә торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне ясалма үстерү тенденциясе барлыкка килде. Моның сәбәбе – плантацияләрдә үстерелгән продукциянең үзкыйммәте халыктан җыелган шул ук төр кыргый үсүче үсемлекләрне сатып алу бәяләренә караганда кимрәк чыга.

Плантацияләрдә барлык төр эшләрне дә бергә туплап һәм механикалаштырып була, шул исәптән әзерләүне дә, бер берәмлек мәйданнан уңышны арттырып, һава шартларына бәйлелекне бетереп, селекция өчен шартлар тудырып, продукциянең сыйфатын арттырып була.

Аз гына чыгымнар белән табигый шартларда иң продуктив үсемлекләрне сайлап алырга һәм аларда җимеш бирү һәм эксплуатацияләү (ягъни культуралаштыру) өчен оптималь шартлар тудырырга мөмкин.

Культивацияләнергә мөмкин булган һәм культураны гамәлгә керткәндә үз сыйфатларын югалтмый торган үсемлек төрләре плантацияләрен булдыру максатка ярашлырак.

Урманчылыктагы шартлар түбәндәгеләрнең плантацияләрен булдыру өчен яраклы: кара миләш (арония), сырганак, гөлҗимеш, кара карлыган һәм башка азык-төлек үсемлекләре, дару үләннәре, гөмбәләрдән – шампиньон плантацияләре.

Хәзерге вакытта, сатып алу бәяләре бик югары булганда, акчаны плантацияләр булдыруга тотарга тәкъдим итәргә мөмкин.

Гөлҗимеш плантацияләре өчен иң яхшы туфрак – озак су баса торган елгаларның үзәннәрендәге органик матдәләргә бай кара туфрак һәм куе соры урман туфрагы. Плантацияләр булдыру өчен сөргәннән, органик 100 т/га, фосфорлы 160 кг/га, калийлы 80 кг/га ашламалар керткәннән соң 3 х 1,5 м лы чокырларга һәм буразналарга гөлҗимеш утыртыла, уңыш бу вакытта 5,0 тонна/га җитә.

Урманчылыкларда ясалма алым белән гади вешенка гөмбәсе үстерергә мөмкин. Бер тонна гөмбә җитештерү өчен лабораторияләрдә үстерелә торган инокулянт йоктырырга һәм плантациягә 25-30 см озынлыктагы һәм 22 см диаметрлы 700 усак кисәге утыртырга кирәк, өч ел эчендә бер тонна гөмбә алырга мөмкин булачак.

## 2.11 Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү урманнарны торгызу һәм үрчетү максатында гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, башка затларга арендага бирелә.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану урманчылыкның яисә урман паркының урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Урман кодексының 24 статьясындагы 2 өлеше нигезендә урманнардан файдаланучы гражданнарның, юридик затларның урман хуҗалыгы регламентын һәм урманнарны үзләштерү проектын үтәмәүләре урман кишәрлеген арендалау килешүен вакытыннан алда туктату, шулай ук урман кишәрлегеннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын мәҗбүри туктату өчен нигез була.

Урманнардан файдаланучы гражданнар, юридик затлар Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган тәртиптә граждан законнары нигезендә үзагачка һәм башка алынган урман ресурсларына милекчелек хокукына ирешәләр.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары.

Урман үсентеләренең утырту материалын (утыртмалар, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

– урманнардан аренда килешүе шартлары нигезендә файдаланырга;

– Россия Федерациясе Урман кодексының 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкалар) булдырырга;

– бирелгән урман кишәрлекләрендә теплицалар, башка корылмалар һәм төзелмәләр урнаштырырга;

– аларны гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәгән башка хокукларга ия булырга.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

– урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

– урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдаланырга;

– урман кишәрлеге арендасы килешүе шартларын үтәргә;

– урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен туфрак эрозиясе булдырмаучы, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән урманнардан файдаланырга;

– урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәргә;

– ел саен урман декларациясен тапшырырга;

– урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

– урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;

– дәүләт урман реестрына билгеләнгән тәртиптә документлаштырылган мәгълүмат тапшырырга;

– Россия Федерациясе законнары белән каралган башка йөкләмәләрне үтәргә.

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, һәм шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урманнар урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, һәм

шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела.

Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен куллану Россия Федерациясе Урман Кодексының 59 статьясы нигезендә тыела.

Лубян урманчылыгы территориясенең 114 кв., 38 бүлемтегендә урман питомнигы урнашкан. Питомникның тибы – даими. Питомникның мәйданы - 6,5 га. Продукцияләнүче мәйданы – 5,5 га, алардан: чәчү бүлеге – 1,5 га, мәктәп бүлеге – 0,5 га, парландырылучы территорияләр – 3,5 га. Питомник нарат чәчкеннәрен ачык тамыр системасы белән 300,2 мең данәдә һәм нарат үсентеләрен 15,4 мең данәдә, чыршыныкын 3,3 мең данәдә үстерүгә исәпләнгән. Урман кишәрлеге "Лубян урман техник колледжы" УҺББ ДБББУ тарафыннан даими (вакыты чикләнмәгән) файдаланудa.

## 2. 12 Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләр башкару максатларында файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урман кишәрлекләреннән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләрне башкару өчен файдалану Татарстан Республикасының Урман планы һәм урманчылыкның урман хуҗалыгы регламенты (РФ УК 43 ст.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен урманнардан файдаланганда урман фонды җирләрендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясы нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урманнар урнашкан башка категория җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга бәйле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү башка федераль законнар белән билгеләнгән очракларда шушы җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә рөхсәт ителә.

Барлык очракларда кебек үк урман инфраструктурасы булдыруга бәйсез объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү җирләрдән файдалану эшләре тәмамланганнан соң рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеш).

Урман утыртмаларын кисү урманнардан файдалануның әлеге төренең бер өлеше булган очракларда җир асты байлыклары геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен аренда килешүләре нигезендә урман кишәрлекләре бирелә (РФ УК 43 ст. 2 өлеш).

Мондый эшләрне башкару урман утыртмаларын кисүгә китерсә, капиталь төзелеш объектларын төзү өчен урманнар үз вәкаләтләре чикләрендә

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары рөхсәтләре буенча урман кишәрлекләре бирмичә генә файдаланыла (РФ УК 43 ст. 3 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен урманнардан файдалану өчен урман кишәрлеген арендалау килешүе, аукцион уздыру таләп ителмәсә, ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә (РФ УК 72 ст. 3 өлеш һәм 74 ст. 3 өлеш).

Урман кишәрлеге арендасының күрсәтелгән вакытлары җир асты турындагы законнарның таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

21.02.1992 ел, №2395-1 РФ Законының 10 статьясында билгеләнгәнчә, җир асты кишәрлекләре файдалануга билгеле бер вакытка бирелә:

– геологик өйрәнү өчен – 5 елга кадәр вакытка;

– файдалы казылмалар чыгару өчен – файдалы казылма ятмаларын эшкәртү срогына, ул файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итә торган техник-икътисади нигезләүдән чыгып исәпләнә;

– җир асты суларын табу өчен – 25 елга кадәр вакытка;

– җир астыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктатканда җир астыннан кыска вакытта файдалану хокукы бирү нигезендә файдалы казылмалар чыгару өчен – бер елга кадәр вакытка.

Файдалы казылма ятмаларын эзләүләрне, бәяләүне һәм эшкәртүне тәмамлау яисә ликвидацион чаралар күрү кирәк булган очракта, әлеге җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозулар булмаганда, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча туктатылырга мөмкин.

РФ УК 20 статьясындагы 2 өлешендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдаланганда алынган урман материалына милекчелек хокукы урнаштырыла.

Җир астыннан файдаланучылар үзагач әзерләргә җыенган очракларда, аны РФ УК 29 ст. каралган тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш. Моның өчен урман кишәрлеге бер үк вакытта төрле максатларда файдалану өчен бирелергә мөмкин (РФ УК24 ст. 2 өлеш).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану тәртибе 26.06.2012 ел, №275 Рослесхоз боерыгы белән расланган.

Әлеге норматив хокукый актта урман кишәрлеге бирмичә генә эшләр алып баруга рөхсәт бирү процедурасы билгеләнә.

Урман фонды җирләрендә урман кишәрлеге тапшырылмыйча гына җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен җир астыннан файдаланучы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына язмача гариза тапшыра.

Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

– җир асты байлыкларыннан файдаланучы турында белешмәләр:

– тулы һәм кыскартылган исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше, урнашкан

җире, почта адресы, банк реквизитлары – юридик зат өчен;

– фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урынының адресы, шәхесен раслаучы документ белешмәләре, - шәхси эшмәкәр булган граждан өчен;

– планлаштырыла торган эшләрне башкару өчен кирәкле урман фонды җирләренең урнашкан урыны һәм мәйданы, урманнардан файдалануны нигезләү һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару вакыты.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә яки билгеләнгән тәртиптә аның рәсмиләштерелгән күчермәсе – юридик зат өчен; Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә яки билгеләнгән тәртиптә аның рәсмиләштерелгән күчермәсе – шәхси эшмәкәр булган граждан өчен;
- салым органында исәпкә алыну турында таныклык күчермәсе;
- затның җир асты байлыкларыннан файдаланучы исеменнән эшчәнлек башкаруга вәкаләтләрен раслаучы документ, – кирәк булганда;
- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең күчермәсе яисә дәүләт ихтыяҗлары өчен җир астын геологик өйрәнү эшләрен алып баруга дәүләт контракты күчермәсе;
- җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре башкарылачак урман фонды җирләренең урнашкан урыны һәм мәйданы турындагы мәгълүматларны үз эченә алган картография материаллары.

Дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы утыз көн эчендә гаризаны һәм аңа теркәлүче документларны карый һәм аталган эшләрне башкаруга рөхсәт бирә яки түбәндәге очракларда гаризачыга рөхсәт бирүдән баш тарта:

- тапшырылган документлар Таләпләр тәртибенә туры килмәсә;
- планлаштырылган эшләрне үткәрү РФ законнарында каралган таләпләргә туры килмәсә;
- Урманнарны җир астын геологик өйрәнү эшләрен башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен файдалану тәртибенең эчтәлегенең күпчелек өлеше төрле төрдәге экологик таләпләрне урнаштыруга барып тоташа.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкаруга бәйле объектлар урнаштыру максатларында, иң беренче чиратта, урманныкы булмаган җирләр, урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган мәйданнарны файдалану карала. Әлеге максатлар өчен бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү эшләрен башкаруга бәйле объектлар урнаштыруның башка вариантлары булмаган очракта рөхсәт ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкаруга бәйле объектлар урнаштыру бирелгән урман кишәрлеге һәм аның янәшәсендәге территориядә эрозия үсешен булдырмаска тиеш.

Тиешле объектларның сак һәм санитар-яклау зоналарында урман утыртмаларын кисү урман кишәрлеген биргән дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла.

Урманнарны җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкару максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

• бульдозер ярдәмендә агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агачларның кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән үзагачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;

• урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;

• урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;

• урманнарны химик һәм радиоактив матдәләр белән чүпләү;

• ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда үтеп керү.

Урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча эшләр башкару максатларында файдаланучы затлар түбәндәгеләрне башкара:

– бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

– җитештерү эшчәнлеге барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгыза;

– әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрергә;

– сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм башкару максатларында, квартал юллары, урман юллары билгән һәм урман утыртмалары белән капланмаган башка җирләрдән максималь рәвештә файдалана, шул исәптән хәрәкәт составын һәм йөкләрне шуларда урнаштыра.

### 2.13 Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү буенча рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү буенча урманнардан файдалану РФ УК 44 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре су законнары нигезендә файдаланыла.

РФ Су кодексының 1 статьясы су объекты дип табигый яисә ясалма сулыкны, су агып төшү урынын йә суларның даими яисә вакытлыча җыелып торулары су режимының характерлы рәвешләренә һәм сыйфатларына ия булган бүтән су объектын аңларга тәкъдим итә.

Россия Федерациясе Су кодексының 5 статьясы ясалма су объектлары дип, аерым алганда, сусаклагычларны, буаларны һәм каналларны игълан итә.

Урман хуҗалыгында сусаклагычлар һәм буалар асылда кече һәм уртача елгаларда, шулай ук инешләрнең урман үткәрүчәнлеген көчәйтү өчен, урман әзерләүне һәм бүтән җитештерүне су белән тәэмин итү өчен инешләрдә корыла һәм файдаланыла.

Урман хуҗалыгында каналлар асылда киптерү, сугару һәм суландыру һ.б. максатларында корыла һәм файдаланыла. Аерым очракларда сал агызу каналлары булдырылырга һәм эксплуатацияләнергә мөмкин.

Шул ук максатларда гидротехник корылмалар булдырыла һәм эксплуатацияләнә, аларга "Гидротехника корылмаларының куркынычсызлыгы турында" 21.07.1997 ел, №117-ФЗ Федераль законның 3 ст. нигезендә түбәндәгеләр керә:

– плотиналар, гидростанция корылмалары, су ташлау, су төшерү һәм су чыгару корылмалары, туннельләр, каналлар, насос станцияләре, судно йөри торган шлюзлар, судно күтәрткечләр;

– су басудан һәм сусаклагыч ярлары, елга үзәннәре ярлары һәм төпләре ишелүдән саклауга билгеләнгән корылмалар; сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы оешмаларының сыек калдыкларын саклагычларны киртәләүче корылмалар (дамбалар);

– каналларда су юып китүләрдән саклаучы җайланмалар, һәм шулай ук су ресурсларын файдалануга һәм суларның һәм сыек калдыкларның начар йогынтысын булдырмый калуга билгеләнгән башка корылмалар.

РФ УК шулай ук махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануны күз алдында тота.

РФ Сәүдә өчен диңгездә йөзү кодексының 9 статьясыннан чыгып, анда махсуслаштырылган диңгез портларына билгеләмә бирелә, РФ УК 44 статьясында күрсәтелгән махсуслаштырылган портлар дигәндә махсус бирелгән территориядә һәм акваториядә урнашкан һәм урман ресурсларын һәм урман хуҗалыгы һәм урман сәнәгате өчен кирәкле бүтән йөкләрне ташучы судноларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән корылмаларны аңларга кирәк.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар, махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен

урманнардан файдалану РФ УК 21 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла яисә әлеге файдалану төре урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзүгә, реконструкцияләүгә һәм эксплуатацияләүгә бәйле булмау мөмкинлеге күрсәтелә.

РФ УК 21 статьясы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгәнчә, урман фонды җирләрендә, шулай ук урманнар урнашкан башка категория җирләрдә сусаклагычлардан һәм бүтән ясалма су объектларыннан, шулай ук гидротехник корылмалардан һәм махсуслаштырылган портлардан файдалану өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителә.

Әлеге максатларда урманнардан файдаланганда агачларны, куакларны, лианаларны кисү, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында да, рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 5 өлеше).

РФ УК 21 ст. 6 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган гидротехника корылмалары төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирләр рекультивацияләнергә тиеш.

РФ УК 21 ст. 4 өлешендә күрсәтелгәнчә, гидротехника корылмалары су законнары нигезендә консервацияләнергә яисә ликвидацияләнергә тиеш, аны РФ УК 44 ст. өлеше таләпләрен гамәлгә ашыручы норма буларак карарга мөмкин, аның буенча су законнары нигезендә су объектлары, гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин.

Әлеге урманнардан файдалану урман ресурсларын алмыйча гына, әмма урман кишәрлекләре бирмичә мөмкин булмаган урманнардан файдалану төренә кертелә (РФ УК 44 ст. 2 һәм 3 өлешләре).

Шуның белән бергә сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлегеннән башка су объекты да таләп ителергә һәм файдалануга бирелергә мөмкин.

Россия Федерациясе Су кодексының 11 ст. нигезендә причалларны урнаштыру, шулай урман кишәрлекләре гидротехника корылмалары, шул исәптән мелиоратив системалар урнаштыру һәм төзү су объектларын файдалануга тапшыру турындагы карарлар нигезендә генә мөмкин.

Су объектларын файдалануга тапшыру турындагы карарны әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләре 30.12.2006 ел, №844 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган.

Дәүләти һәм муниципаль милектәге урман кишәрлекләре сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, арендага яисә түләүсез сроклы файдалануга бирелергә мөмкин. Моннан тыш, мондый урман кишәрлекләренә сервитутлар йөкләнергә мөмкин.

РФ УКның 72 ст. 3 өлеше һәм 74 ст. 3 өлеше игезендә әлеге урман кишәрлекләре мондый максатлар өчен, дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә аукционнар уздырмыйча гына, бер елдан алып кырык тугыз елга кадәр арендага бирелергә мөмкин.

Урман фонды җирләрендә урнашкан әлеге урманнардан файдаланудан алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ УКның 20 ст. 2 өлеше).

## 2. 14 Урманнардан электртапшыру линияләре, элемтә линияләре, юллар, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар (алга таба – линияле объектлар) төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану РФ УК 45 ст. белән регламентлана. Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга РФ УК 9 ст. нигезендә бирелә.

Урман фондындагы юллар урман юлларына һәм гомуми файдаланудагы юлларга бүленә. Урман юллары урман инфраструктурасы объектларына кертелә (кар.: РФ УК 13 ст. һәм 1 бүлеге), ә гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар – урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларга кертелә (кар.: РФ УК 21 статьясы).

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларга кертелә.

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урман фонды җирләрендә генә түгел, федераль законнар белән билгеләнгән очракларда, шул җирләрнең максатчан билгеләнеше нигезендә урманнар урнашкан башка категория җирләрдә дә рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 1 һәм 2 өлешләр).

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм эксплуатацияләгәндә агачларны, куакларны, лианаларны кисү, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында да, рөхсәт ителә (РФ УК 21 ст. 5 өлеше).

Әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирләр рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеше).

Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда агач материалы яисә бүтән урман ресурслары әзерләү таләп ителсә,

урманнардан файдалану РФ УК 25 ст. 2 өлеше нигезендә бер үк вакытта берничә максат өчен гамәлгә ашырыла.

Әгәр урман фонды җирләрендә үзагач әзерләү РФ УК 29 статьясындагы кагыйдәләр буенча рәсмиләштерелмәгән булса, алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ УК 20 ст. 2 өлеше).

Дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен гражданнарга һәм юридик затларга электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү өчен биргәндә урман, шулай ук җир һәм граждан законнары кагыйдәләре кулланыла.

Урман законнары кагыйдәләре буенча урман кишәрлекләре арендага бирелә, ә җир һәм граждан законнары кагыйдәләре буенча урман кишәрлекләре даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга һәм түләүсез сроклы файдалануга бирелә. РФ ҖК һәм РФ ГК нигезендә бу урман кишәрлекләренә гавами һәм хосусый сервитутлар билгеләнергә мөмкин.

РФ УК каралганча, дәүләт яисә муниципаль милектәге әлеге урман кишәрлекләренә бу хокуклар гражданнарга һәм юридик затларга бары тик линия объектларын төзү өчен генә бирелергә тиеш.

РФ УК электрүткәргеч линияләрне һәм бүтән линияле объектларны эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләрен бирү мөмкинлеген билгеләми, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарын билгеләү максатларында да.

Тагын шунысын да аерым билгеләп үтәргә кирәк, әлеге саклау зоналарының хокукый режимы РФ УК белән генә түгел, РФ ҖК белән дә билгеләнә.

РФ ҖК саклау зоналары чикләрендә төрле милекчеләрнең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм арендаторларның җир кишәрлекләре урнашкан булырга мөмкин булуын рөхсәт итә (87 статьяның 3 пункты).

Җир законнарының бу таләпләре урманнарда урнашкан сак зоналарына да кагыла.

Мондый алым урманнардан файдалануның гамәленә дә туры килә. Мисал өчен, саклык зоналары кысаларындагы урман кишәрлекләре азык-төлек урман ресурсларын әзерләү, дару үләннәрен җыю, печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү һ.б. өчен арендага бирелергә мөмкин. Шул ук вакытта урманнардан тиешле файдалануны башкаручы гражданнар һәм юридик затлар саклык зоналарындагы хокукый режимны үтәргә тиешләр.

Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар, шул исәптән аларның сак зоналары турындагы мәсьәлә РФ УК 105 ст. белән җентекләп регламентлана (бу юлларның яклау полосалары яклау урманнары дип санала).

Башка линияле объектлар өчен – төзелеш һәм реконструкцияләү өчен, кирәк чакта – эксплуатацияләү өчен дә коммуникацияләр трассалары бирелә.

Урман хуҗалыгында коммуникация трассалары дип урманда электртапшыру линияләрен, телефон линияләрен, торбаүткәргечләрне һәм б.

салу өчен киселүче полосаларны атыйлар. Әлеге полосаларны агач үсемлекләреннән чистарталар һәм аларның иминлеген булдыручы торышта карап тоталар.

Линияле объектларга кагылышлы мәсьәләләрне җайга салуның хокукый нигезе РФ ҖК, шулай ук федераль законнардан һәм РФ Хөкүмәтенең икътисадның тиешле тармаклары эшчәнлеге үзенчәлекләрен билгеләүче карарларыннан гыйбарәт.

РФ УК 89 ст. каралганча, энергетика оешмалары һәм объектлары эшчәнлеген тәэмин итү өчен җир кишәрлекләре электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары һәм электр энергетикасының Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында каралган башка объектларын урнаштыруга бүлеп бирелергә мөмкин. Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының һәм электр энергетикасының Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында каралган башка объектларның өзлексез имин һәм авариясез функцияләвен тәэмин итү өчен, җирләрнең нинди категорияле булуына карамастан, җир кишәрлекләрен куллануда махсус шартлары булган саклык зоналары билгеләнә, аларның составына бу җир кишәрлекләре керә. Әлеге сак зоналарын билгеләү һәм тиешле җир кишәрлекләреннән файдалану тәртибе РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Үз чиратында, “Электр энергетикасы турында” 26.03.2003 ел, №35-ФЗ Федераль закон электрүткәргеч линияләрен электр челтәре хуҗалыгы объектларына кертә һәм теләсә кайсы зат бу линияләрне төзергә хокуклы дип күрсәтә (3, 10 ст.).

Үткәргечләре җир һәм сулар өстеннән элengән һава электрүткәргеч линияләре һәм көч кабель кулланыла торган кабельле электрүткәргеч линияләре (җир астыннан һәм су астыннан) бүленеше кабул ителгән.

Электрүткәргеч линияләре төзү өчен кирәкле җир кишәрлекләре күләме Һава электрүткәргеч линияләре һәм электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре күләмнәрен билгеләү кагыйдәләре (П.08.2003 ел, №486 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган) нигезендә исәпләп чыгарыла.

Шушы Кагыйдәләрнең 6 пункты белән аларны урман фонды җирләренә карата да һәм энергетика җирләренә кертелмәгән, урманнар урнашкан бүтән категория җирләргә карата да куллану рөхсәт ителә.

10 КВка кадәр көчәнешле һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен (электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганалары), контур мәйданы буларак, җир кишәрлегенең, шул исәптән урман кишәрлегенең дә минималь күләмен билгеләү рөхсәт ителә, ул җир өслеге дәрәҗәсендә багананың аркылы киселешенә тигез була.

10 КВка кадәр көчәнешле һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен урман кишәрлегенең минималь күләме түбәндәгеләр буларак билгеләнә:

- җир өслеге дәрәҗәсендә багананың проекциясе контурыннан 1 метрда торган контур мәйданы (тартып торучы җайланмалары булган баганалар өчен – тартып торучысын да кертеп) - тирәнлеге 0,8 метрдан да артмаган ригельләре

булган баганалар урнаштыру өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләреннән гайре, барлык категория җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен;

• җир өслеге дәрәҗәсендә багананың проекциясе контурыннан 1,5 метрда торган контур мәйданы (тартып торучы җайланмалары булган баганалар өчен – тартып торучысын да кертеп) - тирәнлеге 0 метрдан да артмаган ригельләре булган баганалар урнаштыру өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен.

330 КВ һәм аннан да күбрәк көчәнешле, конструкциясендә җиргә беркетелә торган таянычы (тартып торучы җайланмасы) кулланыла торган һава электрүткәргеч линияләре баганалары урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең минималь күләмнәрен барлык категория җирләр (авыл хуҗалыгы җирләреннән гайре) өчен һәр таянычының (тартып торучы җайланмасының) тышкы контурыннан 1 метрда торган, авыл хуҗалыгы җирләре белән чиктәш җир кишәрлекләре өчен – 5 метрда торган контурлары мәйданы буларак билгеләү рөхсәт ителә.

Һава электрүткәргеч линияләре баганалары электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганаларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең конкрет күләмнәре, баганаларны җиргә беркетү зарурлыгыннан, баганаларның күләменнән һәм типларыннан, грунтның күтәрү сәләтеннән һәм багананың тотрыклылыгын һәм эксплуатацияләү иминлеген тәэмин итү максатында багана мәйданчыгын инженер яктан төзекләндерү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

РФ ҖК 91 ст. нигезендә элемтә тәэмин итү өчен (космик элемтәдән гайре) тиешле инфраструктура объектларын урнаштыру максатларында җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин, түбәндәгеләрне кертеп:

• кабельле, радиорелейлы һәм һава элемтә линияләрен, кабельле һәм һава элемтә һәм радиофикация линияләре трассаларындагы радиофикация һәм элемтә линияләренең тиешле саклау зоналарын;

• җир асты кабельле һәм һава элемтә һәм радиофикация линияләре һәм элемтә линияләренең тиешле саклау зоналарын.

"Элемтә турында" 07.07.2003 ел, №126-ФЗ Федераль закон элемтә линияләрен тапшыру линияләре, физик чылбырлар һәм линия-кабель элемтә корылмалары буларак билгели. Анда шулай ук күрсәтелгәнчә, элемтә оешмаларына җир кишәрлекләре бирү мәсьәләләре, алардан файдалану тәртибе (режимы), шул исәптән элемтә челтәрләренең һәм элемтә корылмаларының саклау зоналарын урнаштыру һәм элемтә челтәрләрен урнаштыру өчен бүлемтек юллары уздыру, шушы җир кишәрлекләрен тартып алу нигезләре, шартлары һәм тәртибе җир законнары белән билгеләнә. Мондый җир кишәрлекләренең, шул исәптән саклау зоналары урнаштыру һәм бүлемтек юллары уздыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренең күләмнәре тиешле эшчәнлек төрен, шәһәр төзелеше һәм проект документациясен гамәлгә ашыру өчен җирләр бүлеп бирү нормалары нигезендә билгеләнә.

Җирләрдә, шул исәптән урманнар урнашкан җирләрдә элемтә максатларында файдалануга кагылышлы мәсьәләләр 09.06.1995 ел, №578 РФ

Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе Элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Кабельле һәм һава элемтә линияләре трассаларындагы урман массивларында һәм урман үсентеләрендә түбәндәгечә бүлемтек юллары уздырылырга тиеш:

• үсентеләр биеклеге 4 метрдан кимрәк булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасыннан ким булмаган һәм плюс 4 м киңлектә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 2шәр метр);

• - үсентеләр биеклеге 4 метр булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасыннан ким булмаган һәм плюс 6 м киңлектә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 3әр метр);

- трасса буйлап элемтә кабеле – кимендә 6 м киңлектә (элемтә кабеленнән һәрьяклап 3 әр метр).

Элемтә линияләре трассалары агач-куаклардан даими рәвештә чистартып торылырга, янгын куркынычы кагыйдәләренә туры килерлек дәрәҗәдә тотылырга, юллар арасының билгеләнгән киңлеге үтәлергә тиеш. Үткәргечләргә һәм элемтә линияләре баганаларына куркыныч тудыручы агачлар киселергә тиеш.

Урман массивлары һәм урман үсентеләре аша уза торган кабельле һәм һава элемтә линияләре юллары элемтә линияләре үз карамагында булган предприятиеләр тарафыннан янгын куркынычы кагыйдәләренә туры килерлек дәрәҗәдә тотылырга тиеш.

Гамәлдәге кабельле һәм һава элемтә линияләре трассалары яклаучы урманнар территорияләре аша узса, махсус сакланылучы кишәрлекләрнең (сирәк һәм бетеп баручы хайваннар төрләрен ашату урыннары, балыкларның кыйммәтле токымнарының уылдык чәчү урыннары һәм башкалар) эшчәнлек әһәмияте кимемәгәндә генә бүлемтек юллары булдыру рөхсәт ителә.

Паркларда, бакчаларда, тыюлыкларда, шәһәрләр һәм торак пунктлары тирәсендәге яшел зоналарда, кыйммәтле урман массивларында, кыр саклагыч урман үсентеләрендә, автомобиль юллары һәм тимер юллар буендагы яклаучы урман полосаларында, елгалар һәм каналлар буендагы, күлләр һәм башка сулыклар тирәсендәге тыюлык урман полосаларында бүлемтек юллары уздыру үсентеләр торышына мөмкин кадәр аз зыян китерерлек һәм аларның яклау вазифалары югалмаслык итеп башкарылырга тиеш. Бүлемтек юлларында куаклыклар һәм яшь агачлар киселмәскә (кабельле элемтә линияләренең бүлемтек юлларыннан гайре), йомшак туфракларда, текә урыннарда (15 градустан артык) һәм сулар белән юыла торган урыннарда түмәрләр казып алынмаска тиеш.

Элемтә линияләре үз карамагында булган оешмаларга урман массивлары аша узучы элемтә линияләрендә, шушы линияләр трассалары тирәсендәге урыннарда аварияләр булган очракларда, саклау зоналарындагы аерым агачларны кисү рөхсәт ителә, әмма соңыннан кисү калдыклары җыеп алынырга тиеш.

РФ ҖК 90 статьясы билгеләгәнчә, оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү һәм торбаүткәргеч транспорт объектларын эксплуатацияләү максатларында, түбәндәгеләр өчен җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин:

- - нефть үткәргечләр, газүткәргечләр, бүтән торбаүткәргечләр урнаштыру;
- - җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары белән саклау зоналары билгеләү.

Газ белән тәэмин итү системасы объектлары урнаштырылган саклау зоналары чикләре төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, магистраль торбаүткәргечләрне саклау кагыйдәләре, билгеләнгән тәртиптә расланган башка норматив документлар нигезендә билгеләнә. Күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә аларны хуҗалык алып бару өчен файдаланганда газ белән тәэмин итү объектларына кадәр билгеләнгән минималь ара чикләрендә нинди дә булса биналар, корылмалар төзү рөхсәт ителми. Газ белән тәэмин итү системасы оешмасына – милекчесенә яисә ул вәкаләт тапшырган оешмага газ белән тәэмин итү системасы объектларына хезмәт күрсәтү, аларга ремонт ясау, аларда килеп чыккан аварияләр һәм һәлакәтләр зыяннарын бетерү эшләрен башкарганда каршылык күрсәтү рөхсәт ителми.

Хәзерге вакытта торбаүткәргечнең һәр төре өчен бүлеп бирелгән полосалар киңлеге һәм саклау зоналары чикләре еш кына төзелеш нормалары (СниП) белән билгеләнә.

Урманнар урнашкан һәм торбаүткәргечләр төзелә, реконструкцияләнә һәм эксплуатацияләнә торган җирләрдән файдалануның үзенчәлекләре законнар белән каралган.

Мәсәлән, "Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында" 31.03.1999 ел, №69-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә газ белән тәэмин итү системасының урманнарда урнашкан объектлары (аларга газүткәргечләр дә керә) үз карамагында булган оешмалар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- газ белән тәэмин итү системасының саклау зоналарын янгын куркынычсызлыгы халәтендә тотарга;
- газ белән тәэмин итү системасының саклау зоналарында һәм мондый зоналардан читтә дә Россия Федерациясе урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән эшләрне башкарырга, агач-куакларны кисәргә.

Газ бүлү челтәрләрен саклау буенча 20.11.2000 ел, №878 РФ Хөкүмәтенең карары белән расланган кагыйдәләрендә, аерым алганда, торбаүткәргечләр төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалануның түбәндәге үзенчәлекләре билгеләнә.

Саклау зоналары урманнар аша уза торган поселокара газүткәргечләр трассалары буйларында, – 6 м киңлектәге, газүткәргечнең һәр ягыннан 3 м киңлектәге бүлемтек юллары уздырыла. Газүткәргечләрнең җир өстендәге кишәрлекләре өчен агачлар белән газүткәргеч арасы газүткәргечне эксплуатацияләү вакытында агач биеклегеннән ким булмаска тиеш.

Газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары урманнар буенча узганда газ бүлү челтәрләренең эксплуатацион оешмалары үз исәбеннән түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

• газ бүлү челтәрләренең саклау зоналарын (бүлемтек юлларын) янгын куркынычсызлыгы халәтендә тотарга;

• бүлемтек юллары чикләре буйлап киңлеге кимендә 1,4 м булган минеральләштерелгән полосалар булдырырга;

• һәр 5-7 км саен янгынга каршы техника узып йөрерлек юл булдырырга.

Мондый сак зоналарында һәм аларның чикләрендә эшләр башкару Россия Федерациясе урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә башкарылырга тиеш.

Авария очракларында эксплуатацион оешмага, соңыннан акт рәсмиләштерү шарты белән, техника һәм материаллар китерү өчен иң кыска маршрут буенча газ бүлү челтәрләренә килергә рөхсәт ителә. Урманнар аша узучы газүткәргечләрдә мондый эшләрне башкарганда, киселгән урыннарны калдыклардан чистарту шарты белән, агачларны кисү рөхсәт ителә.

Урман фонды җирләрендә газ бүлү челтәрләренә ремонт ясау, аларга хезмәт күрсәтү яисә аварияләре зыяннарын бетерү эшләрен башкарганнан соң эксплуатацион оешма бу җирләрне башлангыч хәленә китерергә (рекультивацияләргә) һәм аларны җир кишәрлеге милекчесенә, хуҗасына, аннан файдаланучыга яисә ул вәкаләт биргән затка акт буенча тапшырырга тиеш.

Газүткәргечләр урманнарны кисеп үткәндә саклау зоналарында аларны эксплуатацияләү тәртибе газ бүлү челтәрләренең эксплуатацион оешмалары, шулай ук җир кишәрлекләренең милекчеләре, хуҗалары, алардан файдаланучылар белән килештерелергә тиеш.

10.06.2011 ел, №223 Россия Рослесхоз боерыгы белән расланган Электртапшыру линияләрен, элемтә линияләрен, юлларны, торбаүткәргечләрне һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү буенча урманнардан файдалану кагыйдәләрендә. Әлеге мәсьәлә тулысынча хәл ителмәгән.

Электрүткәргеч линияләр, элемтә линияләре, бүлемтек юллары, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре урманнардан файдалануның әлеге төре өчен РФ УК белән билгеләнгән хокукый җайга салуга түбәндәге нормаларны өсти.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында иң беренче чиратта урманныкы булмаган җирләр файдаланыла, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган җирләр.

Әлеге максатлар өчен бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану бары тик линияле объектлар урнаштыруның башка вариантлары булмаган очракта гына рөхсәт ителә

Автомобиль юллары һәм тимер юллар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда өске сулар һәм туфрак эченә сулар агып төшүне боза торган, юллар буендагы урман кишәрлекләрен су бастыра һәм сазландыра торган очраклар булмаска тиеш.

Линияле объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү билгеләнгән һәм шуның тирәсендәге территориядә эрозия процесслары арттырмаска тиеш.

Гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм линияле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклау һәм санитар-яклау зоналарында урман үсентеләрен кисү шушы зоналарның билгеләнгән режимы нигезендә урман кишәрлеген файдалануга тапшырган дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла.

Электрүткәргечләр һәм элемтә линияләре трассаларын 4 метрдан биегрәк агачлардан һәм куаклардан аларны кисү, химик яисә катыш алымнар белән бетерү юлы белән даими рәвештә чистарту рөхсәт ителә.

Бүлемтек юлыннан читтә үсүче һәм электрүткәргечләрнең һәм элемтә линияләренең үткәргечләренә яисә баганаларына авырга мөмкин булган аерым агачлар яисә агачлар төркеме үз вакытында киселергә тиеш. Электрүткәргечләргә һәм элемтә линияләренә (саклау зоналарына) якын булган урман авызларында комачаулаучы агачлар кичекмәстән киселә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

• бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;

• бирелгән урман кишәрлеген һәм бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

• бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

• транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлеге читендәге юллардан гайре ирекле маршрут буенча узарга.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

• бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

• эшчәнлек барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын торгыза;

• әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча

кирәкле чаралар күрә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда бозылган яисә пычранган җирләр тиешле эшләр тәмамланганнан соң кимендә бер ел эчендә рекультивацияләнергә тиеш.

Электрүткәргечләр һәм элемтә линияләре трассаларының туфрак катламы эрозияне арттырырлык итеп бозылган барлык киңлеге буенча үләннәр чәчү һәм (яисә) куаклар утырту юлы белән рекультивация уздырылырга тиеш.

## 2.15 Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Үзагач һәм башка урман ресурслары әзерләү өчен урман кишәрлекләреннән файдалану РФ УК 46 ст. белән регламентлана, Татарстан Республикасының урман планы һәм урманчылыкның урман регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урман эшкәртү объектларын урнаштыруның бүтән вариантлары булмаганда бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану рөхсәт ителә.

Агач материалы һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урман инфраструктурасына бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү РФ УК 21 ст. нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы булдырыла (әзерләнгән үзагачны эшкәртү объектлары, биоэнергетика объектлары һәм башкалар) (алга таба - урман эшкәртү инфраструктурасы объектлары)

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында иң беренче чиратта урманныкы булмаган җирләр файдаланыла, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган җирләр.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын яклаучы урманнарда һәм махсус яклanучы урманнарда урнаштыру рөхсәт ителми.

## 2.16 Урманнардан дини эшчәнлек башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урманнар дини оешмалар тарафыннан РФ УК 47 ст. һәм 1997 елның 26 сентябрендәге “Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында” №125-ФЗ Федераль закон нигезендә дини эшчәнлек башкару буенча файдаланылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар, төзелмәләр төзү рөхсәт ителә (РФ УК 47 ст. 2 өлеше).

Урманнардан әлеге файдалану, урман ресурсларын алмыйча гына, урман кишәрлекләрен биреп гамәлгә ашырыла.

Урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, авыл хуҗалыгы һәм башка шундый эшчәнлек алып бару дини оешмалар тарафыннан бирелгән урман кишәрлекләрендә РФ УК бүтән статьялары нигезендә башкарылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану субъектлары һәм тиешле урман кишәрлегенә мөлкәти хокуклары булган тиешле субъектлар дини оешмалар дип игълан ителә.

26.09.1997 ел, №125-ФЗ Федераль законның 8 статьясы нигезендә дини оешма дип Россия Федерациясе гражданнарының, Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче бүтән затларның бергә гыйбадәт кылу һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм юридик затлар буларак законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән ирекле берләшмәсе таныла.

Юридик зат статусына ия булмаган дини берләшмәләргә, шулай ук дини төркемнәргә һәм аларда катнашучыларга дини максатларда урманнарны файдалану өчен бирү каралмаган.

Дини оешмалар 08.08.2001 ел, №129-ФЗ Федераль закон нигезендә дәүләт теркәве узарга тиеш (дини оешмаларның вөҗдан ирегe һәм дин тоту турындагы законнар белән билгеләнгән дәүләт теркәвен узу тәртибен исәпкә алып).

РФ УК 47 ст. 3 өлеше билгеләгәнчә, дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлек башкару өчен түләүсез сроклы файдалануга бирелә.

## 2.17 Урманнарны саклау, яклау, яңадан үстерүгә карата таләпләр һәм нормативлар

РФ УК 51 ст. нигезендә урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның РУ УК 81-84 ст. билгеләнгән вәкаләтләре кысаларында гамәлгә ашырыла, әгәр дә бүтәне башка федераль законнарда каралмаса.

Әлеге регламент белән урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу буенча кирәкле булган күләмле күрсәткечләр һәм аларны үткәрүнең технологиясенә карата таләпләр билгеләнә.

15 таблица

Санитар-савыктыру чаралары нормативлары

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| **Урманнарның максатчан билгеләнеше: Саклык урманнары Токымы - Нарат** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык буенча | га | 102 | - | 102 | | 102 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 3,69 | - | 3,69 | | 3,69 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 34 | - | 34 | | 34 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | меңее. м3 | 1,23 | - | 1,23 | | 1,23 |
| | - ликвидлы | меңе. м3 | 0,98 | - | 0,98 | | 0,98 |
| | - эшлекле | меңе. м3 | 0,65 | - | 0,65 | | 0,65 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| **Токымы Чыршы** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык буенча | га | 147 | 31 | 116 | | 147 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 8,98 | 6,12 | 2,86 | | 8,98 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | 3 | 3 | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 49 | 10 | 39 | | 49 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 2,99 | 2,04 | 0,95 | | 2,99 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 2,40 | 1,63 | 0,77 | | 2,4 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 1,54 | 1,03 | 0,51 | | 1,54 |
| **Токымы Ак чыршы** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык буенча | га | 13 | 1 | 12 | | 13 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,72 | 0,15 | 0,57 | | 0,72 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | 3 | 3 | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 4 | - | 4 | | 4 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,24 | 0,05 | 0,19 | | 0,24 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,19 | 0,04 | 0,15 | | 0,19 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,12 | 0,02 | 0,10 | | 0,12 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык буенча | га | 262 | 32 | 230 | | 262 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 13,39 | 6,27 | 7,12 | | 13,39 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 87 | 10 | 77 | | 87 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 4,46 | 2,09 | 2,37 | | 4,46 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 3,57 | 1,67 | 1,9 | | 3,57 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 2,31 | 1,05 | 1,26 | | 2,31 |

15 таблица дәвамы

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Бер.<br>үлч. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| | **Токымы - Биек кәүсәле имән** | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 8 | - | 8 | | 8 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 8 | - | 0,18 | | 0,18 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | |
| 3 | Ел саен файдаланылучы күләм: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 3 | - | 3 | | 3 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,07 | - | 0,07 | | 0,07 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,04 | - | 0,04 | | 0,04 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,02 | - | 0,02 | | 0,02 |
| | **Токымы - Т/кәүсәле имән** | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 32 | - | 32 | | 32 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,55 | - | 0,55 | | 0,55 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 11 | - | 11 | | 11 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |

15 таблица дәвамы

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Бер.<br>үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Ш.и.: | | | |
| | | | Барлыгы | Тоташ | Сайланма | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - тамыр | мең. м3 | 0,18 | - | 0,18 | | 0,18 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,11 | - | 0,11 | | 0,11 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,06 | - | 0,06 | | 0,06 |
| **Каты яфраклылар җәмгысе** | | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 40 | - | 40 | | 40 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,73 | - | 0,73 | | 0,73 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 14 | - | 14 | | 14 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,25 | - | 0,25 | | 0,25 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,15 | - | 0,15 | | 0,15 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,08 | - | 0,08 | | 0,08 |
| **Токымы Каен** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | - | 8 | | 8 |
| | | мең. м3 | 0,24 | - | 0,24 | | 0,24 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Сайланма | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,18 | - | 0,18 | | 0,18 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,11 | - | 0,11 | | 0,11 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,06 | - | 0,06 | | 0,06 |
| **Каты яфраклылар җәмгысе** | | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 40 | - | 40 | | 40 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,73 | - | 0,73 | | 0,73 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 14 | - | 14 | | 14 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,25 | - | 0,25 | | 0,25 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,15 | - | 0,15 | | 0,15 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,08 | - | 0,08 | | 0,08 |
| **Токымы Каен** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | - | 8 | | 8 |
| | | мең. м3 | 0,24 | - | 0,24 | | 0,24 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 3 | - | 3 | | 3 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | | 0,08 | - | | | 0,08 |
| | - ликвидлы | | 0,05 | - | | | 0,05 |
| | - эшлекле | | - | - | | | - |
| **Токымы Усак** | | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 2 | - | 2 | | 2 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,07 | - | 0,07 | | 0,07 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 1 | - | 1 | | 1 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,02 | - | 0,02 | | 0,02 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,01 | - | 0,01 | | 0,01 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| **Токымы Юкә** | | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 15 | 5 | 10 | | 15 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 1,47 | 1,23 | 0,24 | | 1,47 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | 3 | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 5 | 2 | 3 | | 5 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,49 | 0,41 | 0,08 | | 0,49 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,30 | 0,25 | 0,05 | | 0,30 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| **Токымы Кара зирек** | | | | | | | |
| 1 | Ачыкланган фонд, | га | 3 | - | 3 | | 3 |
| | урманчылык таләпләре буенча | мең. м3 | 0,05 | - | 0,05 | | 0,05 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Ш.и.: Сайланма | | |
| | - мәйданы | га | 1 | - | 1 | | |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,02 | - | 0,02 | | 0,02 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,01 | - | 0,01 | | 0,01 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| **Йомшак яфраклылар җәмгысе** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 28 | 5 | 23 | | 28 |
| | | мең. м3 | 1,83 | 1,23 | 0,60 | | 1,83 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 10 | 2 | 8 | | 10 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,61 | 0,41 | 0,20 | | 0,61 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,37 | 0,25 | 0,12 | | 0,37 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү: Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Ш.и.: Сайланма | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Саклык урманнары буенча барлыгы:** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 330 | 37 | 293 | | 330 |
| | | мең. м3 | 15,95 | 7,50 | 8,45 | | 15,95 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 111 | 12 | 99 | | 111 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 5,32 | 2,50 | 2,82 | | 5,32 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 4,09 | 1,92 | 2,17 | | 4,09 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 2,39 | 1,05 | 1,34 | | 2,39 |
| **Урманнарның максатчан билгеләнеше: Эксплуатация урманнары Токым - Нарат** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 79 | 2 | 77 | 2 | 81 |
| | | мең. м3 | 3,62 | 0,29 | 3,33 | 0,34 | 3,96 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | 3 | 3 | 1 | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Сайланма | | |
| | - мәйданы | га | 27 | 1 | 26 | 2 | 29 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 1,21 | 0,10 | 1,11 | 0,34 | 1,55 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,97 | 0,08 | 0,89 | 0,05 | 1,02 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,63 | 0,05 | 0,58 | 0,03 | 0,66 |
| | **Токым - Чыршы** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 38 | - | 38 | 2 | 40 |
| | | мең. м3 | 1,07 | - | 1,07 | 0,29 | 1,36 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | 1 | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 13 | - | 13 | 2 | 15 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,36 | - | 0,36 | 0,29 | 0,65 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,29 | - | 0,29 | 0,1 | 0,39 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,17 | - | 0,17 | - | 0,17 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Сайланма | | |
| **Токым - Карагач** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 2 | - | 2 | | 2 |
| | | мең. м3 | 0,05 | - | 0,05 | | 0,05 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 1 | - | 1 | | 1 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,02 | - | 0,02 | | 0,02 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,01 | - | 0,01 | | 0,01 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| **Ылыслылар җәмгысе** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 119 | 2 | 117 | 4 | 123 |
| | | мең. м3 | 4,74 | 0,29 | 4,45 | 0,63 | 5,37 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 41 | 1 | 40 | 4 | 45 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү: Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Сайланма | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 1,59 | 0,10 | 1,49 | 0,63 | 2,22 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 1,27 | 0,08 | 1,19 | 0,15 | 1,42 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,80 | 0,05 | 0,75 | 0,03 | 0,83 |
| | **Токым - Каен** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 90 | 1 | 89 | | 90 |
| | | мең. м3 | 3,51 | 0,10 | 3,41 | | 3,51 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | 3 | 3 | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 30 | - | 30 | | 30 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 1,17 | 0,03 | 1,14 | | 1,17 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,70 | 0,02 | 0,68 | | 0,70 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,07 | - | 0,07 | | 0,07 |
| | **Токым - Усак** | | | | | | |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | - | 8 | | 8 |
| | | мең. м3 | 0,43 | - | 0,43 | | 0,43 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 3 | - | 3 | | 3 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,14 | - | 0,14 | | 0,14 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,08 | - | 0,08 | | 0,08 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| **Токым - Юкә** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 1 | - | 1 | | 1 |
| | | мең. м3 | 0,03 | - | 0,03 | | 0,03 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | 3 | - | 3 | | 3 |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | - | - | - | | - |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү: Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Ш.и.: Сайланма | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - тамыр | мең. м3 | 0,01 | - | 0,01 | | 0,01 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,01 | - | 0,01 | | 0,01 |
| | - эшлекле | мең. м3 | - | - | - | | - |
| | **Йомшак яфраклылар җәмгысе** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 99 | 1 | 98 | | 99 |
| | | мең. м3 | 3,97 | 0,10 | 3,87 | | 3,97 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 33 | - | 33 | | 33 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 1,32 | 0,03 | 1,29 | | 1,32 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,79 | 0,02 | 0,77 | | 0,79 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,07 | - | 0,07 | | 0,07 |
| | **Эксплуатация урманнары буенча барлыгы:** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 218 | 3 | 215 | 4 | 222 |
| | | мең. м3 | 8,71 | 0,39 | 8,32 | 0,63 | 9,34 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү: Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Ш.и.: Сайланма | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 74 | 1 | 73 | 4 | 78 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | меӊ. м3 | 2,91 | 0,13 | 2,78 | 0,63 | 3,54 |
| | - ликвидлы | меӊ. м3 | 2,06 | 0,10 | 1,96 | 0,15 | 2,21 |
| | - эшлекле | меӊ. м3 | 0,87 | 0,05 | 0,82 | 0,03 | 0,90 |
| | **Барлыгы** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 548 | 40 | 508 | 4 | 552 |
| | | меӊ. м3 | 24,66 | 7,89 | 16,77 | 0,63 | 25,29 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 185 | 13 | 172 | 4 | 189 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | меӊ. м3 | 8,23 | 2,63 | 5,60 | 0,63 | 8,86 |
| | - ликвидлы | меӊ. м3 | 6,15 | 2,02 | 4,13 | 0,15 | 6,30 |
| | - эшлекле | меӊ. м3 | 3,26 | 1,10 | 2,16 | 0,03 | 3,29 |

15 таблица дәвамы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: Тоташ | Сайланма | | |
| **Шул исәптән: Ылыслы** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 381 | 34 | 347 | 4 | 385 |
| | | мең. м3 | 18,13 | 6,56 | 11,57 | 0,63 | 18,76 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 128 | 11 | 117 | 4 | 132 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 6,05 | 2,19 | 3,86 | 0,63 | 6,68 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 4.84 | 1,75 | 3,09 | 0,15 | 4,99 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 3,11 | 1,10 | 2,01 | 0,03 | 3,14 |
| **Каты яфраклы** | | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 40 | - | 40 | | 40 |
| | | мең. м3 | 0,73 | - | 0,73 | | 0,73 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 14 | - | 14 | | 14 |

15 таблицаның азагы

| № п/п | Күрсәткечләр | Бер. үлч. | Һлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Урманнарны чүпләрдән чистарту | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Ш.и.: | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 0,25 | - | 0,25 | | 0,25 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 0,15 | - | 0,15 | | 0,15 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,08 | - | 0,08 | | 0,08 |
| | **Йомшак яфраклы** | | | | | | |
| 1 | Урманчылык таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 127 | 6 | 121 | | 127 |
| | | мең. м3 | 5,80 | 1,33 | 4,47 | | 5,80 |
| 2 | Кисеп ташлау яки чистарту вакыты | ел | | | | | |
| 3 | Ел саен мөмкин булган үзагач алу күләме: | | | | | | |
| | - мәйданы | га | 43 | 2 | 41 | | 43 |
| | Сайлана торган запас: | | | | | | |
| | - тамыр | мең. м3 | 1,93 | 0,44 | 1,49 | | 1,93 |
| | - ликвидлы | мең. м3 | 1,16 | 0,27 | 0,89 | | 1,16 |
| | - эшлекле | мең. м3 | 0,07 | - | 0,07 | | 0,07 |

### *Санитар-савыктыру чаралары үткәргәндә кисәсе агачларны сайлау*

Сайланма санитар кисү һәм чүп-чардан чистарту вакытында кисәргә сайлау һәм агачларны келәймәләү урманчылыктагы (урман паркындагы) вазифалы затларының турыдан-туры контроле астында эшләнә. Тоташ санитар кисүләрдә келәймәләү соралмый.

5-6 нчы категория торышындагы агачлар мәҗбүри тәртиптә санитар кисүләргә билгеләнә. Җил-давыл аударган агачлар 5-6 нчы категория торышындагыларга тиңләнә.

Башка категория агачларны чистарту түбәндәге очракларда мөмкин:

- 4 нче категория торышындагы агачлар ылыслы утыртмаларда кисүгә билгеләнә;
- 3-4 категория торышындагы (нык зәгыйфьләнгән һәм корый баручы) агачлар кисүгә тамыр көпшәге, бактериаль сарысу һәм голланд чире чыганакларында билгеләнә. Шул ук вакытта кисүне планлаштыру материалларында мәҗбүри рәвештә әлеге кишәрлекнең ни сәбәпле чир чыганагына кертелүе, чыганакның сыйфатламалары күрсәтелергә тиеш;
- эксплуатация урманнарында – кәүсәсендә ачыктан-ачык черү билгеләре (куышлар, агач мәшкәләре, кәүсәнең 2/3 әйләнәсе кадәр яман шеш яралары) булган агачлар;
- янгын үткән утыртмаларда – кәүсә әйләнәсенең кимендә 3/4 өлеше кадәр тамыр муенсасы янган агачлар (бу очракта сынау мәйданында кимендә 100 агачның тамыр муенсасы казылган булырга тиеш), яисә кәүсә әйләнәсенең кимендә 3/4 өлешендә юкәр кибү (сынау мәйданы шулай ук мәҗбүри);
- поши һәм башка хайваннар кәүсә әйләнәсенең өчтән бердән күбрәген бозган һәм кәүсә черегe билгеләре булган, шулай ук кәүсәне яртыдан күбрәк баскан яңа корткычлары булган чыршы агачлары.

Ылыс һәм яфрак ашаучы бөҗәкләр чыганакларындагы агачларны кисүгә ылыс (яфрак) терелү дәвере үткәннән соң сайлана.

Гектарына 5-10 данә булган куышлы агачлар урман фаунасындагы җан ияләренә табигый куыш булдыру максатларында калдырыла.

Санитар савыктыру чаралары үткәргәндә агач һәм куакларны кисү Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләренә, Үзагач әзерләү кагыйдәләренә, Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә (2007 елның 30 июнендәге №417 Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгына) һәм Урманнарны карап тоту кагыйдәләренә (16.07.2007 ел, №185 Россия ТРМ боерыгына) ярашлы рәвештә үткәрелә.

Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектларының Кызыл китапларына, шулай ук 2007 елның 15 мартындагы №162 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән үзагачын әзерләү тыелган агач һәм куак төрләре исемлегенә кертелгән урман үсемлекләренең һәлак булган затларын гына кисәргә рөхсәт ителә (Кагыйдәләрнең 34 статьясы).

### *Сайланма санитар кисүләр*

Сайланма санитар кисүләр тотрыклылыгын өлешчә югалткан утыртмаларны савыктыру, аларның максатчан функцияләрен торгызу, кәүсә корткычлары һәм куркыныч йогышлы чир чыганакларын бетерү һәм (яисә) юк итү максатыннан үткәрелә.

Сайланма санитар кисүләрдән соң утыртмаларның тыгызлыгы иминлек категорияләренә яки максатчанлыкка туры килерлек функцияләрне үтәрлек соң чик зурлыклардан түбән булмаска тиеш. Табигый шартларда сирәк тыгызлыкта үсә торган утыртмаларда сайланма кисүдән соң тыгызлык кимү лимитланмый. Андый утыртмаларга түбәндәгеләр керә: артыш, арчан, саксаул урманнары, үз ареалының көньяк чикләрендәге наратлар, биек тау эрбетлекләре.

Өлгергән һәм картайган эксплуатация урманнарында сайланма санитар кисүләр үткәрелми. Аларда агач авулар ешайган очракта, алар беренче чиратлы кисүгә планлаштырыла.

Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сайланма санитар кисүләр үткәрелми.

Үсеп утырган агачлар уттан зарарланганда санитар кисүгә мөмкин кадәр тизрәк керешергә, язгы янгыннарда аны 1 июльгә, иртә җәйге янгыннарда – 1 августка, соң җәйге һәм көзге янгыннарда – киләсе елның 1 маена кадәр төгәлләргә кирәк.

Составында 7 данәдән артык чыршы катнашмалы утыртмаларда сайланма кисүләр рөхсәт ителми.

### *Тоташ санитар кисүләр*

Әгәр 0,1 гектарлы һәм зуррак мәйданда бөтен агачлар киселсә, бу тоташ санитар кисү булып санала. 1 гектарда һәм күбрәк мәйданда (чыршы һәм ак чыршы утыртмаларыннан гайре) сәламәт агач урыннары булган бүлемтекләрне тоташ кисәргә ярамый.

Тоташ санитар кисүләр киселергә тиешле агачлар киселгәннән соң агачлыкның ешлыгы саклык урманы яисә максатчан урман категориясенә ярашлы функцияләрне үтәү сәләте югалырлык чикләрдән түбән төшә торган утыртмаларда үткәрелә. Агачлыкның факттагы ешлыгы урман патологиясен тикшергәндә исәпләнә.

Тоташ санитар кисүгә планлаштырылган урман кишәрлегенең һәр бүлемтегендә сынау мәйданнары билгеләнә. Сынау мәйданнарында төп токымнан булган 100 агач, түбән ешлыклы утыртмаларда (факттагы ешлык 0,3-0,5 булса) – төп токымның кимендә 50 агачы исәпкә алына. Тоташ санитар кисүгә билгеләнгән кишәрлекнең мәйданы 100 гектардан артык булган очракта, сынау мәйданнарын һәр өченче бүлемтектә билгеләү һәм сынау билгеләнмәгән кишәрлекләрдәге агачларны күз чамасы белән патологик таксацияләү рөхсәт ителә.

Сынау мәйданнары кишәрлек буенча тигез билгеләнә. Аларның саны төп урман токымының торыш категорияләре буенча уртача күрсәткечләрне ±10%тан артмаган хата белән бәяләргә мөмкинлек бирергә тиеш.

Тоташ санитар кисүләрнең вакытларын һәм технологиясен төп корткычларның һәм чирләрнең биологиясе, утыртмаларның урман хуҗалыгы ягыннан сыйфатламасы, аның табигый яңарышы белән бәйлиләр.

### *Чүп-чардан чистарту*

Чүп-чарны (ликвидлы булмаган үзагачны һәм утынны), шул исәптән ауган агачларны җыештыру, кагыйдә буларак, карап тоту буенча кисүләр, сайланма һәм тоташ санитар кисүләр белән берлектә үткәрелә.

Аерым чара буларак чүп-чардан чистарту җил-давыл, кар аударган, җилле янгын узган агачлыкларда, ликвидлы булмаган үзагачлар һәм утын гомуми утыртма запасының 90% ыннан арткан очракта үткәрелә.

Чүп-чардан чистарту беренче чиратта махсус саклanучы кишәрлекләрдә, рекреация зоналарында, урман паркларында, санитар-гигиена һәм савыктыру функцияләрен үтәүче урманнарда, юл буендагы саклык полосаларында, мемориаль утыртмаларда һәм башка аеруча кыйммәтле урман массивларында үткәрелә. Башка максатчан билгеләнештәге җирләрдә һәм башка категорияле саклык урманнарында чүп-чардан чистарту зарарлы организмнар чыганагы барлыкка килү яисә янгын куркынычы янаганда үткәрелә.

15.1 таблица

**Агачлар торышы категорияләре шкаласы**

| Агачларның категорияләре | Торыш категориясе билгеләре | |
|---|---|---|
| | Ылыслы | Яфраклы |
| 1 - зәгыйфьләнү билгеләреннән башка | Ябалдашы куе, ылыслары (яфраклары) яшел, шлеге токым, яшь, үсү урыны шартларына карата агымдагы ел үсентесенең зурлыгы нормаль. | |
| 2 – зәгыйфьләнгән | Ябалдашы сирәкләнгән; ылыслары ачык яшел; үсентеләре кимегән, әмма яртысыннан да артыгракка түгел; аерым ботаклары корыган | Ябалдашы сирәкләнгән; ылыслары ачык яшел; үсентеләренең яртысыннан артыгы кимегән; аерым ботаклары корыган; берән-сәрән сулы бөреләр |
| 3 - каты зәгыйфьләнгән | Ябалдашы челтәрле; ылыслары ачык-яшел, тонык; үсентесе аз, гадәти белән чагыштырганда яртысыннан азрак; ябалдашының 2/3 ботаклары кибә | Ябалдашы челтәрле; яфраклары вак, ачык яшел; үсентеләре аз, гадәти белән чагыштырганда яртысыннан азрак; ябалдашның 2/3 ботаклары кибеп бара; бик күп сулы бөреләр |
| 4 - кибеп баручы | Ябалдашы нык челтәрле; ылыслары соры, сарырак яки сары-яшел; үсентеләре зәгыйфь яки юк; 2/3 артык өлештә ботаклары кибеп бара | Ябалдашы нык челтәрле; яфраклары вак, сирәк, ачык яшел яки сарырак төстә; үсентеләре зәгыйфь яки юк; 2/3 артык өлештә ботаклары кибеп бара |
| 5 - яңа коры-сары | Ылыслары соры, сары яки кызыл-ак; өлешчә кайрысы каерыла | Яфраклары шиңгән яки юк; өлешчә кайрысы каерыла |
| 6 - иске коры-сары | Тере ылыслары (яфраклары) калмаган; кайрысы һәм вак ботаклары өлешчә яки тулысынча коелган; кәүсәсендәге корткычлары очып беткән; кәүсәсендә агачларны черетә торган гөмбәләр гөмбәлеге | |

Җил, давыл аударган һәм кар сындырган агачлар аерым исәпкә алына. Урта торыш категориясен хисаплаганда алар яңа яки иске коры-сарыга тиңләштерелә. Яңа гына җил, давыл яки кар аударган агач кәүсәләре дип тикшерү моментына кадәр ике елдан да артмаган чорда һәлак булган агач кәүсәләре санала. Биеклегеннән башлап үлчәгәндә ябалдашы озынлыгының өчтән бер өлеше күләмендә кәүсәсе сынган агачлар давыл аударган (кар басып сындырган) дип санала. Кәүсәсенең өчтән береннән артыграк өлеше өзелгән аударылган яки бөгелгән агачлар җил аударган булып санала.

15.2 таблица

## Сайланма санитар кисүләрдә билгеләнә торган минималь тулылык билгеләре

| Урманнан файдалану төрләре һәм саклык урманнары категорияләре | Күпчелек токым | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Чыршы, ак чыршы | Эрбет | Нарат | Карагач | Имән | Кәстәнә | Каен һәм башка яфраклылар |
| Эксплуатация урманнары | | | | | | | |
| Үзагач әзерләү | 0,5 | - | 0,3 | 0,3 | 0,3 | | 0,3 |
| Чәер әзерләү | - | - | 0,3 | - | - | - | - |
| Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге | Лимитланмый | | | | | | |
| Рекреация эшчәнлеген башкару | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| Урман плантацияләрен эксплуатацияләү | Лимитланмый | | | | | | |
| Урманнан файдалануның башка төрләре | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| Саклык урманнары | | | | | | | |
| 1. Су саклау зоналарында урманнар | Лимитланмый | | | | | | |
| 2. Табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар:<br>а) эчәр су белән тәэмин итү чыганакларының санитар сак зонасындагы беренче һәм икенче поясларындагы урманнар | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| б) РФ субъектлары милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары | 0,6 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |
| в) шәһәр буе җирлекләрендәге урман зоналары | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |

| Урманнан файдалану төрләре һәм саклык урманнары категорияләре | Күпчелек токым | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Чыршы, ак чыршы | Эрбет | Нарат | Карагач | Имән | Кәстәнә | Каен һәм башка яфраклылар |
| г) шәһәр урманнары | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| д) дәвалау-савыктыру җирлекләренең һәм курортларның (таулы-санитар) санитар сак округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урманнар | 0,5 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| 3. Кыйммәтле урманнар:<br>а) дәүләт саклык урман полосалары | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | - | 0,5 |
| б) эрозиягә каршы көрәш урманнары | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 | 0,3 |
| в) далалы, ярымдалалы, чүллекле, урман-далалы һәм аз урманлы таулы территорияләрдәге урманнар | Лимитланмый | | | | | | |
| г) фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар | Лимитланмый | | | | | | |
| д) чикләвекле-һөнәрчелекле зоналар | Лимитланмый | | | | | | |
| е) җимешле урман утыртмалары | Лимитланмый | | | | | | |
| ж) тундра буе урманнары | Лимитланмый | | | | | | |
| з) тасмалы наратлыклар | - | - | 0,2 | - | - | - | 0,3 |
| 4 Махсус сакланучы урман кишәрлекләре | Лимитланмый | | | | | | |

15.3 таблица

**Россия Федерациясенең урман территориясен урманда төпләнмәгән (саклаусыз) урман продукциясен саклауны (калдыруны) тыю вакытлары буенча зоналаштыру**

| Урман үсү зоналары һәм зона өлешләре | Саклаусыз урман продукциясен урманда саклау (калдыру) вакытлары |
|---|---|
| Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы – киң яфраклы урманнар | 1 майдан 1 сентябрьгә кадәр |
| Урман-дала | 15 апрельдән 15 сентябрьгә кадәр |

Искәрмә: Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма хакимият органнары югарыда күрсәтелгән вакытларны урманлы районнарның климат үзенчәлекләрен һәм аерым елларның һава торышын исәпкә алып теге яки бу якка 15 көнгә кадәр үзгәртергә мөмкиннәр.

## Санитар-савыктыру чаралары күрелмәүдән килгән зыянны хисаплау

Утыртмалар кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән зыянны билгеләгәндә, хисап түбәндәгечә ясала:

$$M_1 = Ун[R(t_1) - R^x_{(t)}]$$

Монда Ун – утыртманың корыган өлеше;

R(t1) – үсә калган урманның кыйммәте;

Rx(t1) – корыган урманның кыйммәте;

$t_1$ – агачлыкның кору мизгелендәге яше.

Үсә калган урманның кыйммәте түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R(t1) = \frac{V*m}{(1+a)^{T-t1}}$$

биредә: V – кисү яшендәге фактик агач запасы, м3/га:

m – агач кубометрының кыйммәте, сумнар;

T – кисүнең яше, еллар;

$t_1$ – агачлыкның бәяләү мизгелендәге яше, еллар;

a – дисконтлау нормасы.

Яшь, урта яшьле, өлгереп килүче һәм өлгергән барлык утыртмалар да бәяләүгә кертелә, ә кирәкле булган кулланылыш сыйфатларына бары тик өлгергән утыртмалар гына ия булганга күрә, үсеп утырган агачларны бәяләү башлангыч мизгелгә, ягъни бәяләү мизгеленә дисконтланган җитлегү яшендә көтелгән нәтиҗә буенча башкарыла.

Кисү яшендә көтелгән запас күләме модель утыртмаларының урман корылышы барышында төзелә торган таксация күрсәткечләре динамикасы таблицалары буенча билгеләнә. Өлгергән утыртмаларны бәяләгәндә запаслар таксация тасвирламаларыннан алына. Үзагачның бәясе Россия Федерациясенең конкрет субъекты нормативлары буенча билгеләнә.

Корыган урманның бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Rx(t1) = (1 - \frac{0{,}006*S)V_0m_0}{S},$$

биредә: S – агач кору фараз ителгән мәйдан;

$V_0$ – $t_1$ яшендәге 1 га агач запасы;

$m_0$ – t1 яшендәге 1 куб.м агач өчен төпләтә түләү.

## 2.17.1 Урманнарны янгыннардан саклау таләпләре

РФ Урман кодексының 52 ст. нигезендә урманнарны янгыннардан саклау "Янгын куркынычсызлыгы турында" 21.12.1994 ел, № 69-ФЗ Федераль закон (алга таба – 21.12.1994 ел, № 69-ФЗ Федераль закон) нигезендә гамәлгә ашырылганлыгы билгеләнгән.

21.12.1994 ел, №69 Федераль закон Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең гомуми хокукый, икътисади һәм социаль нигезләрен билгели. Әлеге өлкәдә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, оешмалар, крестьян (фермерлык) хуҗалыклары, бүтән, аларның нинди оештыру-хокукый формалы һәм милек формасында булуына карамастан юридик затлар арасындагы, һәм шулай ук иҗтимагый берләшмәләр, вазифаи затлар, Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар арасындагы мөнәсәбәтләрне көйли.

Янгын куркынычсызлыгы дигәндә Законда шәхеснең, милекнең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең янгыннардан сакланышы аңлашыла, шул ук вакытта янгын дип контрольдә тотылмый торган, матди зыян, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең мәнфәгатьләренә зарар китерә торган яну санала (21.12.1994 ел, № 69-ФЗ Федераль законның 1 ст.).

Янгын куркынычсызлыгы чаралары Россия Федерациясе законнары, янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар нигезендә, һәм шулай ук янгыннар белән көрәш тәҗрибәсеннән, матдәләрнең, материалларның, технология процессларының, конструкция эшләнмәләренең, биналарның һәм корылмаларның янгын куркынычын бәяләүдән чыгып эшләнә (21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль законның 21 ст.).

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең специфик үзенчәлекләре 30.06.2007 ел, №417 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрендә, шулай ук стандартларда чагылыш таба. Мәсәлән, хәзерге вакытта 19.12.1983 ел, №6263 СССР Дәүләт стандартының (алга таба – ГОСТ 17.6.1.01-83) белән расланган "Табигатьне саклау. Урманнарны саклау һәм яклау. Терминнар һәм билгеләмәләр" дигән ГОСТ 17.6.1.01-83, шулай ук 24.02.1998 ел, №38 Федераль урман хуҗалыгы хезмәте 38 боерыгы (алга таба – ОСТ 56-103-98) белән расланган "Урманнарны янгыннардан саклау. Янгынга каршы ерымнар һәм минеральләштерелгән полосалар. Сыйфат критерийлары һәм торыш бәяләмәләре" дигән ОСТ 56-103-98 гамәлдә тора.

Әйтелгән стандартларда урман янгыны дип урман мәйданында таралучы янгын (ГОСТ 17.6.1.01-83) яисә урман фондының капламлы һәм капламсыз мәйданнарында стихияле (идарә ителми торган) ут таралу (ОСТ 56-103-98) аңлана.

Урман янгыннары югарылыклардагы һәм түбәнлекләрдәге янгыннарга бүленә. Югарылыктагы янгын дип агач ябалдашларын ялмап ала торган янгын санала. Түбәндәге янгын – урман аслыгы, коелган яфраклар һәм урман

үсемлекләренең (агачлыкларының) аскы ярусы, куаклар һәм яшь агачлар буйлап тарала торган янгын.

ГОСТ 17.6.1.01-83, моннан тыш, тоташ, ландшафт янгынын, коры-сары янгынын һәм торф янгынын аерып күрсәтә.

Тоташ янгын дип урман биоценозының бөтен компонентларын ялмап ала торган урман янгыны санала.

Ландшафт янгыны – географик ландшафтның төрле компонентларын ялмап ала торган урман янгыны.

Коры-сары янгыны дип төп яну материалын туфрак өстендә яткан агачлар тәшкил иткән аскы янгын аңлана.

Урмандагы торф янгыны – баткаклы һәм сазлыклы туфракларның торф катламы яну ул.

Махсус әдәбияттә янгын куркынычын бәяләгәндә (янгын ихтималын исәпләгәндә) төп категория булып урманнарның янучанлыгы тора, ул исә суммар урман янгыннары мәйданының барлык урман мәйданына нисбәтен аңлата (ГОСТ 17.6.1.01-83).

Урманда янгын куркынычы дип урман янгыны кабыну һәм (яисә) үрләп китү мөмкинлеге аңлана.

Урман кишәрлекләренең янгын куркынычы классы аларда янгын чыгу һәм янгыннарның интенсивлык ихтималларын чагыштырма бәяләүдән гыйбарәт (ГОСТ 17.6.1.01-83). Ул янгынның конкрет урман кишәрлекләрендә чыгу ихтималы буенча, урман үсемлекләре шартларын (урман тибын), аның табигый һәм башка үзенчәлекләрен, шулай ук һава торышын (коры, бик коры, дымлы һ.б.) исәпкә алып билгеләнә.

Шул ук вакытта урманнардагы янгын куркынычының биш классын аералар.

Урманнарны янгыннардан саклау дип урман янгынын булдырмауга, үз вакытында ачыклауга һәм бетерүгә юнәлтелгән саклау (ГОСТ 17.6.1.01-83), ел саен үткәрелә торган чаралар комплексы, шул исәптән янгын куркынычын кисәтү, киметү буенча профилактик чаралар, урман янгыннарын үз вакытында ачыклауга һәм бетерүгә юнәлтелгән чаралар санала (ОСТ 56-103-98).

Урманнарны янгыннардан саклауга урман янгыннарын оператив ачыклау, җир өстендәге һәм авиация урман саклау көчләре белән сүндерү, урман янгыны хезмәтләрен матди-техник яктан тәэмин итү, янгынга каршы кисәтү (профилактика) чаралары үткәрү, урман янгыннарына мониторинг системасын булдыру һ.б.ш. керә.

Кагыйдә буларак, урманнарны янгыннардан саклау төп өч алымның берсе белән тормышка ашырыла:

- җир өстендә саклау (янгыннарны җирдәге көчләр һәм чаралар белән ачыклау һәм сүндерү);
- янгыннардан җир өстендә саклануны авиация патруле белән бергә алып бару (янгыннарны авиация ярдәмендә ачыклау, җирдәге көчләр һәм чаралар белән сүндерү);
- авиация ярдәмендә саклау (янгыннарны авиация ярдәмендә ачыклау, янгын сүндерү көчләрен һәм чараларын авиация белән ташу.

Алга таба 15.4 таблицада урманнарны янгыннардан саклауны оештыру нормативлары китерелә

15.4 таблица

**Урманнарны янгыннардан саклаганда эш урыннарын урнаштыру һәм планлаштыру нормативлары**

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1. | **Гомуми нормативлар** | |
| 1.1 | Урман фондын урман янгыннары районнарына бүлү: | |
| | - җир өстендәге сак районнары<br>- җир өстендәге авиапатруль сагындагы районнар | Янгыннарны ачыклау һәм сүндерү җир өстендә көчләр һәм янгыннарны авиация патруле ачыклау чаралары ярдәмендә, сүндерү - җирдәге көчләр һәм чаралар белән башкарыла |
| 1.2 | Янгын куркынычлылыгы дәрәҗәсе буенча урман фонды кишәрлекләрен бәяләү | |
| | - югары<br>- уртача<br>- түбән | Үсеп китү урыны шартлары буенча - 1-2 класслар, һава шартларына карап - 4-5 класслар<br>3 класс (ике очракта да)<br>Үсеп китү урыны шартлары буенча - 4-2 класслар, һава шартларына карап - 1-2 класслар |
| 1.3 | Урманнарның фактта яну чоры (янгын куркынычы тудыручы һава торышы чоры) | Һава торышы буенча янгын куркынычының 2 - 5 класска кадәрге көннәре |
| 1.4 | Конкрет урманчылык буенча янгын куркынычы сезонының факттагы озынлыгын билгеләү (урманчылык буенча) | Кар катламы кузгалу һәм барлыкка килү. 10 ел һәм аннан да күбрәк еллар эчендә урманнарның фактта яну чорының максималь һәм уртача чоры озынлыгы. Җирле шкалалар буенча һава торышының янгын куркынычы дәрәҗәсе – һава торышының 2 класслы янгын куркынычы башлану һәм бетүнең иң соңгы һәм уртача даталары |
| 1.5 | Урманнарның чагыштырмача януачанлыгы | Янгыннарның уртача еллык мәйданын урман фонды мәйданына бүлүдән килеп чыккан зурлык |
| 1.6 | Урман янгыннарының зурлыгы:<br>- эре<br>- исәпкә алып була торган | <br>25 га артык мәйдан<br>Теләсә нинди мәйданда урман фонды территориясе янып китү |
| 1.7 | Янгынның интенсивлыгы<br>- түбән<br>- уртача<br>- югары | <br>Ялкынның биеклеге 0,5 м һәм аннан да югары<br>Ялкынның биеклеге - 0,6 - 1,0 м<br>10 метрдан артык |
| 2. | **Җир өстендәге сак районнарында урманнарны янгынга каршы планлаштыру нормативлары:** | |
| 2.1 | Ылыслы токымнарның янгын куркынычы булган эре массивларын планлаштыру | Ылыслы токымнарның янгын куркынычы булган эре массивларын планлаштыру 2 гектардан алып 12 мең гектарга кадәр мәйданда өске һәм аскы янгыннар таралуга каршы торырлык (янгын куркынычы дәрәҗәсенә һәм урман хуҗалыгы интенсивлыгына бәйле рәвештә) янгынга каршы табигый яисә ясалма барьерлар яисә аермалар белән, шулай ук гамәлдәге янгыннарны локальләштергәндә таяныч линияләре белән эре йомык блокларга бүлү. Аларда гомуми юллар челтәренә керерлек юллар салалар. |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 2.2 | Урман массивлары территория-сендә янгынга каршы табигый барьерлар сайлау | Су баса торган киң тугайлары булган күлләр һәм елгалар, яфраклылар өстенлек иткән урман кишәрлекләре (составы буенча кимендә 7 берәмлек), урманнар һәм янучан материаллар капламаган кишәрлекләр |
| 2.3 | Янгынга каршы ясалма барьерлар һәм аермалар сайлап алу | Тимер юл трассалары һәм автомобиль юллары, электртапшыру линияләре һәм торбаүткәргечләр һ.б.ш. ике яклары буйлап мөмкин булган саен 50-60 метр киңлектәге яфраклы агачлыклар полосасын утырталар. Киртәләрнең гомуми киңлеге - 120-150 метр. Яфраклы полосаларның урманга карап торган тышкы яклары буенча 1,4 метр киңлектәге минполосалар булдыралар, ә әгәр дә яфраклы полосалар янгын куркынычы буенча 1 һәм 2 класслыга карауы кишәрлекләргә якын урнашса - бер-берсеннән 5 -10 метр ераклыктагы ике минполоса булдырыла. Яфраклылар полосалары булдыру мөмкин булмаган ылыслы урман үсентеләре территориясе (урман бүлемтеге сәбәпле) чокырның һәр ягыннан киңлеге 120-150 м булган полосаларда янучан материаллардан (агач материалы чүбеннән, ылыслы шытымнардан, янгын куркынычы булган урманчыклардан, ылыслыларның 1,5-2,0 метрга кадәрле аскы ботакларыннан һәм башкалардан) даими рәвештә чистартылып торыла. Ылыслы урманнардан мондый полосаларны янәшә урнашкан урманнан чиклиләр һәм буйлы юнәлештә һәр 20-30 метр саен 1,4 метр киңлектәге минполосалар белән аералар. Мондый төп каршылыкларның киңлеге (чокыр яки юлларның киңлеге белән берлектә) - 260 - 320 метр. |
| 2.4 | Янгынга каршы өстәмә киртәләр һәм чокырлар булдыру | 2.2 һәм 2.3 пунктларда күрсәтелгән киртәләр тиешле күләмдә булмаган очракта, блок буйлатып йомык божра булдыру өчен аларда юллар һәм һәр ике як буйлап яфраклы полосалар булдырып чокырлар казыйлар |
| 2.5 | Уртача интенсивтагы урман хуҗалыгы алып барыла торган зоналарда урнашкан, янып китүчәнлеге югары булган ылыслыларның кыйммәтле токымнары массивларында планлаштыру | 2-12 мең га (2.1 п. кара) кадәр мәйданлы эре блоклар һәм массивлар барьерлар (чокырлар, уттан каршылыклар) 2.2-2.4 пунктларда каралган тәртиптә 400дән 1600 га кадәр мәйданлы уртача йомык блокларга бүләләр. Шул ук вакытта киң кулланылыштагы (тимер юл, шоссе) юлларның һәр ягы буенча яфраклы полосаларны (хуҗалары көче белән) 30 - 50 м киңлектә, ә башка чокырлар, шул исәптән кварталлардагы урман юллары буйлап һәр ягыннан 10 -15 метр киңлектә булдыралар. Ылыслы яшь агачлыклар булган чокырларга тоташучы аеруча кыйммәтле массивларда (яфраклы полосаларны булдыру мөмкинлеге булмаганда) һәр яктан 100 м киңлектәге полосаларны янучан материаллардан чистарталар һәм, әлеге таблицаның 2.3 п. күрсәтелгәнчә, һәр 20-30 м саен буйлы минеральләштерелгән полосалар ясыйлар. Мондый эчке (өстәмә) яфраклы токым саклагычларының киңлеге 60 - 100 м булырга тиеш, ылыслы токымнарныкы - 200 м, урман юллары буенча (чокырларның һәм урман юлларының киңлеген исәпкә алмыйча) - 20 - 30 м. |
| 2.6 | Яшел зоналарда һәм 1 класслы ылыслы культураларның һәм яшь урман үсентеләренең эре кишәрлекләрен планлаштыру | Аларны 25га мәйданлы блокларга минполосалар яисә юллар ярдәмендә бүләләр, аларда яфраклы яшь агачлардан һәм куаклардан ике яклап 10 м киңлектәге полосалар булдыралар. Аның үзәгеннән гади юл белән каплавычның гомуми киңлеге - 30 метр. Яфраклы полосаларны булдыру мөмкин булмаганда, 100 м киңлектәге полосалардагы ылыслылар чокырына якын урыннарда һәрьяклап янучан материалны юк итәргә, шулай ук 20-30 м саен аркылы минполосалар салырга кирәк (2.3 п. кар.) |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) | |
|---|---|---|---|
| 2.7 | Поселоклар янәшәсендәге ылыслы урманнарны планлаштыру | Урман массивы тирәли янгынга чыдам киңлеге 150 метрдан да ким булмаган яфраклы урман кашаклары булдырыла. Мондый урман кашакларының ике чиге буйлап 2,5 метрдан тар булмаган киңлектәге минполосалар булдырыла. Әгәр дә яфраклы урман кашакларын булдыру мөмкин булмаса, ул вакытта поселокка якын урнашкан ылыслы урман полосаларында 250 - 300 метрлы киңлектә янучан материалларны тулысынча алып бетерәләр һәм алар буйлап һәр 50 метр саен буйлы минполосалар салалар (2.3 п. кара). | |
| 2.8 | Яклаучы миниполосаларны бульдозерлар, тракторлар, туфрак эшкәртүче һәм башка кораллар ярдәмендә туфрак өстендәге каплам төренә һәм куәтенә бәйле рәвештә салганда: | | |
| | - лишайниклардан һәм яшел мүкләрдән<br>- җиләклекләрдән һәм арчаннан<br>- куәтле үлән капламында һәм чүпләнгән урыннарда<br>минималь киңлеге<br><br>- блоклар һәм ылыслы массивлар эчендә<br>(2.1, 2.5 - 2.7 п.п.) | 1.0 км башлап 1.5 км кадәр<br>1.5 км башлап 2.5 км кадәр<br>2.5 км башлап 4.0 км кадәр<br><br>1.4 м (ПКЛ-70 сукасы бер уза)<br>Корылмалар, урман культуралары, табигый шытып чыккан урманнар биләгән мәйданнар тирәсендә, ылыслы, яфраклы урман үсентеләрендә уза торган агач ташу юллары буйларында, миниполосалар дәвамы буларак, булдырылган янгынга каршы барьерларда һәм ылыслы урман үсентеләрендә, шулай ук кирәк булган башка урыннарда | Полосаның киңлеге түбәнлектәге янгын ялкынының мөмкин булган биеклегеннән ике тапкырга артыграк булу хисабыннан чигереп тору сыйфатында хезмәт итәргә мөмкиннәр |
| | - янгын куркынычы булган сезонга калдырылган коры туфракларда урнашкан ылыслы тигез урманнардагы коры туфраклы диләнкеләрдә | Урман әзерләүчеләр урман бүлемтекләрен минполосалар белән әйләндереп ала. Моннан тыш, 25 гектардан артык мәйданлы диләнкеләр 25 гектардан артмаган кишәрлекләргә аркылы минполосалар белән бүленергә тиеш. Агач материалын складлаштыру урыннары шулай ук аерым, йомык миниполосалар белән әйләндереп алына, ә ылыслы урманнарны кисү урыннарында – бер-береннән 5-10 м ераклыкта булган ике шундый полоса белән әйләндереп алына | |
| | - тимер юлларда, шосселарда һәм агач ташу юлларында (үз карамакларындагы оешмалар көчләре белән) | Алар буйларындагы полосаларны (агач ташу өчен – һәр ягыннан 10 м) янгын сезоны эчендә ауган агачлардан, агач чүпләреннән һәм башка тиз кабынып китүчән материаллардан чистартып торыла. Минеральләштерелгән полосаларны чигерелгән полосаларның тышкы ягы буйлап салалар, ылыслы утыртмаларда коры туфракта - бер-берсеннән 5 метр ераклыкта ике минеральләштерелгән полоса салына. Шушындый ук шартларда минполосалар белән юл буйларында яткан шпаллар өемнәрен һәм кар саклау щитларын, агач күперләрне, стационар платформаларны, торак йортларны һәм юлларны карап йөрүчеләр будкаларын әйләндереп алалар, учак ягу рөхсәт ителгән урыннар, урманда ял итү һәм тәмәке тарту урыннары, урманнарда эшләр башкарганда ЯММ саклау урыннары тирәли, янгын куркынычы урман промыселлары мәйданчыклары тирәли (күмер ягу, сагыз, деген эшкәртү һәм башкалар), арадаш һәм төп чәер складлары тирәли, авыл хуҗалыгы җирләре чикләре буйлап әйләндереп алалар | |
| 2.9 | Янгын куркынычы сезонында янгынга каршы аермалар кору: | | |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) | |
|---|---|---|---|
| | - урмандагы үзагач саклыкханәләре тирәли | Саклыкханәләрне ачык урыннарда түбәндәге аралыкта урнаштыралар: яфраклы урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 20 м кадәр, 8 га һәм аннан да күбрәк - 30 м, ылыслы һәм катнаш урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 40 м, 8 га аннан да күбрәк - 60 м.<br>Саклыкка кую урыннары һәм күрсәтелгән янгынга каршы аермалар янучан материаллардан чистартыла | |
| | - торф табу предприятиеләре тирәли | Тирә-яктагы урман массивларыннан 75-100 метр киңлектәге эчке кырыеннан йомык сусыткәргеч каналлы чокырлар белән аералар. Чокыр полосасында ылыслы агачларны, һәм шулай ук 8 метрга кадәр биеклектәге яфраклы агачларны кисәләр һәм бүтән янучан материаллардан чистарталар | |
| 2.10 | Янгынга каршы сулыклар кору: урман янгыннары чыгу мөмкин булган урыннан ерак урнашкан су чыганакларын урнаштыру: | | |
| | Утыртмаларның янгын куркынычы классификациясе | Ераклыгы, км | Бер сулыктан су белән тәэмин ителүче утыртмалар мәйданы, га |
| | 1 | 2 - 4. | 500 |
| | 2 | 2 - 8. | 2000 - 5000. |
| | 3 - 5. | 8 - 12. | 5000 - 10 000. |
| | - янгын сүндерү өчен табигый су чыганакларын әзерләү | Аларга килү юлларын төзекләндерү, янгын автоцистерналары һәм мотопомпалар белән су алу өчен махсус мәйданчыклар җиһазландыру, ә кирәк очракларда сулыкларны тирәнәйтү һәм буалау | |
| | - янгын сүндерү буенча ясалма сулыклар төзү | "Росгипролес" институтының типлаштырылган проектлары буенча, янгын куркынычы югары булган урман массивларында аларда табигый су чыганаклары булмаганда, яхшыртылган автомобиль юллары янында, алардан сулыкларга кадәр килү юллары салынган булырга тиеш | |
| | - янгынга каршы сулыкта нәтиҗәле су запасы | Кимендә 100 м3 елның иң эссе чорында | |
| 2.11 | Урман юлларын кору: | | |
| | - юллар челтәренең гомуми тыгызлыгы (куелыгы) | Кимендә 6 км - 1000 га гомуми мәйданга, шул исәптән янгын куркынычы түбән булган һәм янгын тиз таралмый торган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда юллар челтәре куелыгы 6 км/мең га рөхсәт ителә, янгын куркынычы югары булган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда ул бу күрсәткечтән артык булырга тиеш | |
| | - урман хуҗалыгы юллары | Урман янгыннары белән көрәш өчен түгел, урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен кирәкле юллары булган кишәрлекләрдә урман хуҗалыгы интенсив алып барыла торган үзләштерелгән урманнарда корыла. 5 категория гомуми файдаланудагы юлларга тиңләштерелә һәм 3 типка бүленә.<br>1 тип урман хуҗалыгы юллары: бер полосалы, полосаларның гомуми киңлеге - 8 м, юл кырые киңлеге – 1,75 м.<br>Исәпләп чыгарылган хәрәкәт тизлеге - 60 км/сәг, сикәлтәле урыннарда 40 км/сәг кадәр кими | |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| | - янгынга каршы юллар | Урман хуҗалыгы буенча 3 типлы билгеләнеш юлларына карыйлар, җир капламының киңлеге - 4,5 м, юл кырыйлары киңлеге - 0,5 шәр метр. Аларны бар булган урман юллары челтәрләренә өстәмә коралар, автотранспорт янгын буенча куркыныч саналган урыннарга һәм сулыкларга үтеп керә алсын өчен. Аларга шулай ук табигый грунт юллары, квартал урман юллары һәм төрле трассалар кертелә |
| 2.12 | Көчләрне һәм чараларны янгын сүндерү урынына илтеп җиткерү вакыты | Янгын күренгәннән соң 3 сәгатьтән дә артмаска тиеш. Янгын куркынычы югары булган кишәрлекләр өчен А - 0,5 – 1,0 сәгатьтән дә артмаска тиеш |
| 2.13 | Янгын урынына бару юлына китә торган вакытны исәпләп чыгарганда юлларның, сукмакларның яисә җәяүлеләр узып йөрерлек урыннарның сикәлтәлеген һәм җир өсте рельефын исәпкә алу өчен аларны озынайту коэффициентлары | |
| | - 1 тип урман хуҗалыгы юллары өчен<br>- 3 тип (янгынга каршы) урман хуҗалыгы юллары өчен | Тигез җирлектә - 1,1; таулыклы җирлектә - 1,25<br><br>Тигез җирлектә - 1,15; таулыклы җирлектә - 1,65 |
| 2.14 | Янгын сүндерүче хәрәкәте тизлеге | Гадәттә 1 - 3 км/сәг (автомобиль юлыннан коралларын күтәреп янгын урынына килгәндә) |
| 2.15 | Җир өстендә патруль уздыру маршрутларын планлаштыру: | |
| 2.15.1 | Урнаштыру урыннары | Агач-куаклар аз булган урыннарда (15% һәм аннан да түбән) һәм территория буйлап вак урман кишәрлекләре урнашканда. Кыр саклау урман үсентеләрен, чокырлар һәм балкалар буйлап үсентеләрне саклаганда яшел зоналар урманнарында, урман паркларында һәм башкаларда. Стационар күзәтү пунктларыннан күзәтүгә һәм авиапатрульгә өстәмә рәвештә – агач материалы әзерләү урыннарында, төрле объектлар төзү урыннарында һәм трассаларда, ял зоналарында, елгалар һәм күлләр ярлары буйлап, янгын куркынычы югары булган урыннарда |
| 2.15.2 | Патруль уздыру маршруты озынлыгы | Транспорт төренә, юллар торышына һәм саклана торган кишәрлекне карап чыгу санына бәйле рәвештә |
| 2.15.3 | Янгын куркынычы булган кишәрлекләрдә урман янгынына патруль уздыру хәрәкәте тизлеге | |
| | - мотоцикллар, машиналар һәм башка транспорт чаралары | Гомуми файдаланудагы шоссей юллары буйлап - 30 км/сәг артык, урман юллары буйлап -15-20 км/сәг. Урмансыз киңлекләрдә юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре нигезендә арттырылырга да мөмкин |
| | - моторлы көймәләрдә һәм катерларда | Су юллары буйлап - 15 - 20 км/сәг кысаларында |
| 2.16 | Җирлектә урман янгыннары чыгуга күзәтчелек пунктларын урнаштыру нормативлары: | |
| 2.16.1 | Вышкаларның әйләнә-тирәлектән биеклегенә бәйле рәвештә максималь күзәтү радиусы (бик яхшы күренүчәнлек шартларында):<br>– вышкаларның биеклеге, м<br>– күзәтү радиусы, км | 10 15 20 25 30 35 40<br>12 15 17 19 21 23 24 |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 2.16.2 | Вышкаларны оптималь урнаштыру | Калку җирләрдә – бер-берсеннән 10-12 км. ерак түгел, ә тигез җирдә – 5-7 км. Янгын чыгуның иң ихтимал төбәгендә анның урынын 2-3 пункттан покмак үлчәү инструменты (буссоль һ.б.ш.) һәм бинокль ярдәмендә төгәл ачыклау исәбеннән. ПТУ-59 телевидение корылмасының күзәтү радиусы 8 км кадәр (күзәтче югары күтәрелмичә дә). Видеоконтроль җайланмасын һәм идарә пультын мачтадан 1 км кадәр ераклыктагы теләсә нинди ябык бинага урнаштыралар, ә кабельнең озынлыгы 1 км алып 3 км кадәр булганда линия көчәйткече тоташтырырга кирәк. |
| 2.16.3 | Вышкаларны (чаралар җитешмәгәндә) рөхсәт ителгәнчә урнаштыру | 35 м биеклеге типлаштырылган металл вышка начар һава шартларында 10-12 км, ә яхшы шартларда 20 км кадәр араны күрергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә аларны минималь күренүчәнлектән икеләтә күбрәк ераклыкта (20-24 км) урнаштыралар. ПТУ-59 телевидение корылмасының күзәтү радиусы - 10-15 км кадәр. |
| 2.16.4 | Күзәтү вышкаларының хезмәт итү вакыты:<br>– агач – 10 ел<br>– металл – 30 ел | Вышкаларның бәясе бер үк диярлек |
| 2.17 | Янгын-химия станцияләрен планлаштыру һәм урнаштыру нормативлары: | |
| 2.17.1 | ЯХС оештыруның максатка ярашлылык күрсәткечләре (урманнарны янгыннан саклауны оештыру планнарына ярашлы рәвештә) | Беренче чиратта, беренче өч класслы янгын куркынычына караган кыйммәтле урманнары, һәр 1000 га урман фондына гомуми озынлыгы 6 км ким булмаган транспорт юллары һәм су юллары булган урман хуҗалыкларында |
| 2.17.2 | Һәр ЯХС тирәсендә беркетелә торган урманнар территориясе радиусы:<br>– юл челтәрләре яхшы булганда<br>– канәгатьләнерлек булганда<br>– сыйфатсыз булганда | <br><br>40 км. күбрәк түгел<br>кимендә 30 км<br>кимендә 20 км |
| 2.17.3 | ЯХС бинасына урын сайлау | Урманның янгын куркынычлы һәм янучан кишәрлекләренә мөмкин кадәр якында, беркетелгән территория үзәгендә, урман хуҗалыгы (урманчылык) конторасына, цехларга, түбәнге агач саклыкханәләренә, күп кешеләр эшли торган бүтән хуҗалыкларга, төп транспорт юлларына, сулыкларга якын җирдә. Берничә варианттан бу шартлардагы иң мөһим таләпләрнең күпчелегенә туры килә торганын сайлыйлар. Техника һәм урман янгыны бригадалары гадәттә бер пунктта туплана, ләкин кирәк булганда ЯХС тармаклары ике я күбрәк пунктта да урнашырга мөмкин (зур булмаган ерак, янгын куркынычлы урманчылыкларда яисә аерым ЯХС оештыру максатка ярашсыз булган аймакларда). |
| **3.** | **Урманнарны янгыннардан авиация патруле белән саклау эшләрен планлаштыру нормативлары** | |
| 3.1 | Төбәктә маршрут линияләрен урнаштыру:<br>– авиация патруле белән саклаганда | Бер-берсенә һәм күзәтелә торган кишәрлекнең озын ягына параллель итеп<br>Бер-берсеннән 60 км ерак түгел, ә маршруттан күзәтү кишәрлеге чигеннән – 30 км ерак түгел |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 3.2 | Очыш биеклеге:<br>– урманнарны янгыннан авиация патруле белән саклаганда | Оптималь биеклек – 600 м. Һәр аерым очракта куелган бурычның үзенчәлекләре, җирле очыш шартлары, аппаратның техник характеристикасы, аның герметик кабинасы булу-булмау белән билгеләнә (АН-24 самолетыныкы – 7000 м кадәр). |
| | – авиация белән патрульләүне урманнарның санитар торышына гомуми күзәтчелек белән бергә алып барганда | Урманның аерым кишәрлекләрен җентекләп күзәтү өчен самолетта очыш 200 м кадәр, вертолетта очыш 100 м кадәр түбәнәя (урындагы рельефны һәм анда биек элементлар булуны исәпкә алып). |
| 3.3 | Авиация белән партульләгәндә янгын урынын билгеләү төгәллеген бәяләү: | |
| | – бик яхшы<br>– яхшы<br>– канәгатьләнерлек<br>– начар | Ялгышсыз<br>0.5 км кадәр ялгыш белән<br>0.5 км алып 1.0 км кадәр ялгыш белән<br>1 км зуррак ялгыш белән |
| 3.4 | Янгын мәйданын югарыдан билгеләүнең төгәллеге | 30%тан артмаган ялгышу рөхсәт ителә |
| 3.5 | Парашютчы-янгын сүндерүчеләрне төшерү урыннарына һәм андагы шартларга таләпләр: | |
| | – очыш биеклеге<br><br>– җир өстендәге җил тизлеге<br>– ачык җиргә төшү мәйданнарының үлчәмнәре<br><br>– сикерү тыела | 800 м түбән түгел (парашют тибына карап)<br>Кимендә 8 м/с<br>Кимендә 75 x 75 м (урман яланнары, кипкән сазлыклар, басулар һ.б., ә алар булмаганда – биеклеге 20 м кадәр булган куаклар һәм агачлар)<br>Кисентеләргә, урман янган җирләргә, җил еккан агачлыкларга, шулай ук югары вольтлы линияләр тирәсенә. |
| 3.6 | Авиация белән сакламалы урманнар территориясендә урман хуҗалыклары башкара торган эш урыннары һәм кишәрлекләр планлаштыру нормативлары: | |
| 3.6.1 | Авиация хәбәрләрен кабул итү пунктларын оештыру:<br>– урнашу урыны<br><br><br><br>– аларны патруль самолетлары (вертолетлары) өчен тану билгеләре белән җиһазлау | Урманчылык , ЯХС кишәрлек урманчылыклары, авыл хакимиятләре, колхоз, совхоз конторлары янында, телефоны һәм радиоэлемтәсе булган торак пунктларда<br>Кизү тору оештырылган өй түбәләренең ике кыегында да ак майлы буяу яисә бур белән, гарәп цифрлары белән пунктның номеры языла. Цифрларны яңа ышкылган тактадан да ясарга мөмкин.<br>Саннарның зурлыгы: биеклеге буенча - 2.5 - 3.0 м, киңлеге буенча - 0.75 м |
| 3.6.2 | Патруль самолетларына һәм вертолетларына яхшы ориентлашу шартлары булдыру максатыннан өстәмә-ясалма ориентирлар кору: | |

<table>
<tr><th>№ п/п</th><th>Күрсәткечләр</th><th colspan="2">Нормативлар (оптималь күрсәткечләр)</th></tr>
<tr><td></td><td>– ориентирларның типлары һәм урыннары<br><br>– аларга тану билгесе кую</td><td colspan="2">Урман территориясендә булган корылмалар (кордоннар, аучы өйләре, бараклар һ.б.ш.). Алар булмаса, ачык урыннарда (кимендә 100х100 м) җирдә каезланган киртәләрдән (каезланмаган каен киртәләрдән) куышлар, ике кыеклы түбәләр корыла яисә 7 м кадәр биеклектәге нык утыртылган колгаларга ак флаглар эленә.<br>Корылма яисә куыш түбәсенең ике кыегына да, бөтен озынлыгына, квартал (аймак) номеры яки патруль картасының шартлы шакмагы төшерелә. Билгенең биеклеге – кимендә 3 м, иңе – кимендә 0.75 м.</td></tr>
<tr><td>3.6.3.</td><td colspan="3">Вертолетлар эшли торган төбәкләрдә төшеп утыру мәйданчыклары сайлау һәм җиһазлау:</td></tr>
<tr><td></td><td>– тәгаенләнеше<br><br>– урнашу урыны</td><td colspan="2">Ягулык салу, янгын сүндерү көчләрен һәм чараларын алу һәм төшерү, хәбәрләр кабул итү һ.б.ш. пунктлары<br>Янгыннар еш кабына торган яисә янгын куркынычы югары булган урман масивларында</td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td rowspan="2">– вертолетлар күтәрелә һәм төшә торган мәйданчыкларның минималь үлчәмнәре<br>(якынлашуны исәпләүнең эш мәйданы)</td><td>Вертолет типлары</td><td>Тигез җирлек, м</td></tr>
<tr><td>МИ - 6<br>МИ - 8<br>МИ - 4<br>МИ - 2<br>МИ - 1А</td><td>50 х 50<br>30 х 30<br>30 х 30<br>16 х 16<br>16 х 16</td></tr>
<tr><td></td><td>– күтәрелү һәм төшү (һавадан килү) юнәлешендәге комачаулар<br>– комачауларның урнашуы (МИ-2, МИ-1А, Ка-26 өчен – 0.5 м.дан биегрәк булса; МИ-6, МИ-8, МИ-4 өчен – 1 метрдан биегрәк булса)</td><td colspan="2">Барлык комачаулар мәйданчык чигеннән үз биеклегеннән икеләтә ераграк торырга тиеш<br><br>Мәйданчык чигеннән кимендә 10 м ераклыкта</td></tr>
</table>

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы РФ Урман кодексының 53 статьясына ярашлы рәвештә тәэмин ителә, анда янгын куркынычсызлыгының төп чаралары саналган.

Бу чаралар арасында беренче булып урманнарны янгыннан саклауны оештыру аталган (элегрәк урман законнарында "урманнарның янгынга каршы корылышы" термины кулланылган).

Урманнарны янгынга каршы кору дигәндә беренче чиратта урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче инфраструктура төзү аңлана.

Тиешле урман инфраструктурасы объектларына урман юллары, самолет һәм вертолет утырту мәйданчыклары, ярузлар, янгынга каршы ерымнар, минеральләштерелгән полосалар, янгын сулыклары һ.б.ш. керә.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче урман инфраструктурасы турында гомуми күзаллауны урманнарда янгын профилактикасы буенча киңәшләр һәм урман янгыны хезмәтләренең эш регламентлары бирә (Федераль урман хуҗалыгы хезмәте тарафыннан (17.11.1997) һәм ОСТ 56-103-98 белән расланган, анда урманнарда янгын

куркынычсызлыгы дип аларда янгын чыгу мөмкинлеген минимумга кадәр кимәтә торган торышны һәм янгынны уңышлы бетерү шартларын тәэмин итү аңлана.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен янгынга каршылык әһәмиятендәге юллар гына кулланылмый. Теләсә нинди урман юллары аларны янгын куркынычсызлыгы максатларында файдалану мөмкинлеген күздә тоткан типлаштырылган проектларга ярашлы рәвештә корылырга тиеш.

"Вәкаләтләрне чикләүне камилләштерү уңаеннан Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 31.12.2005 ел, №199-ФЗ Федераль закон белән урман янгыннарын сүндерүне оештыру функцияләре РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылды.

Россия Федерациясе УК 1 өлешенең 4 пунктына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе урман янгыннарын сүндерүне оештыруны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшыра.

Шулай итеп, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына ярашлы рәвештә, урман янгыннарын сүндерүне оештыру РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан башкарыла.

Арендалы урман кишәрлекләрендә янгынга каршы оештыру эшләрен, урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү системасын һәм чараларын карап тоту һәм эксплуатацияләүне урманнарны үзләштерү проектлары нигезендә аларның арендаторлары тәэмин итәргә тиешле.

30.06.2007 ел, №417 РФ Хөкүмәте карары белән "Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре" кабул ителгән. Бу норматив-хокукый актта төрле дәрәҗәдәге хакимият органнарының урманнарны янгыннардан саклау өлкәсендәге вәкаләтләре, урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр билгеләнә.

15.5 таблица

Янгынга каршы корулар буенча чаралар күләме

| № п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ревиз. чорында | 1 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **1.** | **Кисәтү чаралары** | | | |
| 1.1 | Даими күргәзмәләр | данә | **1** | **-** |
| 1.2 | Даими элмә такталар | данә | 1 | - |
| 1.3 | Кисәткеч аншлаглар | данә | 30 | 3 |
| 1.4 | Авыл хуҗалыгы оешмалары вәкилләре белән даими рәвештә кирәк булган саен киңәшмәләр уздыру | данә | 10 | 1 |
| 1.5 | Контроль постларын оештыру | данә | 4 | 4 |
| 1.6 | Массакүләм ял итү урыннарында аншлаглар урнаштыру | данә | 2 | - |
| 1.7 | Алмашынып торучы таблолы аншлаглар урнаштыру | данә | 2 | - |
| 1.8 | Матбугатта һәм радиодан чыгыш ясау | лекцияләр | 10 | 1 |
| 1.9 | Ял һәм тәмәке тарту урыннарын оештыру | данә | 10 | 1 |
| **2.** | **Янгыннар таралуны чикләү буенча чаралар** | | | |
| 2.1 | Янгынга каршы киртәләр, чокырлар булдыру | км | - | - |
| 2.2 | Культуралар, ылыслы яшь урманлыклар тирәли һәм юллар буйларында минеральләштерелгән полосалар кору | км | 50 | 5 |
| 2.3 | Урман ызаныннан башлап юл буйлары һәм урман поселоклары буйлап минеральләштерелгән полосалар кору | км | 50 | 5 |

| № п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ревиз. чорында | 1 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 2.4 | Янгынга каршы чокырларны карап тоту | км | - | - |
| 2.5 | Минеральләштерелгән полосаларны карап тору | км | 400 | 40 |
| **3.** | **Юл төзелеше** | | | |
| 3.1 | Янгынга каршы юллар төзү | км | 5 | 0,5 |
| 3.2 | Күперләр төзелеше | данә | 1 | - |
| 3.3 | Янгынга каршы билгеләнештәге юлларны төзекләндерү | км | 20 | 2 |
| 3.4 | Урман юлларын төзү | км | 5 | 0,5 |
| **4.** | **Элемтә оештыру** | | | |
| 4.1 | Элемтә линияләрен төзү | км | - | - |
| 4.2 | Радиостанцияләр (кәрәзле элемтә) булдыру | данә | 5 | 1 |
| **5.** | **Күзәтчелек-сак хезмәте** | | | |
| 5.1 | Янгынга каршы вакытлы каравылчылар яллау | кеше | 2 | 2 |
| **6.** | **Янгыннарга каршы көрәш чаралары** | | | |
| 6.1 | I типлы ЯХС карап тоту | данә | 1 | 1 |
| 6.2 | Янгын инвертарьләре пунктларын оештыру | данә | 3 | 3 |
| 6.3 | Ясалма сулыклар төзү | данә | - | - |
| 6.4 | Сулыкларга керү юллары (пирслар) булдыру | данә | 3 | 3 |
| 6.5 | ИЯД булдыру | күләм/кеше | 2/12 | 2/12 |
| **7.** | **Янгыннаргы каршы кораллар сатып алу** | | | |
| 7.1 | Автомашина ГАЗ-66, УАЗ-469 | данә | - | - |
| 7.2 | Капрон янгын җиңсәсе | п.м. | 200 | 20 |
| 7.3 | Мотопомпалар | данә | 1 | - |
| 7.10 | Бензопычкылар | данә | 2 | - |
| 8 | Янгын куркынычы мониторингы | мең. га | 12,9 | 12,9 |

15.6 таблица

## Урман хуҗалыгын алып баручы урман фондын биләүчеләрне урман янгыннарын сүндерү җайланмалары һәм чаралары белән тәэмин итү нормалары

| № п/п | Җайланма, инвентарь һәм янгын сүндерү чаралары | Үлч. берәмл. | Урманчылык | Кишәрлек урманчылыгы | Урман хуҗалыгы кишәрлеге | Карап чыгу |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Югары үтеп керешле бортлы автомобильләр (ГАЗ-66, УАЗ-3301, "Урал" һ.б.) яки вездеходлар (ЛПМ - 0,1 һ.б.) | данә | 1 | - | - | - |
| 2. | Күкмә җиһазландырылган мотопомпалар (МН-13\60 һ.б.) яки кечкенә габаритлы (МЛН-3\0,3 Л-1\0,75,МЛВ-1,МЛВ-2,МЛП-0,2 һ.б.) | данә | 2-3 | 1 | - | - |
| 3. | Су куа торган җиңсәләр (Д=26, 51 мм) | пог. м. | 600 | 300 | - | - |
| 4. | Туфрак эшкәртә торган кораллы тракторлар (ПКЛ-70, ПЛ-1,2 һ.б.) | данә | 1 | 1 | - | - |
| 5. | Резин сыешлыклар (РДВ - 1500 һ.б.) | данә | 2 | 1 | - | - |
| 6. | Ут кабыза торган | данә | 2-4 | 2 | - | - |

| № п/п | Җайланма, инвентарь һәм янгын сүндерү чаралары | Үлч. берәмл. | Урманчылык | Кишәрлек урманчылыгы | Урман хуҗалыгы кишәрлеге | Карап чыгу |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | җайланмалар (АЗ һ.б.) | | | | | |
| 7. | Урман ранецлы ут сүндергечләр (РЛО-М һ.б.) | данә | 10-15 | 5 | - | - |
| 8. | Бензин пычкылары ("Дружба", "Урал" һ.б.) | данә | 2-8 | 1 | - | - |
| 9. | Торфлы баганалар (ТС-1, ТС - 2 һ.б.) | данә | 2 | - | - | - |
| 10. | Кул инструментлары: - көрәкләр | данә | 30 | 20 | 10 | 6 |
| | - китмәннәр | данә | 10 | 5 | 5 | - |
| | -тимер тырмалар | данә | 10 | 5 | 5 | 5 |
| | -балталар | данә | 10 | 5 | 4 | 3 |
| | -аркылы пычкылар | данә | - | - | 4 | 3 |
| 11. | Эчәр сулар өчен билгеләнгән 20 литрлы бидоннар яисә канистрлар | данә | 2-4 | 1-2 | 1 | 1 |
| 12. | Су өчен 10-12 литрлы тимер чиләкләр / каен сыешлыклары | данә | 10 | 5 | 3 | 3 |
| 13. | УКВ һәм КВ диапазонлы радиостанцияләр ("Кактус, "Ромашка", "Карат-М", һ. б.). Радиоэлемтә оештырылганда | данә | 2-3 | 1 | - | - |
| 14. | Су өчен кружкалар | данә | 5-10 | 5 | 5 | 4 |
| 15. | Беренче ярдәм аптечкасы | данә | 3-4 | 1-2 | 1 | 1 |
| 16. | Индивидуаль яра бәйләү пакетлары | данә | Янгын сүндерүдә катнашучылар санына карап | | | |
| 17. | Кизү тору буенча махсус кием (куртка, итекләр, җиңсәләр), саклагыч күзлекләр, респираторлар | ком. | Үзәк предприятие, урманчылык булганда янгын сүндерү командасы әгъзалары санына карап | | | |

## 2.17.2 Урманнарны зарарлы организмнардан, урман чирләреннән һәм корткычларыннан саклау РФ Урман кодексының 54 ст. ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла

Урманнарны зарарлы организмнарда саклау – урманнарның тотрыклыгын саклауга, урманнар юкка чыгу, зарарлану, көчсезләнү, пычрану аркылы килә торган зыянны булдырмауга, урман чирләреннән, табигый һәм антропоген характерлы башка зарарлы йогынтылардан килә торган югалтуларны киметүгә юнәлтелгән чаралар системасы ул.

РФ УК 54 ст. 2 өлешендә урманнарны карантин объектларына кертелгән зарарлы организмнардан саклау 15.07.2000 ел, №99-ФЗ Федераль законга ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла дип билгеләнгән.

Аталган Федераль закон нигезендә үсемлекләр карантины – Россия Федерациясе территориясендә үсемлекләрне һәм үсемлекләрдән алына торган продукцияне карантин объектларыннан саклау буенча чаралар системасын күздә тоткан хокукый режим булып тора.

Карантин объектлары дип зарарлы, Россия Федерациясе территориясендә булмаган яки аларның таралышы чикләнгән организмнар

(ягъни үсемлекләргә һәм үсемлекләрдән алына торган продукциягә зыян салырга сәләтле теләсә кайсы төргә, сортка яки биологик типка караган үсемлек, хайван яки чир тудыручы организм) санала.

Урман корткычы булган күпчелек хайваннар бөҗәкләр классына, азрак өлеше умырткалыларга керә, башлыча кимерүчеләр, тояклы дендрофаглар һ.б.

Туклану характерына һәм яшәү урынына бәйле рәвештә хайваннар берничә категориягә бүленә:

- ылыс кимерүчеләр (нарат ефәкчесе, монашенка ефәкчесе, нарат кисмәне һ.б.) һәм яфрак кимерүчеләр (парсыз ефәкче, алтын корсак, яфрак бөтергеч һ.б.) таза үсемлекләргә һөҗүм итәләр. Уңайлы шартларда алар күпләп үрчеп китеп зур территорияләргә тарала һәм аерым агачларны да, утыртмаларны да үсештән туктатып, нык көчсезләндереп һәм арытаба корытып, урманнарга зур зыян сала;
- кәүсә корткычлары (кайры кисмәне, агач күбәләге, пыялач күбәләк, нарат кайрысы кандаласы һ.б.) көчсезләнгән агачларга һөҗүм итәләр. Юкәрдә, камбийда һәм үзагачта тишекләр тишеп, алар агачны корытырга һәм аны очсызландырырга мөмкиннәр;
- тамыр корткычлары һәм туфракта яшәүче корткычлар (май коңгызы, чертләвек, кара кабык, тамыр көпшәге һ.б.) барыннан элек урман культуралары питомниклары һәм кыр саклау полосалары өчен куркынычлы.
- Җимеш һәм орлык корткычлары (бөҗәкләрнең күп төрләре), агач токымнарының, куакларның һәм башка урман үсемлекләренең генератив органнарын зарарлыйлар, аларның табигый яңарышын тоткарлыйлар.

Урман үсемлекләренең гөмбәләр, бактерияләр, вируслар һәм башка патоген организмнар китереп чыгара торган чирләре әйләнә-тирәлек белән мөнәсәбәттә уза торган һәм үсемлекләрнең зыянлаган органнарында метаболизм бозылу, анатомик һәм морфологик үзгәрешләр белән бара торган катлаулы процесс булып торалар. Урман үсемлекләренең чирләре еш кына шактый мәйданнарда урман һәлак булуга китерә.

Үсемлекләрнең йогышлы һәм йогышлы булмаган чирләре була. Йогышлы чирләрне, кагыйдә буларак, микроорганизмнар китереп чыгара, алар чирле үсемлектән таза үсемлекләргә күчәргә мөмкиннәр. Йогышлы булмаган чирләр үсемлекләр өчен уңайсыз берничә экологик фактор булганда барлыкка киләләр.

Урман үсемлекләренең түбәндәге чирләре була:

- шытым һәм чәчкен чирләре (ак күгәрек, имән ак куныгы, нарат һәм чыршыда карсыман щютте, нарат һәм чыршы ылыслары тутыгы һ.б.ш.);
- сеңерчә чирләре (элмә токымнарының голланд чире, имән сеңерчәләре микозы);
- рак чирләре (сумалалы рак, нарат һәм ак чыршының тутыклы рагы һ.б.ш.);
- тамыр һәм аскы өлештәге черүләр (тамыр губкасы, Швейниц ку гөмбәсе һ.б.);
- агач кәүсәсе черекләре (нарат, чыршы, карагай һәм имән көпшәкләре,

имән һәм усак мәшкәләре һ.б.ш.);

• тубырчык, җимеш һәм орлык чирләре (имән чикләвеге һәм каен орлыгы мумияләнү, чыршы тубырчыгы тутыгы һ.б.ш.).

Урман үсемлекләре чирләрен, урманнарның, урман ресурсларының һәлакәтен яисә зыянлавын булдырмау максатында урманнарны зарарлы организмнардан саклауга (урманнарда аларның чыганакларын ачыклауга, ул чыганакларны профилактикалау, локальләштерү һәм бетерүгә) юнәлтелгән чаралар күрергә кирәк.

15.7 таблица

**Урманнарны яклау чараларының еллык күләме**

| № п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Проектланган | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Урман патологиясе ягыннан тикшерү | га | 100 | |
| 2. | Туфрак казулар | чокырмлар | 30 | |
| 3. | Яңа киселгән агачларны (аучылык агачларын) сайлау | м3 | - | барлыкка килүенә карап |
| 4. | Питомникларга профилактик сиптерүләр (серкәләндерүләр) | га | 2 | барлык чәчүлек мәйданында |
| 5. | Орлыкларны агулау | га | 5 | барлык чәчүлек орлыклар |
| 6. | Җир өстендәге юк итү чаралары | га | - | зарарлану чыганаклары барлыкка килүгә карап |
| 6.1 | ш.и. химик көрәш чаралары | га | - | - |
| 7. | **Биологик көрәш чаралары** | | | |
| 7.1 | Оялар әзерләү | данә /га | 30/50 | |
| 7.2 | Ояларны рәтләү | данә | 10 | |
| 7.3 | Кырмыска ояларын киртәләү | данә | 5 | |
| 7.4 | Кырмыска ояларын күчерү (бүлеп чыгару) | оялар | 2 | |
| 7.5 | Аттрактант тозакларын куллану | га | 5 | |
| 8. | **Оештыру-хуҗалык чаралары** | | | |
| 8.1 | Корткыч һәм авыру чыганаклары барлыкка килүне күзәтеп тору | мең га | 12,9 | урманчылыкның барлык мәйданын даими карап тору |
| 8.2 | Сак покмакларын оештыру | данә | 1 | |
| 8.3 | Урманны саклау буенча лаборатория җайланмаларын, күрсәтмә пособиеләрне, әдәбият сатып алу | сум | 5000 | |
| 8.4 | Урман саклауны пропагандалау | сум | 5000 | |
| 9. | Урманнарны чүпләрдән чистарту | га | 100 | |

## 2.17.3 Урманнарны кабат җитештерүгә карата таләпләр (урман торгызу, урман үрчетү, урманнарны карап тоту буенча чаралар үткәрүнең нормативлары, параметрлары һәм вакытлары)

Яшь агачларны карап тоту һәм урманнарны карап тоту буенча үзагач белән бәйле булмаган бүтән чараларның нормативлары һәм параметрлары

16 таблица

| Урманнарны карап тоту төрләренең исеме | Кишәрлек урманчылыгы исеме | Хуҗалык | Агач токымы | Мәйданы, | Кисеп ташланучы запас, м3 | Кабатланучанлык чоры ел | Ел саен була торган күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Мәйданы,га | Кисем ташланучы запас, куб/м. | |
| | | | | | | | | гомуми | 1 гектардан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| **Урманнарны карап тоту буенча кисүләр, шул исәптән:** | | | | | | | | | |
| тоныкландырулар | Лубян | Ылыслы | Нарат Чыршы | 248 | 1520 | 3-6 | 43 | 268 | 6 |
| тазартулар | Лубян | | | 522 | 8530 | 8-12 | 61 | 992 | 16 |
| тоныкландырулар | Лубян | Каты яфраклы | Биек кәүсәле имән | 5 | 30 | 3-5 | 1 | 6 | 6 |
| тазартулар | Лубян | | | - | - | - | - | - | - |
| Урманнарны агроурманмелиоратив чаралар үткәрү юлы белән карап тоту | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |
| **Урманнарны карап тоту буенча бүтән чаралар, шул исәптән:** | | | | | | | | | |
| кыйммәте аз булган урман утыртмаларын реконструкцияләү | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |
| агач токымнарының җимеш бирүен карап тоту | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |

16 таблица дәвамы

| Урманнарны карап тоту төрләренең исеме | Кишәрлек урманчылыгы исеме | Хуҗалык | Агач токымы | Мәйданы, | Кисеп ташланучы запас, м3 | Кабатланучанлык чоры ел | Ел саен була торган күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Мәйданы,га | Кисем ташланучы запас, куб/м. | |
| | | | | | | | | гомуми | 1 гектардан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| агачларның ботакларын кискәләү | Лубян | - | - | | | | - | - | - |
| урманнарга ашлама кертү | Лубян | - | - | | | | - | - | - |
| урман кашакларын карап тоту | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |
| куаклыкларны карап тоту | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |
| кирәкле булмаган агач үсемлекләрен бетерү юлы белән урманнарны карап тоту | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |
| бүтән чаралар | Лубян | - | - | - | - | - | - | - | - |

16.1 таблица

**Урманнарны кабат җитештергәндә урманнарны карап тоту буенча үзагач әзерләүгә бәйле булмаган проектланучы төрләр һәм ел саен мөмкин булган күләмнәр**

| Токымы: | Мәйданы, га | Кисеп ташланучы запас, куб/м. | Кабатланучанлык вакыты, ел | Ел саен була торган күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәйданы,га | Кисеп ташланучы запас, куб/м. | |
| | | | | | гомуми | 1 гектардан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| **Саклык урманнары<br>Карап тоту төре - тоныкландырулар** | | | | | | |
| Нарат | 30 | 180 | 3-5 | 6 | 36 | 6 |
| чыршы | 14 | 60 | 4-6 | 2 | 10 | 4 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **44** | **240** | | **8** | **46** | **5** |
| **Җәмгысе тоныкландырулар** | **44** | **240** | | **8** | **46** | **5** |
| **Карап тоту төре - тазартулар** | | | | | | |
| Нарат | 49 | 810 | 8-12 | 5 | 81 | 17 |
| чыршы | 8 | 120 | 8-10 | 1 | 15 | 14 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **57** | **930** | | **6** | **96** | **16** |
| **Җәмгысе тазартулар** | **57** | **930** | | **6** | **96** | **16** |
| **Саклык урманнары буенча барлыгы** | | | | | | |
| **Ылыслы** | **101** | **1170** | | **14** | **142** | **12** |
| **Җәмгысе** | **101** | **1170** | | **14** | **142** | **12** |
| **Эксплуатация урманнары<br>Карап тоту төре - тоныкландырулар** | | | | | | |
| Нарат | 42 | 270 | 3-5 | 9 | 54 | 6 |
| чыршы | 157 | 1010 | 4-6 | 26 | 168 | 6 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **204** | **1280** | | **35** | **222** | **6** |
| Б/кәүсәле имән | 5 | 30 | 3-5 | 1 | 6 | 6 |
| **Каты/яфр. җәмгысе** | **5** | **30** | | **1** | **6** | **6** |
| **Җәмгысе тоныкландырулар** | **209** | **1310** | | **36** | **228** | **6** |
| **Карап тоту төре - тазартулар** | | | | | | |
| Нарат | 114 | 2170 | 8-12 | 11 | 217 | 19 |
| чыршы | 351 | 5430 | 8-10 | 44 | 679 | 15 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **465** | **7600** | | **55** | **896** | **16** |
| **Җәмгысе тазартулар** | **465** | **7600** | | **55** | **896** | **16** |
| **Эксплуатация урманнары буенча барлыгы** | | | | | | |
| **Ылыслы** | **669** | **8880** | | **90** | **1118** | **13** |
| **Каты/яфр.** | **5** | **30** | | **1** | **6** | **6** |
| **Җәмгысе** | **674** | **8910** | | **91** | **1124** | **13** |
| **Барлыгы<br>Карап тоту төре - тоныкландырулар** | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Нарат | 77 | 450 | | 15 | 90 | 6 |
| чыршы | 171 | 1070 | | 28 | 178 | 6 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **248** | **1520** | | **43** | **268** | **6** |
| Б/кәүсәле имән | 5 | 30 | | 1 | 6 | 6 |
| **Каты/яфр. җәмгысе** | **5** | **30** | | **1** | **6** | **6** |
| **Җәмгысе тоныкландырулар** | **253** | **1550** | | **44** | **274** | **6** |
| **Карап тоту төре - тазартулар** | | | | | | |
| Нарат | 163 | 2980 | | 16 | 298 | 18 |
| чыршы | 359 | 5550 | | 45 | 694 | 15 |
| **Ылыслылар җәмгысе** | **522** | **8530** | | **61** | **992** | **16** |
| **Җәмгысе тазартулар** | **522** | **8530** | | **61** | **992** | **16** |
| **Барлыгы** | | | | | | |
| **Җәмгысе** | **775** | **10080** | | **105** | **1266** | **13** |

17 таблица

## Урман торгызу һәм урман үрчетү буенча чараларның нормативлары һәм параметрлары

Мәйданы, га

| Күрсәткечләр | Урман үсемлекләре белән капланмаган урманнар | | | | Реконструкция фонды | Киләсе чорда тоташ кисүләр буенча диләнкеләр | Тоташ санитар кисүләр | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Көекләр һәм һәлак булган утыртмалар | Кисеп атылган урыннар | Бушлыклар һәм агачсыз урыннар | Җәмгысе | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урман торгызуга мохтаҗ җирләр - Барлыгы: | 4 | 99 | 6 | 109 | 9 | 670 | 39 | 827 |
| Шул исәптән токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | 4 | 64 | 5 | 73 | 9 | 280 | 23 | 385 |
| Каты яфраклы | | | 1 | 1 | | | 16 | 17 |
| Йомшак яфраклылар | | 35 | | 35 | | 390 | | 425 |
| Ясалма (урман культураларын булдыру) - барлыгы: | 4 | 63 | 6 | 73 | 9 | 213 | 39 | 334 |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | 4 | 63 | 5 | 72 | 9 | 213 | 23 | 317 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Каты яфраклы | | | 1 | 1 | | | 16 | 17 |
| Йомшак яфраклылар | | | | | | | | |
| Катнаш - барлыгы: | | | | | | | | |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | | | | | | | | |
| Каты яфраклы | | | | | | | | |
| Йомшак яфраклы | | | | | | | | |
| *Табигый торгызылу* барлыгы: | | 36 | | 36 | | 390 | | 426 |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | | 1 | | 1 | | | | 1 |
| Каты яфраклы | | | | | | | | |
| Йомшак яфраклы | | 35 | | 35 | | 390 | | 425 |
| *Үсентесен саклау юлы белән -* Барлыгы: | | | | | | 67 | | 67 |
| Алардан токымнар буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | | | | | | 67 | | 67 |
| Каты яфраклы | | | | | | | | |
| Йомшак яфраклы | | | | | | | | |

# Урман торгызу методлары

Урман торгызу кисеп ташланган, һәлак булган, зарарланган урманнарны торгызу максатларында гамәлгә ашырыла. Урманнарны торгызу урман үсентеләрен торгызуны, урманнарның биологик күптөрлелеген, аларның файдалы функцияләрен саклап калуны тәэмин итәргә тиеш.

Урман торгызу табигый, ясалма яки катнаш урман торгызу юллары белән гамәлгә ашырыла. Россия Федерациясе Урман кодексының 62 статьясының 1 өлеше.

Табигый урман торгызу урманны торгызуга түбәндәге ярдәм чаралары хисабына гамәлгә ашырыла: урман агач токымнарының урман утыртмаларын кискәндә, киртәләп алганда һ.б. яшь агачын саклау юлы белән (алга таба - табигый урман торгызуга ярдәм).

Ясалма урман торгызу урман культураларын булдыру юлы белән башкарыла: чәчкеннәрне, чәчкечләрне, чыбыкчаларны утырту яки урман үсемлекләре орлыкларын чәчү.

Катнаш урман торгызу табигый һәм ясалма урман торгызуларны берләштерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Урман торгызулар түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

а) агач материалы әзерләү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә - шушы урман кишәрлекләренең арендаторлары тарафыннан:

Россия Федерациясе Урман кодексының 62 статьясының 2 өлеше.

б) әлеге пунктның "а" пункт өлешендә күрсәтелгәннәрдән башка урман кишәрлекләрендә:

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан, аларның вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьялары нигезендә.

Урманнарны торгызу урман кисүләр җирләрендә, янгыннан соң калган җирләрдә, бушлыкларда, урман үсентеләре белән капланмаган башка ачыклыкларда яисә урман торгызу өчен яраклы җирләрдә гамәлгә ашырыла.

Урман торгызу максатларында агачлар киселгән урыннар, көекләр, аралыклар, агачсыз урыннар, бүтән урман үсемлекләре белән капланмаган яки урман торгызу өчен яраклы җирләрнең мәйданнары ел саен исәпкә алына, алардагы үсентеләрнең һәм яшь агачларның торышына карап, урман торгызу ысуллары ачыклана. Шул ук вакытта табигый торгызылуга, ясалма торгызылуга, катнаш торгызылуга тиешле булган урман кишәрлекләре мәйданнары да исәпкә алына.

Дәүләт урман реестры, урман корылышы материаллары, махсус тикшеренүләрнең һәм диләнкеләрне аерып чыгаргандагы материалларның күрсәткечләре буенча урман торгызуны таләп итүче җирләрне исәпкә алу.

Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән һәр урман кишәрлегендә урманнарны торгызу гамәлләре урманнарны торгызу проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман торгызу проекты түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

урман кишәрлегенең урнашу урыны сыйфатламасы (урманчылыкның (урман-паркның), кишәрлек урманчылыгының исеме, квартал номеры, бүлендек номеры, урман кишәрлегенең мәйданы);

урман кишәрлегендәге табигый-климат шартлары сыйфатламасы (ш.и. рельефы, гидрологик шартлары, туфрагы һ.б.);

кисеп ташланган урыннарның сыйфатламасы (мәйдан берәмлегендә түмәрләр саны, кисүдән калдыкларыннан һәм үзагач чүп-чарларыннан чисталык торышы, калдырылган бүтән агачларның һәм куакларның холкы һәм урнашуы, туфракның томалану һәм туфракның минеральләшү дәрәҗәсе һ.б.);

бар булган урман агач токымы шытымнарының һәм үсентеләренең сыйфатламасы (токымнарның составы, уртача яше, уртача биеклеге, мәйдан берәмлегендә агачларның һәм куакларның күләме, аларның урман кишәрлеге мәйданы буйлап урнашуы, урман утыртмаларының торышы һәм аның бәясе, һ.б.);

урман, торгызылучы урманнарның токым составын торгызу буенча проектланучы ысулга карата нигез;

урман торгызу буенча эшләрне башкару вакытлары һәм ысуллары;

урман торгызу эшләрен тәмамланган дип табу өчен торгызылучы урманнарның бәя күрсәткечләре (яше, токымнарның составы, уртача биеклеге һ.б.).

Утырту материалын үстерү һәм урман культураларын булдыру өчен 1997 елның 17 декабрендәге "Орлыкчылык турында" № 149-ФЗ Федераль законы (Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 1997, № 51, ст. 5715) нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүче урман утыртмаларының районлап бүленгән орлыклары кулланыла.

Урман торгызу өчен кулланыла торган яшь агачларны торгызуда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле утырту материалларының параметрлары 18.1 таблицада күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Сәнәгать калдыклары, рекреация басымнары, зарарлы организмнар һәм бүтән начар йогынты белән зарарланган урманнарда урман торгызулар әлеге зарарлау факторларына карата тотрыклы урман утыртмаларын формалаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

### *Табигый урман торгызу*

Урманнарны табигый торгызуга ярдәм итү максатларында түбәндәге чаралар күрелә:

урман үсентеләре ябалдашлары астында шытып чыккан урман үсентеләренең яшәргә сәләтле, әлеге табигый-климат шартларында яңа урман үсентеләре булдырырга сәләтле төп урман агач токымнары буынын (яшь агачларны) саклап калу. Ике яшькә кадәрге агач үсентеләре (үзлегеннән үсеп чыккан) яшь агачларга кертелми;

кыйммәтле урман токымлы урман утыртмаларын кискәндә яшәргә сәләтле, яхшы тамыр җибәргән, 2,5 метрдан артык биеклектәге төп урман агач

токымнарын булдыруда катнашучы урман үсентеләрен (яшь агачларны) саклап калу;

урман үсемлекләре белән капланмаган мәйданнарда кыйммәтле агач токымнарының урман үсентеләре шытымнарын карау;

туфрак өслеген минеральләштерү;

мәйданнарны киртәләү.

Кыйммәтле урман агач токымнарының урман утыртмалары шытымнарын саклау чаралары урман утыртмаларын кисү белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла. Мондый очракларда кисүләр башлыча кар өсли кыйммәтле урман агач токымнары шытымнары һәм яшь агачлары санын урман бүлемтеге биргәндә каралганнан күбрәк юк итүдән һәм зарарлаудан саклауны тәэмин итәрлек технологияләр кулланып гамәлгә ашырыла. Кисүләр уздырганнан соң шытымнарны һәм яшь агач токымнарын кисек калдыкларыннан, сынган һәм зарарланган урман утыртмаларыннан арындыру юлы белән аларны карау уздырыла.

Кисүләр уздырганда урман үсентеләрен яшәргә сәләтле нарат, чыршы, пихта, имән, бук, корычагач һәм үзләренә туры килә торган табигать-климат шартларындагы кыйммәтле агач токымнарының бүтән урман үсентеләре шытымнары һәм яшь агачлары сакланып калырга тиеш.

Төп урман агач токымнары үсентеләрен кисеп ташланган урыннардагы тирәлекнең начар факторларыннан саклау, урман утыртмаларының уңышлы үсешен һәм тиешле составта тулысынча формалашуын тәэмин итү өчен тиңдәш урман агач һәм куаклык токымнарының (өрәңге, юкә һ.б.) үсентеләре тулысынча яки өлешчә саклана.

Урман утыртмаларының тереклек итүгә яраклы шытымнары һәм яшь агачлары түбәндәге билгеләр белән сыйфатлана:  куе ылыс, яшел яки куе-яшел төсле ылыс, сизелерлек чагыла торган тоныклык, биек ноктасы очлы яки конус формалы симметрияле куе яки уртача куелыктагы ябалдашлы кәүсәсенең биеклегеннән кимендә 1/3 озынлыктагы төркемнәрдә һәм кәүсәнең 1/2 биеклегендә – берәм-берәм урнашкан, шытым биеклеге буенча соңгы 3-5 елда югалмаган, бөренең югары өлешендәге шытымы ябалдашның өске яртысындагы ян-як ботак үсентеләреннән ким түгел, туры зарарланмаган кәүсәчекләр, шома яки вак тәңкәле лишайникларсыз кайры

Җиргә яткан агачтан үсүче шытымны һәм ылыслы урман утыртмаларының яшь агачын тереклек итүгә яраклылык буенча аталган билгеләргә кертергә була, әгәр дә җирдә яткан агач чересә, ә шытымның тамырлары туфракның минераль өлешенә үтеп кергән булса.

Комсыл туфракларда үсүче наратлыкларда чыршылы урман утыртмаларының шытымы чыршы утыртмасы агачлыкларның сыйфатын һәм продуктлылыгын киметмәгән очракта саклана. Нарат һәм чыршы урман утыртмаларын торгызганда кирәкле очракларда шытым агачлар киселгән урыннарда туфракны саклау һәм тотрыклы һәм югары җитештерелешле нарат-чыршы урман утыртмаларын саклау өчен саклана.

Каты яфраклы урман утыртмалары токымының тереклек итүгә сәләтле шытымы ябалдашының нормаль, кәүсәчекләрнең биеклеге һәм киңлеге буйлап пропорциональ үсеш алган яраклануы белән сыйфатлана.

Зарарлы организмнар белән зарарланган, аз үсеш алган һәм агач кискәндә зарарланган шытым диләнке эшләре тәмамланганнан соң кисеп ташланырга тиеш.

Барлык агач токымнарының шытымнары түбәндәгеләргә бүленә:

– биеклеге буенча – өч эрелек категориясенә: 0,5 метрга кадәр вак, 0,6-1,5 метр – уртача һәм 1,5 метрдан артык – эре. Саклanырга тиешле яшь агач эре шытым белән бергә исәпкә алына:

куелыгы буенча – дүрт категориягә: сирәк – 2 меңгә кадәр, уртача куелыкта – 2-8 мең, куе – 1 гектарда 8 меңнән артык үсемлек;

мәйданы буйлап бүлүгә карап - очравына карап өч категориягә (шытымның очравы - ул исәпкә алынган үсемлекле мәйданнарның тәҗрибә мәйданында яки диләнкедә салынган исәпле мәйданнарның гомуми күләменә карата процентларда чагылдырылган күрсәткече): тигез – 65% күбрәк очракта очрый, тигез түгел – 40-65% очракта очрый, төркемле (тереклек итүгә яраклы һәм йомык шытымның кимендә 10 вак данәсе яки 5 уртача һәм эре нөсхә данәләре).

Сайланма кисүләрне үткәргәндә урман чыбылдыгы астындагы барча шытымнар һәм яшь агачлар, күләменә, тереклек итүгә яраклылык дәрәҗәсенә һәм аларның мәйдан буйлап урнашу холкының нинди булуына карамастан, исәпкә алынырга һәм сакланырга тиешле.

Урман утыртмаларын тоташ кисүләргә аерганда 1 гектардан артык мәйданлы, кыйммәтле урман агач токымнарының урман утыртмалары өстенлек итүче урманны табигый торгызуны тәэмин итәрлек күләмдә шытымнары һәм яшь агачлары булган урман кишәрлекләре һәм кисүләр башкарылганнан соң урман торгызу буенча чаралар үткәрелергә тиешле кишәрлекләр бүленә.

Төрле биеклектәге шытымнар булганда аның исәбен биеклеге буенча төркемнәргә бүлеп башкарырга кирәк.

Шытым күләмен ачыклау өчен вак һәм уртача шытымны эрегә хисаплау коэффициенты кулланыла. Вак шытым өчен – 0,5, уртачага – 0,8, эрегә 1,0 коэффициенты кулланыла. Әгәр дә шытым составы буенча катнаш булса, торгызу бәясе табигый-климатик шартларга туры килүче төп урман агач токымнары буенча бирелә.

Шытымнарны һәм яшь агачларны исәпкә алу аларның санын һәм тереклек итүгә яраклылыгын 10 процентган да артмаган ялгышлык белән ачыклау методлары белән башкарыла.

Барлык очракларда да визирларда һәм санап чыгу тасмаларында алдан ук билгеләнгән мәйданнар арасындагы ераклыкларны сакларга кирәк. 5 гектарга кадәрле мәйданлы кишәрлекләрдә 30 хисап мәйданы салына, 5-10 гектарлы диләнкеләрдә – 50 һәм 10 гектардан зуррак мәйданнарда – 100 мәйдан.

Мәйданнарны киртәләү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү яңа чыккан урман үсентеләренә һәм шытымнарына кыргый яисә йорт хайваннары зарар китерү куркынычы булган очракларда планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызуга ярдәм күрсәтү урман үсентеләренең кыйммәтле агач токымнары орлыклары чыганаклары (якындагы урман үсентеләре, аерым орлык агачлары яисә аларның төркемнәре, чәчәклекләре, полосалары, тулылыгы 0,6 дан артык булмаган урман үсентеләре ябалдашлары астындагы кисәргә керешелә торганнары) булган мәйданнарда гамәлгә ашырыла.

Туфракны минеральләштерү урман утыртмаларының орлык уңышы канәгатьләндерерлек һәм уңдырышлы булган елларда башкарылырга тиеш. Җир өстендәге туфракны минеральләштерүнең иң кулай вакыты - урман агач үсемлекләренең орлыклары коела башлаганчы.

Туфракның механик составына һәм дымлылыгына, үләнле капламының куелыгына һәм биеклегенә, урман түшәмәсенең ныклылыгына, җир өстендәге туфракның минеральләшү дәрәҗәсенә, орлыклык агачларның күләменә һәм кишәрлектәге башка шартларга карап, эшләр туфракны механик, химик яки ят чаралар белән эшкәртү юлы белән башкарыла.

Урманны табигый торгызуга ярдәм буларак үткәрелгән чараларның нәтиҗәләре шытымның куелыгы 18.2 таблицада күрсәтелгән нормативларга туры килгәндә нәтиҗәле дип табыла. Урманны табигый торгызуга ярдәм буларак үткәрелгән чараларның нәтиҗәлелеген исәпкә алу эшләрне башкарганнан соң 2 ел үткәч башкарыла.

Хуҗалык эшчәнлеге чикләнгән режимдагы урманнарда, шул исәптән милли паркләрдагы урманнарда, табигать тыюлыкларында урманнарны табигый торгызуга ярдәм итүнең башка чаралары, алар тиешле территорияләрне саклау режимын бозарлык булмаса гына, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Шытымнар саны 18.2 таблицасында күрсәтелгәннәрдән кимрәк булганда, урманнарны ясалма яисә катнаш торгызуның өстәмә чаралары карала.

Агач токымнары белән урманнарны табигый торгызу уңышлы уздырылган мәйданнар урман үсемлекләре каплаган җирләргә кертелә.

### *Ясалма һәм катнаш урман торгызу*

Урманнарны ясалма торгызу хуҗалык өчен кыйммәтле урман агач токымнарын урманнарны табигый торгызуны тәэмин итү мөмкин булмаганда яисә урманнарны катнаш торгызу максатка ярашсыз булганда, шулай ук урман культуралары һәлак булган урман кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын булдыру өчен урман кишәрлеген әзерләгәндә шуннан соңгы барлык технологик гамәлләрне сыйфатлы үтәү өчен, шулай ук янгын куркынычын киметү һәм урман культураларының санитар торышын яхшырту өчен шартлар тудыру чаралары гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлеген әзерләүгә түбәндәгеләр керә:

урман кишәрлеген тикшерү;

урманнарны торгызуны проектлау;

урман кишәрлеген бүлеп чыгару;

урман культураларының яисә туфрак эшкәртү полосаларының булачак рәтләре линияләрен маркалау һәм техника эшләү өчен куркыныч булган урыннарны билгеләү;

мәйданны ауган агачлардан, ташлардан, кирәксез агач үсемлекләреннән, вак түмәрләрдән, корыган агач кәүсәләреннән тоташ яисә полосалап чистарту;

түмәрләрне казып алу яисә аларның биеклеген техника йөрешенә комачауламаслык дәрәҗәдә киметү;

урман кишәрлеге өслеген планлаштыру, мелиоратив эшләр алып бару, авышлыкларда террасалар кисү;

зарарлы туфрак организмнары белән башлангыч көрәш.

Урман кишәрлеген тикшергән вакытта аның торышы һәм урман утыртмаларын үстерүгә яраклылыгы ачыклана, тереклек итүгә яраклы шытымнарның һәм кыйммәтле урман агач токымнары яшь агачларының күләме һәм урнашуы, дымлы үзагач һәм диләнке калдыклары белән чүпләнү дәрәҗәсе, түмәрләрнең саны һәм биеклеге, кишәрлекнең техника эшләре өчен мөмкинлеге, туфракта зарарлы организмнар булу-булмавы билгеләнә, урман үсемчелеге шартларының тибы аныклана һәм урман культураларын булдыру ысулы ачыклана.

Урман кишәрлеген ясалма урман торгызу эшләренә бүлгәндә, аны урман кварталының чикләренә, юлларына һәм башка даими ориентирларга бәйләп, геодезия сүрәте ясала.

Агачлар киселгән урыннарны урман культураларын булдыру өчен әзерләгәндә урман утыртмалары киселә.

Агачлар авып яткан җирләрне тоташ чистартканда кирәкле булмаган агач үсемлекләренең кәүсәчекләре, вак түмәрләр урман кишәрлеге чикләренә күчерелә яки аның территориясендә өемнәргә өелә.

Өлешчә чистарту төрле киңлектәге полосалар белән тоташ чистарту мөмкин булмаган яки максатчан булмаган очракларда башкарыла.

Урман кишәрлекләрен чистартканда һәм түмәрләрне казып алганда туфракның өске уңдырышлы капламы максималь сакланырга тиешле.

Туфракны эшкәртү алымнары урманнарны ясалма торгызуны проектлаганда табигать-климат шартларына, туфрак типларына һәм бүтән факторларга бәйле рәвештә сайлап алына.

Туфракны эшкәртү барлык кишәрлекләрдә (тоташ эшкәртү) яисә аның бер өлешендә (өлешчә эшкәртү) механик, химик яисә термик алымнар белән гамәлгә ашырыла. Нигезе, техника кулланып, туфракны механик эшкәртү була.

Тоташ механик эшкәртү барча территориясендә техника эшенә комачаулар булмаган урман кишәрлекләрендә башкарылырга мөмкин (6 градуска кадәрге тау текәлекләре булганда һәм туфракның су һәм җил эрозиясе булмаганда).

Туфракны өлешчә механик эшкәртү полосаларны сөрү, минеральләштерү яки полосалардагы яки мәйданнардагы туфракны көпшәкләндерү, буразналар яки траншеялар кисү, микроюгарылыклар (пластлар, түтәлләр, сыртлар, таучыклар), чокырлар булдыру юлы белән башкарыла.

Туфракны буразналап яки полосалар эшкәрткәндә аларның туры сызыклы булуы һәм параллельлеге сакланырга тиеш.

Хәрәкәт итүче комнар, кирәк булган очракта, куаклы яки үләнле үсемлекләрдән кулисалар ясау, механик саклагычлар (щитлар, ботаклар, камыш сабаклары яки салам һ.б.ш.) кую, өслеккә ябышучан матдәләр сөртү юлы һәм башка ысуллар белән беркетелә.

Туфракны баштан эшкәртмичә, искәрмә буларак, яхшылап чистартылган агач киселгән 1 гектарга 500 данәгә кадәр түмәрләре булган урыннарда, аз кыймматле тиз үсүче урман агач токымнары урман утыртмаларының торгызылу куркынычы булмаганда, һәм шулай ук күп еллык-туңлы җирләрдә чәчкеннәрне утыртып, урман культураларын булдыру рөхсәт ителә.

Урман культуралары төп бер агач токымының урман үсентеләреннән (чиста токымнардан) яисә төп берничә агач токымыннан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан (катнаш культуралар) булдырылырга мөмкин.

Урман культуралары төп бер агач токымының урман үсентеләреннән (чиста токымнардан) яисә төп берничә агач токымыннан һәм юлдаш агач һәм куак токымнарыннан булдырылырга мөмкин.

Бар булган юлдаш агач токымы җирле урман агач токымнарыннан һәм куак токымнарыннан сайлап алганда аларның төп урман агач токымына йогынтысын исәпкә алырга кирәк.

Юлдаш агач һәм куак токымнары урман культураларына кертү башлыча аларның рәтләрен төп урман агач токымы рәтләре белән чиратлаштырып гамәлгә ашырыла.

Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасындагы агач киселгән урыннарда яңа, дымлы һәм дымландырылган туфракларда чәчкеннәрне утырту юлы белән булдырыла торган культураларның беренчел куелыгы кимендә 1 гектарга 3 мең булырга тиеш, урман-дала зонасындагы коры туфракларда - 1 гектарга 4 мең данә. Орлык чәчеп урман культураларын булдырганда утырту урыннарының саны чәчкеннәрне утыртудан булдырылган урман культураларының күрсәтелгән нормалары белән чагыштырмача 20% арта. Урман культураларын үсентеләрдән булдырганда утыртылган үсемлекләрнең санын 1 гектарга 2,5 мең данәгә кадәр киметергә мөмкин.

Зарарлы организмнар таралу чыганакларында утыртуның (чәчүнең) башлангыч куелыгы) һәм урман культуралары составы махсус тикшеренүләр нигезендә билгеләнә.

Урман культураларын булдыруның төп ысулы утырту материалының төрле төрләре белән гамәлгә ашырыла торган утыртудан гыйбарәт. Су һәм җил эрозиясенә дучар булган туфракларда, артык дымлы туфракларда һәм утырту урыннарын чүп үләннәр бик тиз басып китә торган кишәрлекләрдә, шулай ук дымлылык булмаган районнарда гамәлгә ашырырга кирәк.

Утырту өчен 18.1 таблицада күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүче чәчкечләр кулланыла.

Урман культураларын орлык чәчеп булдыру үлән капламы аз үсеш алган урман кишәрлекләрендә рөхсәт ителә.

Урман культураларын утырту һәм чәчү туфракка ашламалар, үсемлекләрне яклау чаралары кертү, шулай ук туфракны яхшырта торган махсус үләннәр чәчү белән бергә алып барылырга мөмкин.

Күп очракларда урман культураларын утыртуның һәм чәчүнең иң яхшы срогы – яз башы, бөреләр уяна башлаганчы.

Туфрак өслеген чүп үләннәр һәм агач-куак үсемлекләре сырып алмасын, туфракта дым җыелсын өчен урман культураларын агротехник карау уздырыла.

Агротехник карауга түбәндәгеләр кертелә:

үсемлекләрне үлән һәм туфрак өемнәреннән, ком өеменнән, туфракны су юып алып китүдән һәм җил белән очыртудан, салкыннан кысылудан кул ярдәмендә төзәткәләү;

культуралар рәтләрендә һәм рәт араларында үлән һәм агач үсемлекләрен юк итеп, туфракны көпшәкләндерү;

үлән һәм кирәксез агач үсемлекләрен юк итү һәм чыгуларын булдырмый калу;

урман культураларын өстәү, минераль ашламалар белән тукландыру һәм урман культураларына су сибү.

Урман зонасында агротехник карау башлыча төп урман агач токымының урман үсентеләрен чүп үләннәр һәм кирәксез тиз үсә торган урман агач токымнары йогынтысы аркасында начар үсүдән һәм һәлак булудан саклап калу максатларында уздырыла.

Агротехник карау алымнары, саны һәм озынлыгы табигать-климат шартларына, культивацияләнә торган урман агач токымның биологик үзенчәлекләренә, туфрак эшкәртү алымына, урман культураларын булдыру ысулына, кулланыла торган утырту материалы зурлыгына бәйле була.

Урман-дала зонасында агротехник карап тоту башлыча туфрактагы дымны җыюга һәм саклап тотуга юнәлдерелә.

Агротехник карау алымнары, саны һәм озынлыгы табигать-климат шартларына, культивацияләнә торган урман агач токымның биологик үзенчәлекләренә, туфрак эшкәртү алымына, урман культураларын булдыру ысулына, кулланыла торган утырту материалы зурлыгына бәйле була.

Чүп үләннәрне һәм кирәксез агач үсемлекләренә каршы көрәш өчен химик чаралар куллану, Россия Федерациясе урман законнары нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклауны исәпкә алып, бик сирәк очракларда гына рөхсәт ителә.

Үсеп китү мөмкинлеге 25-85% булган урман культуралары (үсемлекләрнең һәлак булган нөсхәләре урынына яңаларын утырту) өстәлергә тиеш. Тигез һәлак булмый торган урман культуралары кишәрлек мәйданы буйлап үсеп китүчәнлегенә карамастан өстәләләр.

Урман культураларының үсеп китүчәнлеге бәясе сакланган үсемлекләре булган утырту (чәчү) урыннарының санын тәҗрибә мәйданында исәпкә алынган гомуми утырту (чәчү) урыннары санына карата процент күрсәткеченнән чыгып ачыклана.

Культивацияләнүче үсемлекләрнең куелыгы һәм урнашуы тәҗрибә кишәрлекләрендә яки урман культураларының урман кишәрлеге диагонале буенча тигез аралыклар аша урнашкан исәпкә алынган рәт өлешләрендә билгеләнә. Тәҗрибә мәйданнары киңлеге буенча рәт араларындагы үзәктән санаганда төп токымның кимендә 4 рәтен һәм токымнар катнашмасының тулы циклын үз эченә алырга тиеш.

3 гектарга кадәрле зурлыктагы урман кишәрлекләрендә мәйданның кимендә 5%ы яки утырту (чәчү) урыннарының күләме исәпкә алына, 4тән 5 га кадәр – кимендә 4%, 6дан 10 га кадәр – кимендә 3 %, 11 дән 50 гектарга кадәр – кимендә 2%, 50дән 100 гектарга кадәр – кимендә 1,5%, 100 га һәм аннан да зуррак – кимендә 1%. Культивацияләнүче урман үсемлекләренең торышына һәм холкына карап, процент арттырылырга мөмкин.

Тоташ буйлы чәчүләрдә чәчү урыннары, әлеге мәйдан буенча аерым урман агач токымнары урман утыртмалары урнашуына карап, 0,4-1 метр саен исәпкә алына. Мондый исәпкә алу ысулында һәлак булган үсемлекләргә 0,8 метрдан 2 метрга кадәрге рәтләр һәм культивацияләнүче агач үсемлекләре шытымнары булмаган урыннар керә.

***Урманнарны катнаш торгызу*** кыйммәтле урман агач токымнарын табигый торгызу тәэмин ителмәгән урман кишәрлекләрендә утырту һәм чәчү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Урман культураларын утырту һәм чәчү юлы белән кертелгән төп урман агач токымы урман үсентеләре саны урман үсентеләре шытымнарына тигез яисә аннан да күбрәк булган урман кишәрлекләре мәйданнары урманнарны катнаш торгызу биләгән урман үсентеләрен саны ким булган мәйданнарга кертелә.

Катнаш урман торгызуда урман культураларының куелыгы (мәйдан берәмлегендә утырту яки чәчү урыннары) бар булган шытым һәм төп урман агач токымы урман утыртмаларының яшь агачлары күләменә карап, культивацияләнүче үсемлекләрнең һәм төп урман агач токымнары урман утыртмаларының үсентеләре күләме 17.2 таблицада күрсәтелгәннәргә карата кимрәк булмаганны исәпкә алып билгеләнә.

Урман утыртмаларының ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу гадәттә санитар-гигиеник функцияләрен арттыру максатларында яшел зоналарда, эрозиягә каршы һәм башка яклаучы урманнарда уздырыла.

Урман үсентеләре ябалдашлары астында урманнарны катнаш торгызу урман культураларының башлангыч куелыгы тиешле табигать-климат шартларында урманнарны ясалма торгызу өчен билгеләнгән норманың кимендә 50%ын тәшкил итәргә тиеш.

Үсеп китүчәнлеге кимендә 25% булган урман культуралары һәлак булган дип санала.

Урман культураларын утыртып, ясалма һәм катнаш урман торгызу эшләре башкарылган урман кишәрлекләре мәйданнары 17.1 таблицада күрсәтелгән төп урман агач токымы параметрларына җиткән урман үсемлекләре белән капланган җирләргә карый.

17.1 таблица

**УРМАН АГАЧ ТОКЫМНАРЫНЫҢ УТЫРТУ МАТЕРИАЛЫНА ҺӘМ УРМАННАРНЫ ЯСАЛМА ҺӘМ КАТНАШ ТОРГЫЗГАНДА БУЛДЫРЫЛГАН, МӘЙДАННАРЫ УРМАН ҮСЕМЛЕКЛӘРЕ БЕЛӘН КАПЛАНГАН ҖИРЛӘРГӘ КЕРТЕЛӘ ТОРГАН ЯШЬ АГАЧЛАР СЫЙФАТЫНА КАРАТА ТАЛӘПЛӘР**

| Агач токымнары | Утырту материалына таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле яшь агачлыкларга карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Яше, кименд ә, ел | тамыр башланга н җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсә биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимендә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклеге кимендә, м |
| 1. Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | | | | | | | |
| 1.1. Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы районы (ылыслы-киң яфраклы урманнар районы) | | | | | | | |
| Карелия каеныһәм еламсар каен (сөялле) | 2 | 3,0 | 25 | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 4 | 2,0 | 1,1 |
| Еламсар каен (сөялле) | 2 | 2,5 | 20 | Яңа һәм дымлы имән катыш урман | 5 | 2,0 | 1,5 |
| Ботаклы-чатаклы имән | 1 - 2. | 3,0 | 12 | Яңа һәм дымлы имән катыш урман | 8 | 1,7 | 0,9 |
| Европа чыршысы (гади) | 2 - 3. | 2,0 | 12 | Катлаулы, вак үләнле, кара җиләкле | 7 | 2,0 | 1,0 |
| | | | | Озын мүкле, үләнле-сазлыклы | 7 | 2,0 | 0,7 |
| Сукачев һәм Себер карагайлары | 2 | 2,5 | 15 | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 5 | 1,7 | 1,2 |
| Себер эрбет нараты | 3 - 4. | 3,0 | 12 | Шул ук | 9 | 1,6 | 0,8 |
| | | | | Катлаулы, вак үләнле | 5 | 1,5 | 1,5 |
| | | | | Озын мүкле, үләнле | 9 | 1,6 | 0,7 |
| Гади нарат | 2 | 2,0 | 12 | Лишайниклы арчанлы | 7 | 2,5 | 0,8 |
| | | | | Нарат җиләкле, кымызлыклы, кара җиләкле | 7 | 2,0 | 1,2 |
| | | | | Озын мүкле һәм сфагнумлы | 7 | 2,2 | 1,0 |

| Агач токымнары | Утырту материалына таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле яшь агачлыкларга карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Яше, киментдә, ел | тамыр башлангаы җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсә биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимендә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклеге кимендә, м |
| Гади корычагач | 2 | 4,0 | 15 | Яңа һәм дымлы имән катнаш урманнар һәм имәнлекләр | 6 | 2,0 | 1,5 |
| 2. Урман-дала зонасы | | | | | | | |
| 2.1 Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | | | | | | | |
| Еламсар каен (сөялле) | 1 - 2. | 2,0 | 20 | Яңа һәм дымлы имән катыш урман | 5 | 2,0 | 1,3 |
| Ботаклы-чатаклы имән | 1 - 2. | 4,0 | 15 | Коры киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 7 | 1,5 | 0,9 |
| | | | | Яңа киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 7 | 1,5 | 1,1 |
| | | | | Дымлы киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 7 | 1,5 | 1,3 |
| Европа чыршысы (гади) | 2 - 3. | 2,0 | 12 | Яңа һәм дымлы киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 7 | 1,5 | 0,7 |
| Сукачев һәм Себер карагайлары | 1 - 2. | 2,5 | 15 | Яңа киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 5 | 1,5 | 1,4 |

| Агач токымнары | Утырту материалына таләпләр | | | Мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелергә тиешле яшь агачлыкларга карата таләпләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Яше, кименд ә, ел | тамыр башланга н җирдә кәүсәсе диаметры, кимендә, мм | кәүсә биеклеге кимендә, см | урманнар типлары төркеме яисә урман үсентеләре шартлары типлары | яше, кимендә, ел | төп токымнар агачлары саны кимендә, 1 гектарга мең данә | төп токым-нар агачлары ның уртача биеклеге кимендә, м |
| Гади нарат | 2 | 3,0 | 10 | Коры наратлык, киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 6 | 2,2 | 1,1 |
| | | | | Яңа һәм дымлы наратлык, киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар һәм күчеш холыклы урманнар | 6 | 2,0 | 1,3 |
| Ак тирәк | 1 | 3,0 | 15 | Дымлы күчеш холыклы урманнар һәм киң яфраклы токымлы уңдырышлы балчыксыл туфрактагы урманнар | 4 | 0,8 | 2,5 |
| Гади корычагач һәм ланцентлы (яшел) | 1 | 2,0 | 12 | Яңа һәм дымлы имән катнаш урманнар һәм имәнлекләр | 6 | 2,0 | 1,7 |

17.2 таблица

# КЫЙММӘТЛЕ УРМАН АГАЧ ТОКЫМНАРЫНЫҢ ТАБИГЫЙ ТОРГЫЗЫЛУЫНА КАРАП, УРМАН ТОРГЫЗУ АЛЫМНАРЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | | | |
| 1.1. Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы районы (ылыслы-киң яфраклы урманнар районы) | | | |
| Шытымнарны саклау чаралары ярдәмендә урманнарны табигый торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 3 артык |
| | | Яңа | 1,5 артык |
| | | Дымлы | 1 артык |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 4 артык |
| | | Яңа | 3 артык |
| | | Дымлы | 2 артык |
| Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызу яисә урманнарны катнаш торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 1 - 3. |
| | | Яңа | 0,5 - 1,5. |
| | | Дымлы | 0,5 - 1. |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 2 - 4. |
| | | Яңа | 1 - 3. |
| | | Дымлы | 1 - 2. |
| Ясалма урман торгызу | Нарат, чыршы, карагай | Коры | 1 кимрәк |
| | | Яңа | 0,5 кимрәк |
| | | Дымлы | 0,5 кимрәк |
| | Имән һәм бүтән 0,5 метрдан биегрәк булган каты яфраклылар | Коры | 2 кимрәк |
| | | Яңа | 1 кимрәк |
| | | Дымлы | 1 кимрәк |
| 2. Урман-дала зонасы | | | |
| 2.1. Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | | | |
| Шытымнарны саклау чаралары ярдәмендә урманнарны табигый торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 4 артык |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 3 артык |
| | | Яңа имәнлекләр һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар, дымлы һәм тугайлыклы имәнлекләр | 2 артык |
| Туфракны минеральләштерү юлы белән урманнарны табигый торгызу яисә урманнарны катнаш торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 1,5 - 4,0. |
| | | Яңа наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 0,5 - 2,0. |
| | | Дымлы наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 0,5 - 1,5. |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 2 - 3. |
| | | Яңа имәнлекләр һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар, дымлы һәм тугайлыклы имәнлекләр | 1 - 2. |
| Ясалма урман торгызу | Нарат | Бик коры һәм коры наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 1,5 кимрәк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Яңа наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар, дымлы наратлыклар, ярлы туфракта үсүче наратлыклар һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 0,5 кимрәк |
| | Имән | Бик коры һәм коры имәнлекләр, ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар | 2 кимрәк |
| | | Яңа имәнлекләр һәм ярлы туфракта үсүче катлаулы урманнар, дымлы һәм тугайлыклы имәнлекләр | 1 кимрәк |

17.3 таблица

## Урман торгызу чараларының чиратлылыгы

| № п/п | Төрләре буенча исеме | Төргә керүче категорияләр | Чиратлылык | Проектланучы чаралар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Саклык категорияләре | Саклык урманнары<br>Эксплуатацияләнә торган | 1<br>2 | |
| 2. | Мәйданнарның категорияләре | Яңа кисеп ташланган урыннар | 1 | Урман культуралары, табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Көекләр | 2 | Иске көекләрдәге урман культуралары, яңаларында - урман культуралары, табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Агачсыз урыннар һәм иске кисеп ташланган урыннар<br>Азтулылыклы утыртмалар | 3<br>4 | Урман культуралары<br>Катнаш урман торгызу |
| 3. | Өстенлек итүче токым төркемнәре | Имәнлекләр | 1 | Урман культуралары, киләчәктә карап тоту кисүләре белән табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Ылыслы | 2 | Урман культуралары, киләчәктә карап тоту кисүләре белән табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Йомшак яфраклы | 3 | Урман культуралары, булышу (киләчәктә карап тоту кисүләре буләе чыршы, имән үсентеләрен саклау, таб. үстер.) |
| 4. | Урман типлары | Имәнлекләр д1, Д2, Д3.<br>Наратлыклар һәм юкәлекле чыршылыклар, кымызлыклы, имәнле С2, С3, Д2, Д3 | 1<br>2 | Урман культуралары, булышу (ябалдаш астында чәчү, үсентесен саклау һәм алга таба карап тоту кисүләре белән табигый торгызылулар)<br>Урман культуралары, булышу (алга таба карап тоту кисүләре белән агач кискәндә үсентесен саклау) |
| | | Майниклы-кара җиләкле, үләнле наратлыклар, нарат җиләкле һәм кара җиләкле чыршылыклар В2, В3 | 3 | Урман культуралары, булышу (алга таба карап тоту кисүләре белән агач кискәндә үсентесен саклау) |
| | | Ак мүкле наратлыклар А1 | 4 | Урман культуралары, табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Кара җиләкле наратлыклар А3 | 5 | Табигый торгызылуга ярдәм итү һәм өлешчә культуралар |
| | | Нарат җиләкле наратлыклар А2 | 6 | Урман культуралары, табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Елга буендагы, озын мүкле наратлыклар һәм чыршылыклар, А4, В4, С4, Д4 | 7 | Микроюгарылыкларда өлешчә культуралар, табигый үстерүгә ярдәм итү |
| | | Су баса торган имәнлекләр<br>Сфагнумлы һәм кыяклы-сфагнумы наратлыклар<br>Елга буйларындагы озын мүкле сфагнумлы чыршылыклар<br>А5, В5, В4, С5, Д5, Д4 | 8 | Биеклекле урыннардагы өлешчә культуралар, табигый үстерү һәм киптергәннән соңгы культуралар |
| | | Зирек урманы Д5 | | Табигый үстерү |
| | | Таллыклар | | Урман культуралары, табигый үстерүгә ярдәм итү |

17.4 таблица

# Урман торгызу эшләрендә эш урыннарын сайлап алу, урнаштыру һәм планлаштыру

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 1. Эш урыннарын рациональ сайлап алу билгеләре<br>1.1. Яраклаша алырдай яшь агач булганга карап | |
| Торгызылган дип түбәндәге кишәрлекләрне санарга: | |
| - йомшак яфраклы хуҗалыкта | 1 гектарга кимендә 5 мең данә шытымнары яисә орлык нөсхәләре мәйдан буенча чагыштырмача тигез урнашканда |
| - каты яфраклы тәбәнәк кәүсәле хуҗалыкта | 1 гектарга каты яфраклылар токымнарының шытымнары белән 400-600 данә түмәр булганда (400 данәдән ким булса – торгызу канәгатьләнерлек түгел) |
| Вак шытым | 1,5 м биеклектәге нөсхәләре гомуми саныннан 2/3 артык булганда |
| Эре шытым | 5 м биеклектәге нөсхәләре гомуми саныннан 1/3 артык булганда |
| 1.2 Урман культуралары мәйданнары категориясе буенча: | |
| - тоташ сөрү рөхсәт ителә торган | Бушлыклар, ачыклыклар, аланнар һәм авыл хуҗалыгы әйләнешеннән төшеп калган мәйданнар, киселгән урыннар һәм черегән яисә казып алынмаган түмәрләре булган иске янгын урыннары |
| - туфракны полосалар һәм буразналар рәвешендә өлешчә эшкәртү рөхсәт ителә торган | Киселгән урыннар, төп һәм икенчел токымнар белән торгызылмаган янгын урыннар, 1 гектаргага артык дымлы 500 түмәргә кадәр, 600 түмәргә кадәр – яңа һәм коры туфракларда |
| - туфракны буразналар яисә мәйданчыклар рәвешендә эшкәртү рөхсәт ителә торган | Шул ук мәйданнар, әмма аларда тиешенчә 500дән артык һәм 600 түмәр |
| - Туфракны өлешчә эшкәртүне таләп итә торган | Киселгән урыннар, төп токым белән канәгатьләнмәслек дәрәҗәдә торгызылган яисә йомшак яфраклылар белән (соры зирек, фаут усагы һәм башкалар) яисә сирәкләнгән үсентеләр |
| 1.3 Кишәрлек урнашу рельефы буенча: | |
| - оптималь | Диңгез өслегеннән 500 метрга кадәр биеклектәге һәм 5 градуска кадәр тигезлек шартлары |
| - тракторлар кереп йөри ала торган (иминлек күзлегеннән) | 6-12 градус авышлыгы (гомуми билгеләнештәге тракторлар базасында агрегатлар белән эшкәртү: көпчәкле - 8 градустан да артмаган авышлыкларда, башмаклы - 12 градустан да артмаган) |
| 1.4 Гидрологик шартлар буенча (дым күп яратмый торган агач токымнары өчен) | |
| - оптималь | Туфрак-грунт сулары кимендә 30 см тирәнлектә яткан дренажланган туфраклар (мөмкин булса – туфракны эшкәртмичә, ә кирәк чакта – полосаларны фреза яисә сука белән йомшарту, буразналар яру) |
| - мөмкин булган | Дымы вакытлыча артып киткән туфраклар (түтәлләр һәм катламнар рәвешендә микрокалкулыклар әзерләгәннән соң) |
| | Дымы артып киткән туфраклар (дренаж каналлары ярып яисә киптергәннән соң туфракны катламнар белән әзерләү) |
| - мөмкин булмаган | Йомык котлованнар кишәрлекләре (киптерү юлы белән артык дымны чыгару кыенлашкан) |
| 1.5 Урман культуралары эшләре башкарылырга тиешле кисүләрне планлаштыруга таләпләр | |
| - кисү калдыклары | Яндырылырга яисә 3 м киңлектәге тыгыз параллель валларга куелырга тиеш. Кисек калдыклары гомуми мәйданның 20%тан артмаган өлешен биләргә тиеш (вариант: кисек калдыклары бик күп булмаганда, ягъни 1 гектарга 15 скл. куб. м булганда, кисү бүлемтекләре буйлап тигез урнаштырылырга мөмкин) |
| - үзагач | Барлык агач материалы урман культуралары эшләре башланганчы тулысынча алып бетерелергә тиеш. |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| - агач материалының өске складлары һәм йөк төяү мәйданнары били торган мәйдан | 10 гектардан кимрәк булган диләнкеләрдә ул гомуми мәйданның 10%тан артмаган өлешен биләргә тиеш.<br>Барлык кисү урыннарында ул урманнар торгызу эшләрен уздырырга яраклы хәлгә ктерелергә тиеш (агач материалын тулысынча җыеп алу, шул исәптән аска салынганнарын, кисек калдыкларын, бульдозер белән микрорельефны тигезләү һәм башкалар) |
| - диләнкеләрне машина белән эшкәртү барышында минеральләштерелгән туфрак өслеге күләме: | |
| а) урман культуралары булдырылырга тиешле | Көлсу авыр балчык һәм суглин дымлы туфракларда (кара җиләкле, озын мүкле наратлыклар һәм чыршылыклар) – урман бүлемтекләре мәйданының 20%ы. Коры комлы туфракларда (лишайниклы наратлыклар) - урман бүлемтекләре мәйданының 15%тан артмаган өлеше. |
| б) табигый яңартылырга тиешле<br><br><br><br><br>- түмәрләрнең биеклеге<br>- 1 гектарга түмәрләр саны<br>- 600 данәдән артык | Көлсу комлы яхшы дренажланган туфраклардагы тигезлек урманнарында (нарат җиләкле наратлыкларда) 15-20% өлешен минеральләштерү рөхсәт ителә (үзлегеннән орлыкларын чәчүне тәэмин итеп). Табигый яңартылуга ярдәм итү өчен бүлеп бирелгән кисү урыннарында туфракны минеральләштерү гомуми мәйданның кимендә 20-30%ында уздырылырга тиеш (шытымнарны саклап калу шарты белән).<br>Диаметрының 1/3ыннан артмаган, диаметры 30 сантиметрдан нечкәрәк, 10 сантиметрдан артмаган<br>Җир белән тигез өлештә алдан түмәрләрне казып чыгармыйча, чистартмыйча, кисеп алмыйча сукалар, фрезалар, урман утырту машиналары, культиваторлар белән эшләү рөхсәт ителми.<br>Эре утырту материалларын механикалаштырылган утырту алдыннан полосалап казып алу юлдаш һәм куак токымнары үсентеләре белән капланган кисүләр урыннарында аеруча нәтиҗәле була (полосаларның киңлеге 2 м.). |
| 1.6. Кишәрлекләрне урман культуралары фондына кертүнең рөхсәт ителмәгән үзенчәлекләре | |
| - урманчылык<br><br>- техник-икътисади<br><br><br><br>- туфракның тамырлар үтеп керерлек тыгыз катламы тирәнлеге буенча | Хуҗалык өчен кыйммәтле токымнар белән табигый рәвештә канәгатьләнерлек яңара торган мәйданчыклар<br>Су бастырылырга яисә корылмалар куелырга тиешле җирләр. Хуҗалык йогынтысы өчен мөмкин булмаган, күләме һәм әһәмияте буенча зур булмаган, аерым урнашкан, ерак урнашкан, урман культуралары булдыру өчен икеләтелгән чыгымнар таләп итүче мәйданнар<br>Шуннан артык түгел: көньяк тайгада - чыршы өчен - 40 һәм нарат өчен 60 см; катнаш урманнарда - чыршы өчен - 50 см һәм нарат өчен - 80 см; киң яфраклы урманнарда - чыршы өчен - 60 см һәм нарат өчен - 120 см. |
| 2. Кишәрлекләр конфигурациясе һәм күләме | Туры покмаклы яисә трапеция сыман, агрегатлар эшләү өчен уңайлы. Эре массивлар рәвешендә, мөмкин кадәр тигез яклы |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| 3. Кишәрлекне җирлектә беркетү | Урман культуралары эшләрен алып бару өчен бүлеп бирелгән барлык мәйданнар покмак үлчәү рәвешендә фотога төшерелгәннән соң, сызыклары кисешкәш җирләрдә (кишәрлек яклары) баганалар утырту юлы белән шушы урында беркетелә. Баганалар озынлыгы 2 м, диаметры 12-16 см булырга һәм багананың өске очында төрге белән ике мәртәбә ышкып алып ясалган чокырда (яңагында) тиешле язу ясалырга тиеш. Барлык кишәрлекләр сызымда квартал челтәренә бәйләп, ачык визирлар яисә табигый чикләр белән чикләнгән булырга тиеш. Урман культуралары проектына кушып бирелүче сызымнарда шулай ук утырту материалын казып кую чокырларның кайда урнашуы, техника туктап тору урыннары, буразналар, борылып китүче полосалар юнәлеше һәм эшкәртелми торган мәйданнар (юллар һәм башкалар) ачык итеп билгеләнергә тиеш. Сызымнар 1:10000 масштабында төзелә, кишәрлек мәйданы 1 гектарга кадәр төгәллек белән исәпләнә. Фотога төшерү белән бергә (урман культураларын булдыру буенча билгеләнгән алымнарга бәйле рәвештә) мәйданны урында һәм сызымда үсү шартлары буенча бер үк төрле кишәрлекләргә, шулай ук блокларга (әгәр янгынга каршы чокырлар казу зарур булса) кишәрлекләргә алдан бүлгәләү гамәлгә ашырыла. |
| 4. Урманчылык территориясендә урман культуралары кишәрлекләрен урнаштыру | Кишәрлекләр урман культуралары эшләрен төрләре һәм аларны башкару вакытлары буенча мөмкин кадәр бер урында, ахыр чиктә якындагы кварталларда (блокларда) тупланган булырга тиеш. Моның өчен мондый блоклар җыелмасын алдан әзерләп куялар, алар өчен (туфрак өлгерү срокларын исәпкә алып) эшләрне башкару графикларын һәм техника (эш урыннары) хәрәкәте өчен барлык урманнар торгызу эшләре буенча уртак итеп тә, иң мөһимнәре өчен аерым да рациональ маршрутлар әзерлиләр (агачлар утырту, туфракны әзерләү, урман культураларын карау, питомник кору һәм утырту материалларын казып алу һәм башкалар). |
| 5. Техника өчен туктап тору урыннарын һәм тиешле эшләр башкару сезонына эшчеләрне яшәү өчен урнаштыру | Эшкәртелергә тиешле кишәрлекләр (блоклар, кварталлар) мөмкин кадәр территория үзәгендә иң ерак урнашканыннан 10 километрдан ла артык булмаган җирдә урнашырга тиеш. Эшләр күп булып та, эшчеләрне һәр көн саен эш урыннарына илтү мөмкин булмаганда яисә моны нинди дә булса сәбәпләр аркасында башкару мөмкин булмаганда, аларның техник туктап тора торган урыннар янәшәсендә күкмә йортларда, кыр лагерларында яисә торак пунктта вакытлыча яшәүләрен оештыралар. |
| 6. Кишәрлектә утырту материалы өчен казып кую чокырларын урнаштыру (чәчкеннәре алмаштырыла торган запасы булган тракторлар) | Чәчкеннәрне утыртканда аларны китерүнең максималь аралары 50 метрдан артмаска тиеш. Казып кую өчен калкулыктагы, су басмый торган, җил һәм кояш тими торган, туфрагы җиңел булган урыннар сайлап алына. |
| 7. Урман культуралары кишәрлекләрендә эш урыннарын урнаштыру: | |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| - туфракны кул белән эшкәртеп<br>- киселгән агачларны һәм куакларны кулдан җыю<br>- 2 куак кискечнең берьюлы эшләве<br>- ике һәм аннан да күбрәк агрегат бер үк вакытта туфрак эшкәрткәндә<br><br>- тамырлары казып алына торган теләсә нинди эшләр башкару барышында<br><br>- урманнарны механикалаштырылган утыртуда | Бер-берсенә 3 м якын түгел<br><br>Куак кискечләр эшли торган урыннан 30 метрдан якын түгел<br><br>Бер-берсенә 60 м якын түгел<br><br>Сөзәклек буенча - бер-береннән 60 метрдан да якын түгел (бер үк вертикаль буенча техника һәм кешеләр эшләү рөхсәт ителми).<br>Горизонталь буенча - 30 метрдан якын түгел<br><br>Тамырказыгычтан 50 метрдан да якын түгел<br><br>Агрегат артыннан төзәтеп йөрүче эшчеләр аңардан 10 метрдан да якын түгел. Агрегат борылып киткәндә, башка җиргә күчкәндә, каршылыкларга тап булганда үсентеләр утыртучылар трактор туктаганнан соң тракторчы сигналы буенча эш урыннарыннан китәргә тиеш. Агрегат хәрәкәттә вакытта аларга аннан тушәргә, аңа утырырга яисә утырту материалын тутырырга рөхсәт ителми. Берничә агач утырту агрегаты бер үк кишәрлектә берьюлы эшләгәндә бер-берләреннән 20 метрдан да якын булмаска тиеш. |
| 8. Кишәрлекләрдә эшләү урыннарын (чокырлар, буразналар, полосалар) урнаштыру: | Мөмкин кадәр туры сызык буйлап бер-беренә параллель урнашакан кишәрлекнең озын ягы буенча |
| - чокыр-чакырлы рельефлы урында<br>- дымлы туфракларда (кара җиләкле урманнарда) һәм дымлы (озын мүкле) туфракларда | Чокырлар авышлыкта аркылы урнашырга тиеш<br><br>Туфракны киптерү максатларында сулар агып төшү юнәлеше буенча (сөзәклек буенча), аларны табигый су агып төшү чокырларына яисә гамәлдәге мелиоратив челтәрләргә кушып, буразналар яралар |
| 9. Полосалар үзәкләре арасындагы ераклык (буразналар, культуралар рәтләре): | |
| - туфракны өлешчә эшкәрткәндә<br><br>- рәтләр арасындагы ераклык | Төп токымны утыртуның әлеге урман үсү районы өчен билгеләнгән санын тәэмин итәргә һәм кирәк булганда агрегаталар (катоклар һәм башкалар) өчен булачак культуралар рәтләре арасында (киңлеге кимендә 3 метрлык) узып йөрү урыннары салынырга тиеш.<br>Нарат культуралары өчен - 3-4 м, чыршы өчен - 4 м, карагай өчен - 5 метрга якын, кедр өчен - 6 метрга якын (тамырларын казып алганда нарат һәм чыршы өчен 5 метрга кадәр арттырылырга мөмкин) |
| 10. Культуралар рәтләрендә утырту материаллары арасындагы ераклык: | |
| - чәчкеннәр<br>- эре утырту материалы (үсентеләр) | 0.50 - 0.75 м<br>0.75 - 1,50 м (күләменә һәм токымына карап) |
| 11. Урман культураларының 1 гектарына башлангыч куелык (урман утырткaнда): | |
| - уңайлы үсү шартларындагы кисүләрдә<br>- аеруча коры урыннарда | 4 мең данәдән азрак булмаган |

| Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|
| | 7-8 мең данәгә кадәр |
| 12. 1 гектарга карата нарат культураларының куелыгы: | |
| - туфракны өлешчә әзерләгәндә<br>- тоташ булганда<br>- хрущевланган мәйданчыкларда һәм кайры асты кандаласы чыганакларында<br>- азкыйммәте утыртмаларны өлешчә реконструкцияләгәндә | 8 мең данәгә кадәр<br><br>10-20 мең данәгә кадәр<br>15-20 мең данәгә кадәр<br><br>Урман культураларының оптималь куелыгыннан кимендә 50% |
| 13. Урман культуралары өстәмәләре | Чәчкеннәр һәм утыртмалар шактый корыганда (10%тан артыграк) |
| 14. Урман культуралары исәптән төшереп калдырылырга тиеш | Үсеп китүләре 25%тан ким булганда (комнарны беркетә торган токымнардан тыш) |
| 15. Урманнарның табигый яңару чоры | 3-5 ел (һәрбер урман хуҗалыгы районы өчен аерым билгеләнә) |

**УРМАН ТОРГЫЗУ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ХИСАП-ТЕХНОЛОГИК КАРТАЛАРНЫҢ СЫЙФАТЛАМАСЫ**
**№ 2 хисап-технологик карта урман культураларын хрущевланган комлы һәм комлы кәсле туфракларда иске янгыннан калган урыннардагы урман кисүләрдән соң калган май хрущының тотрыклы чыганакларында стандарт чәчкеннәр утыртып җитештерү өчен (лишайниклы, кылганлы, арчанлы, болынлы, кырлыгынлы-паллы, кисүләрнең төрле үләнле типлары). Урман үсү районнары 2 -5.**

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Җитештерү операцияләре комплексы | Хисап агрегаты һәм эшләр күләме | Механизмнарның һәм эшчеләрнең эше | |
|---|---|---|---|---|
| | | | маш./ смен | кеше/көн |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Төпләрне чыгару һәм иске түмәрле мәйданнарны чистарту | С-100, К-2А, 100 ТҮМӘР | 0,20 / 0,20 | 0,20 |
| 2 | Туңга сөрер алдыннан тоташ бөркүле гексохлоран кертү | ДТ-20, СУК. С-КА. 10 МЕҢ КВ. М. | 0,10 / 0,10 | 0,10 / 0,10 |
| 3 | 20-25 см дан кимрәк булмаган тирәнлеккә туфракны тоташ туңга сөрү | ТДТ-40М, ПКЛ-70, 10 МЕҢ КВ. М | 0,67 / 0,67 | 0,67 |
| 4 | Утырту алдыннан үләннәре бетерү белән катламнарны тәлинкәле тырма белән эшкәртү | ТДТ-40М, БДТ-25 | 0,10 / 0,10 | 0,10 |
| 5 | 0,5х1,5 м итеп урнаштырып, параллель рәтләр белән 2 еллык чәчкеннәр утырту | ТДТ-40М, СБН-ЛМД, 10 МЕҢ ДАНӘ | 0,73 / 0,73 | 0,73 / 2,55 |
| 6 | 2-2-2=6 карау еллары буенча рәтләр арасындгы үләннәрне юк итеп, туфрак йомшарту | ДТ-20, ДЛХН-6, 46 КВ | 3,26 / 3,26 | 3,26/ - |
| 7 | 0,5 м киңлектәге полоса буйлап үләннәрне юк итеп һәм еллар буенча туфрак йомшарту: 2+1=3 карап тоту | КИТМӘН, 11,5 МЕҢ КВ. М | - | 11,50 |
| Җәмгысе | | | 5,06 | 19,21 |

Түмәрсез мәйданнарда 1 операция үткәрелми.

Кара пар буенча туфракны әзерләгәндә ГХЦГ кертү нормасы ике мәртәбә кими.

Ачык киңлекләрдә сөрү яклаучы аралар калдыру юлы белән башкарыла, соңыннан аларны культуралар утырткач 3-4 елдан соң культивациялиләр.

## № 3 хисап-технологик карта
## Сукалаган буразналар төбенә орлыктан үрчетелгән чәчкеннәрне урман кисүләрдә утыртып, нарат культуралары булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа нaратлыклар һәм коры наратлыклар А2, В2 (нарат җиләкле һәм майниклы- нарат җиләкле наратлыклар).

Туфраклар: көлсу, кәсле-көлсу, комлы һәм комсыл.

Кисеп атулар: 1 гектарга түмәрләре 900 данәгә кадәр булган яңа гына, кисекләрдән яхшы чистартылган, болынлы, кылганлы һәм кылган-паллы типлар.

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналарның маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Туфракны 10 -15 см тирәнлектәге буразналар ясап буразналарның үзәкләре арасында ара калдырып эшкәртү<br>3.0 м - 3.33 км | ЛХТ – 55, (ТДТ-40М, СУН-3)<br>ПКЛ - 70. | маш/см.<br>маш/см. | 0,33<br>0,33 |
| 2. | 4,44 мең данә чәчкенне вакытлыча казып кую | - | кеше/сәг | 4,48 |
| 3. | Рәттә 0,5 м саен буразна төбенә механикалаштырылган утырту – 3,33 км.<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | ЛХТ – 55 (ТДТ-40М)<br>СУН-3<br>(СБН - 1А) | маш/см.<br>маш/см. | 0,40<br>0,40 |
| 4 | Рәтләр арасындагы шытымнарны юк итеп, туфракны йомшарту юлы белән культураларны дүрт мәртәбә (1-2-1) карау (3,33 х 4 = 13,32 км) | ЛХТ-55, (ТДТ-40М, СУН-3)<br>КЛБ-1,7 | маш/см. | 1,20 / 1,20 |

**Чыгымнар сводкасы**

| ИСЕМЕ | Үлч. берәмл. | Чыгымнар |
|---|---|---|
| Трактор ЛХТ – 55 (ТДТ – 40М, СУН – 3) | маш/см. | 1,93 |
| Сабан ПКЛ - 70 | -//- | 0,33 |
| Культиватор КЛБ – 1,7 | -//- | 1,20 |
| Урман утырту машинасы СБН - 1А | -//- | 0,40 |
| Урманчылык эшләре | кеше/сәг | 11,74 |
| Ике еллык нарат чәчкеннәре | мең данә | 6,66 |

## № 5 хисап-технологик карта
## Чәчкеннәрне урман кисүләрдә буразна төбенә утыртып, ылыслы культуралар булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа коры наратлыклар В3-2 һәм яңа, дымлы урманлыклар - С2, С2-3, С2-Д2 (куаклы ачы җиләк, катлаулы, кара җиләкле-ачы җиләкле, нарат җиләкле-кара җиләкле).

Туфраклар - көлсу һәм кәсле-көлсу, кәсле, соры урман, начар көлсу комлы, ярым балчыклы.

Киселгән урыннар – 1 гектарга түмәрләре 900 данәгә кадәр булган, агач кисекләреннән чистартылган яңа, кылганлы, паллы, болынлы, кура җиләкле, эре үләнле типлары.

Төп токымнар: нарат, чыршы, чиста рәтләр белән карагай.

Нарат культуралары коры наратлыкларда проектлана, чыршы һәм карагай – коры урманчыкларда һәм коры наратлыкларда.

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналарның һәм коралларның маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфракларның категориясе | | |
| | | | | җиңел | уртача | авыр |
| 1. | Буразналар үзәкләре арасы 3,5 м – 2,86 км булган 10 - 12 см тирәнлектә итеп туфракны әзерләү а) I районда<br>б) II - IV районнарда | ЛХТ – 55 (ТДТ-40М)<br>СУН-3)ПКЛ – 70<br>ЛХТ – 55 (ТДТ-40М)<br>СУН-3)<br>ПКЛ-70 | м/см<br>м/см<br>м/см<br><br>м/см | 0,29<br>0,29<br>0,34<br><br>0,34 | 0,29<br>0,29<br>0,34<br><br>0,34 | 0,29<br>0,29<br>0,34<br><br>0,34 |
| 2. | Утыртыр алдыннан буразналарны һәм катламнарны 2 мәртәбә эшкәртү – 2 км х 2 = 5,72 км | ЛХТ – 55<br>(ТДТ-40М, СУН-3)<br>КЛБ - 1.7 | <br>м/см<br>м/см | <br>0,51<br>0,51 | <br>0,51<br>0,51 | <br>0,51<br>0,51 |
| 3. | 3,82 мең данә чәчкеннәрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | | кеше/сәг | 3,86 | 3,86 | 3,86 |
| 4. | Рәттә 0,75 м саен буразна төбенә чәчкеннәрне механикалаштырылган утырту – 2,86 км. а) I районда<br><br><br>Ике еллык чәчкечләр<br>б) II - IV районнарда | ЛХТ - 55.<br>(ТДТ-40М, СУН-3)<br>СБН - 1А<br><br><br>ЛХТ - 55.<br>(ТДТ-40М, СУН-3)<br>СБН - 1А | <br>м/см<br>м/см<br>м/сәг<br>т.данә<br><br>м/см<br>м/см | <br>0,34<br>0,34<br>6,23<br>3,82<br><br>0,40<br>0,40 | <br>0,34<br>0,34<br>6,23<br>3,82<br><br>0,40<br>0,40 | <br>0,34<br>0,34<br>6,23<br>3,82<br><br>0,40<br>0,40 |

РТК бетү № 5

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналарның һәм коралларның маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфракларның категориясе | | |
| | | | | җиңел | уртача | авыр |
| | Ике еллык чәчкечләр | | м/сәг<br>т.данә | 7,21<br>3,82 | 7,21<br>3,82 | 7,21<br>3,82 |
| 5. | Рәтләр арасындагы һәм янындагы шытымнарны юк итеп, туфракны йомшарту юлы белән культураларны механикалаштырылган карау:<br>Наратлыкларда – дүрт мәртәбә (0 – 1 – 2 – 1) – 2,86 х 4 = 11,44<br>Ылыслылар урманчыкларында – биш мәртәбә (1 – 2 – 1 – 1) 2,86 х 14,3 км | ЛХТ – 55<br>(ТДТ-40М, СУН-3)<br>КЛБ – 1,7<br>ЛХТ – 55<br>(ТДТ-40М, СУН-3)<br>КЛБ – 1,7 | м/см<br>м/см<br><br>м/см<br>м/см | 1,03<br>1,08<br><br>1,29<br>1,29 | 1,03<br>1,08<br><br>1,29<br>1,29 | 1,03<br>1,08<br><br>1,29<br>1,29 |
| 6. | Туфракны йомшартып һәм 50 см киңлектә буразналардагы чүп үләннәрне юк итеп, киң яфраклы урманнарда һәм урман-дала зоналарында культураларны кул белән карау:<br>Ярлы туфракта үсүче наратлыкларда – өч мәртәбә (1 – 2) – 1430 х 3 = 4290 кв. м<br>Күчеш холыклы урманнарда – дүрт мәртәбә (1 – 2 – 1) – 1430 х 4 = 5720 кв. м | | м/сәг<br>м/сәг | 38,05<br>50,74 | 53,2<br>70,93 | 85,8<br>114,4 |

**Чыгымнар сводкасы**

| ИСЕМЕ | Үлч. берәмл. | Чыгымнар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | коры наратлыклар | | | ылыслы урманчыклар | | |
| | | җиң. | урт. | авыр | җиң. | урт. | авыр |
| Трактор ЛХТ – 55 (ТДТ – 40М, СУН – 3) | маш/см. | 2,17 | 2,17 | 2,17 | 2,43 | 2,43 | 2,43 |
| Сабан ПКЛ - 70 | -//- | 0,29 | 0,29 | 0,29 | 0,29 | 0,29 | 0,29 |
| Культиватор КЛБ – 1,7 | -//- | 1,03 | 1,03 | 1,03 | 1,29 | 1,29 | 1,29 |
| Урман утырту машинасы СБН - 1А | -//- | 0,34 | 0,34 | 0,34 | 0,34 | 0,34 | 0,34 |
| Урманчылык эшләре | кеше/сәг | 10,09 | 10,09 | 10,09 | 10,09 | 10,09 | 10,09 |
| Ике еллык нарат чәчкеннәре | мең данә | 3,82 | 3,82 | 3,82 | 3,82 | 3,82 | 3,82 |

## № 6 хисап-технологик карта
## Урмансыз бушлыкларда, янгыннан калган урыннарда һәм түмәрсез яки түмәрләре саны аз (1 гектарга 200 данәгә кадәр) һәм үлән капламы зәгыйфь булган урман кисүләр урыннарында чәчкеннәр утыртып, нарат һәм каен катнаш нарат культураларын булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа һәм коры наратлыклар, яңа коры наратлыклар А1, А2, В2 (лишайниклы, верещатниклы, нарат җиләкле).

Туфраклар - көлсу, кәсле-көлсу, комлы һәм комсыл.

Киселгән урыннар – лишайниклы, арчанлы, кырлыганлы-паллы типлар.

Төп токым: нарат Тиңдәш токым - каен.

Культураларның схемасы 1. С – С – С – С 2. С – С – С – С - 5 рәт.
С – С – С – С Б - Б -Б -Б - 1 рәт.

2 схема каенны торгызу мөмкин булмаган шартларда кулланыла.

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналар һәм җиһазлар маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфракның категориясе | |
| | | | | уртача | җиңел |
| 1. | Полосалар кучәрләре буенча 2,5 м саен урман фрезасы белән туфракны йомшарту | Т-74 (ДТ-75)<br>ФЛН-0,8 | м/см<br>м/см | 0,19<br>0,19 | 0,19<br>0,19 |
| 2. | 5,33 мең данә чәчкеннәрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | | м/сәг | 5,38 | 5,38 |
| 3. | Рәттә 0,5 м саен буразна төбенә чәчкеннәрне механикалаштырылган утырту – 4 км. а) I районда<br>2-3 еллык чәчкечләр | Т-74 (ЛХТ-55<br>ТДТ-40М, СУН-3)<br>СБН-1А | м/см<br>м/см<br>м/сәг<br>т.данә | 0,40<br>0,40<br>7,36<br>8,00 | 0,40<br>0,40<br>7,36<br>8,00 |
| 4. | 1 нче районлагы рәтләр тирәсендә үләннәрне юк итеп, туфракны эшкәртеп культураларны механикалаштырылган ысул белән карап тоту (4 км х 4 = 16 км) | МТЗ-80 (ЛХТ-55, ТДТ-40<br>СУН-3)<br>КЛБ-1,7 | м/см<br>м/см | 1,44<br>1,44 | 1,44<br>1,44 |

РТК бетү № 5

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналар һәм җиһазлар маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфракның категориясе | |
| | | | | уртача | җиңел |
| 5. | 50 см полосалары булган рәтләрдә туфракны йомшартып һәм чүп үләннәрне юк итеп, киң яфраклы урманнар зонасында культураларны өч мәртәбә (1 – 1 – 1) кулдан карау (2000 кв. м х 2 = 4000 кв. м) | | кеше/сәг | 49,6 | 49,6 |

**Чыгымнар сводкасы**

| ИСЕМЕ | Үлч. берәмл. | Чыгымнар | |
|---|---|---|---|
| | | Туфракның категориясе | |
| | | җиңел | уртача |
| Трактор ЛХТ – 55 , МТЗ - 80 | маш/см. | 0,89 / 1,44 | 0,59 / 1,44 |
| Культиватор КЛБ – 1,7 | -//- | 1,44 | 1,44 |
| Тырма БДНТ – 2,2 | -//- | 0,19 | 0,19 |
| Урман утырту машинасы СБН - 1М | -//- | 0,40 | 0,40 |
| Урманчылык эшләре | кеше/сәг | 12,74 | 12,74 |
| Ике-өч еллык нарат чәчкечләре | мең данә | 5,33 | 5,33 |

## № 9 хисап-технологик карта
## Урман кисүләрдә имән чикләвеген чәчеп яисә ПКЛ-70 сукасы ярдәмендә әзерләнгән бразна төбенә чәчкеннәр утыртып, имән культуралары булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа һәм дымлы урманчыклар – Д2-3 һәм С2 – Д3

Кәсле-көлсу балчыклы туфрак, соры балчыксыл урман туфрагы (кайвакыт юылган), көрән, селтеле көл кертелгән кара туфрак, болын-кара туфраклы, балчыклы һәм балчык катламы булган комнан торган туфрак, черемәле-карбонатлы балчыклы туфрак.

Киселгән урыннар – 1 гектарга түмәрләре 600 данәгә кадәр булган агач кисекләреннән яхшы чистартылган (юкә, очлы яфраклы чаган һәм башка токымнарны яңарту мөмкин булганда).

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналар һәм җиһазлар маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | |
|---|---|---|---|---|---|
